PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2018 СЕНТЯБРЬ № 9

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ВУНДЕРКИНД БАЛА
сәләт – зур йөк

«ИРЛӘРНЕ ҖӘЛЛӘРГӘ ЯРАМЫЙ!»
ачыктан-ачык сөйләшәбез

МИЛӘҮШӘ АЙТУГАНОВА СЫЙЛЫЙ
«Яшьлек» ашы

«СӨЕМБИКӘ» ОПЕРАСЫ – ГОРУР РУХ ӘСӘРЕ

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Разил ВӘЛИЕВ

ВӘГЪДӘ

Оҗмах вәгъдә итмим сиңа...
Бик тар әле чикләрем.
Бар байлыгым — җыр-моңнарым
Һәм дә кара икмәгем.

Күкне бирә алмам сиңа...
Йолдызсыз да итмәмен.
Айны бөтен көе саклап,
Сине, ахры, көткәнмен.

Шатлыкларым тулы килеш,
Кайгымны да түкмәдем.
Йортым тәбәнәк булса да,
Биек әле күкләрем.

Бәлки, бәхетле булмассың...
Бәхетсез дә итмәмен.
Оҗмах бирәм димим сиңа,
Тәмугка да кертмәмен.

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Алия ханым. 1968 ел.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2018

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

9’2018



Фото: Ксения Богданова

Җитәкче-баш мөхәррир
Гөлнара Ильяс кызы САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Гөлнора Гатина
Фото: Ольга Лаут

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Чулпан Галиәхмәтова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 2.08.2018 ел
Заказ Е-2251
Тираж 4916

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА

Көзге моң

Көзге моңны кем ишетте микән бүген?
Талгын очкан пәрәвезләр ишеткәндер.
Кояш исә, безгә сибәр нур җыйганда,
Яфракларның көләчләрен иш иткәндер.

Иш иткәндер гөлләрнең ул
елмайганын,
Горур, биек тауның ап-ак түбәлесен
Һәм мәчетнең болытларга тигән аен,
Кешеләрнең нурлы йөзен үбәр өчен.

Мин уйланып калдым
шушы яктылыктан,
Кояштан да, күнемнән дә нур алганда.
...Көзге моңны
мин ишеттем кебек бүген,
Чәчемә чал пәрәвезләр уралганда.



Фото: Анна Арахамия









БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА 

ДАЛА КЫЗЫ КАЙТА КАЗАНГА
Ландыш Әбүдәрова
26



ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ 



6

«АНА ТЕЛЕ» – ӘНИЛӘР ВӨҖДАНЫНДА
Чулпан Галиәхмәтова, Лилия Гәрәева

18



«БӘХЕТЛЕ БУЛМЫЙ КАРА...»
Гөлнур Сафиуллина

14



ДОУЛА
Гөлнур Хәсәншина

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ 

22



МОРЗА КЫЗЫ
Ландыш Әбүдәрова

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34 ҮЗ КОЯШЫМ ЧЫКМАС ДИМӘ... Роза Сабирова

ЯШӘЕШ 



42 ИРЛӘРНЕ ҖӘЛЛӘРГӘ ЯРАМЫЙ Чулпан Галиәхмәтова



50 ЗАНЗИБАР Раушания Полосина-Сөләйманова

ШУЛАЙ УК: 

10 ГАҖӘЕП БАЛАЛАР ЯКИ АТЫЛГАН ЙОЛДЫЗЛАР Чулпан Галиәхмәтова

46 АЗГЫННАР Мәдинә Авзалова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



60 ҮСЕМЛЕК СӨТЕ

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

ТЫНЫЧ ЙОКЛА, КЫЗЫМ. ДАНИЯ НУРЛЫ. АЧЫКТАН-АЧЫК СӨЙЛӘШӘБЕЗ

ИЯРТЕП КИЛГӘН БАЛА. ЯҢА ӘТИГӘ КЕМ УЛ

«СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР». НУРИХАН ФӘТТАХ. ӨЗЕК

ПӘЙГАМБӘР БАСКАН ЭЗЛӘР. МИН АЧКАН ДӨНЬЯ





«АНА ТЕЛЕ» – ӘНИЛӘР ВӨҖДАНЫНДА

БАЛАНЫҢ ТУГАН ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮ-ӨЙРӘНМӘВЕН ХӘЗЕР БЕЗ, ӘТИ-ӘНИЛӘР, ХӘЛ ИТӘЧӘКБЕЗ. МИЛЛӘТ КИЛӘЧӘГЕ БЕЗНЕҢ ҖАВАПЛЫЛЫККА КҮЧТЕ. РОССИЯДӘ «МӘГАРИФ ТУРЫНДА» КАНУН КАБУЛ ИТЕЛЕП, ТУГАН ТЕЛЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ РӘСМИЛӘШТЕРЕЛЕП, БЕР КАЛЫПКА САЛЫП КУЕЛДЫ. УЛ 1 СЕНТЯБРЬДӘН ГАМӘЛГӘ КЕРДЕ.

Каш ясыйбыз дип күз чыгара яздык. Мәктәпләрдә туган телне өйрәнү мәсьәләсенә әнә шул татар халкы мәкале бик туры килә. Дәресләр санын арттыру, катлаулы уку әсбаплары Тукай телен яратмауга китерде. Бәлки, татар телен илаһилаштырып, башка милләт балаларына ботка кашыгы белән «тел ашату» да зур ялгышлык булгандыр. Ни өчен шушы чиккә җиттек соң? Чөнки мәгариф буенча федераль стандартлар камил түгел иде. Әгәр дә ФГОСТта төгәл итеп республика дәүләт телләрен өйрәтү методикасы язылган булса, уку-укыту әсбаплары, программалар тиешенчә кабул ителгән булыр иде. Илнең мәгариф министрлыгы эшләп бетермәве аркасында, аңлашылмаучылыклар туып, бөтен гаеп мәктәп директорлары, укытучылар җилкәсенә өеп калдырылды. Шуннан тиз арада федераль күләмдә мәгариф турындагы канун кабул ителде. Анда рус телен дәүләт теле буларак мәктәпләрдә өйрәнү гарантияләнсә, Россия халыкларының туган телләрен өйрәнергә теләгән очракта, укучыларның һәм аларның ата-аналарының язма гаризасы кирәк булачак дип язылган. Шунысы да мөһим: ана телен өйрәнүгә сәгатьләр урыс теле хисабыннан булырга тиеш түгел. Димәк, Татарстанда татар теленең киләчәге өчен рәсми рәвештә ата-аналар җаваплы булып калды.

Кулга каләм алып гариза язганчы, уйланырлык урын бар. Без кем? Тамырыбыз кайдан? Глобальләшү шаукымына ияреп татарлыгыбызны онытып җибәрмибезме? Дөнья белән бергә атлау яхшы анысы. Тик глобальләшүнең икенче ягы да бар – телне, нәсел тарихын оныткан маңкортлашу. Бу хакта уйламыйча, хәзерге заман мәктәпләрендә бала һәм безнең алда торган төп максат – бердәм дәүләт имтиханнарыннан кételгән нәтиҗәгә ирешү өчен генә телгә хыянәт итмибезме? Әйе, республика мәгариф системасы, үзе дә аңламыйча, милләт төшенчәсен онытып җибәреп, барлык мәктәп укучыларына татар теленнән имтихан бирүне мәҗбүриләштереп, туган телен яраткан, тик белем дәрәҗәсе бик түбән булганнар сафын да киметте.

Тукай телен өйрәнергә авыр дигән глобальләшкән татар гаиләләре бар. Бу – бүген бала үстерүче әти-әниләрнең үз ана телләрен җуеп бетерү нәтиҗәсе. Шунысы куанычлы, мин белмим, балам белсен дип уйлаучылар да юк түгел. Казанда яшәүче Ульяна белән Алексей Зевакиннар бердәнбер уллары Кириллны милли рух белән сугарылган Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясенә укырга бирәләр. Алексей үскәндә, мәктәпләрдә Тукай телен татар балалары гына укый. «Хәзерге акылым булса, мин дә аларга ияреп йөргән булыр идем», – дип үкенүен яшерми. Улы белән бергә махсус сүзлекләр төзеп, тел өйрәнәләр. «Хәзер саф татарча барган ата-аналар җыелышында бар нәрсәне аңлап кайтам», – ди. Телләр белү баланың гомуми үсеше өчен файдалы, берсе дә артык була алмый дип саный ата. Татар телен белү сибелеп таралган төрки телле халык белән аралашуга юл ачуын да аңлый. Кириллга татар мәктәбендә беренче ике ел бик авыр була. Дәрестә генә түгел, тәнәфесләрдә дә интегә ул. «Башка мәктәпкә бармыйм», – дип кайта кайчак. Бәлки, кирелә-неп, ташлаган да булыр иде. Тик әтисе, күршеләре, аларның уллары Фәнис ярдәме белән татар мохитенә кереп китә ала. Инде мәктәп тәмамлар вакыт җитә. Киләчәктә үзен муниципаль менеджмент өлкәсендә күрә. Татарстанда эшләгән җитәкчеләргә ике

ФИКЕР



Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопарк директоры Антон ГРАЧЕВ

Мин Ижау шәһәрендә туып-үстем. Әти-әниемнәр өйдә татарча сөйләшмәделәр. Шуңа күрә билгеле бер яшькә кадәр татар теле минем өчен бары тик әни теле генә булды. Мәктәптә укый башлагач, каникуллар вакытында еш кына авылга әбигә кунакка кайта идем. Ул русча белми, мин – татарча. Аңлашырга тырыштык. Шул рәвешле, татар теле минем тормышка әби аша килеп керде. Башта тел туганнар белән аралашу өчен генә кирәк дип саный идем. Соңрак мин аңа карата мөнәсәбәтемне үзгәрттем. Хәзер ул мин аңлаган һәм бераз сөйләшә белгән генә тел түгел, ә бәлки бер үзенчәлекле өлешем, ата-бабаларымның төсе! Гади генә «рәхмәт» сүзен әйткәндә дә тарихны үзем аша кичерәм кебек. Тормыш иптәшем – татар кызы. Әле аның ниндие! Туган тел буенча олимпиадаларда җиңүче. Без өйдә еш кына татарча сөйләшәбез. Миңа әле аннан бик күп өйрәнәсе. Камиллеккә чикләр юк диләр бит.

Өйдә балалары белән ана телендә сөйләшмәгән татар гаиләләренә бик аптырыйм. Бөтен кешене бары бер телдә генә сөйләшергә мәҗбүр итеп, тамырларны оныттыру заманнары узды. Хәзер узган гасырда юкка чыгарылган кыйммәтләрне барлау чоры: үз традицияләреңне хөрмәт итү, нәселең белән горурлану, гаиләгә ана телен кайтару өчен мөмкинлекләр тудырылган вакытта яшибез. Туган телеңне үзең белмәсәң, балаларыңа өйрәтү зарур. Киресенчә булган очракта тарих онытылачак. Иманым камил, ата-бабалар моның өчен безне гафу итмәячәк!

Фото: www.pixabay.com

PRESSA

телне дә белү зур өстенлек ләбаса. Кирилл: «Мин мәктәпкә рәхмәтле», – ди. Тел өчен генә түгел, әхлакка, тәртипкә өйрәткәне өчен дә...

Рус мәктәпләрендә укучыларның ата-аналары да узган кыш ике лагерьга бүленде. Берәүләр: «Безгә артык тел кирәкми, бала башын катырмыйбыз», – дисә; икенчеләре баласына татар телен өйрәтүне сорап тыныч кына гариза язды. Кызым укыган гимназиядә соңгылар арасында рус милләтеннән булган әниләр күбрәк тә иде. Зыялы ата-ана баланың киләчәген уйлап эш йөртә шул.

«Татар телен белмәү кыенлыгын мин үземдә татыдым», – ди Татьяна Орманова. Мәктәп тәмамлап, техникумга укырга керә ул. Ә анда татар телендә сөйләшүчеләр күп була.

– Тәнәфес вакытында коридорда кызлар татарча сөйләшкәндә, яннарында авызыма су капкан кебек басып тора идем, – дип искә ала. – Алар сөйләшәләр, көлешәләр – бернәрсә аңламыйм. Миннән көләләрме, үтеп барган егеттәнме? Бик уңайсызлана идем.

Техникумда ныклап татар телен өйрәнә башлый ул. Теләге булса, кеше тау да күчерә. Татьяна да, акцентым бар дип уйлап, сөйләшергә кыенсынса да, кызлар сөйләгәнне аңлап, әңгәмәгә кушыла башлый. «Минем кызым Татарстанда яшәп, ник татар телен белмәскә тиеш?! Киләчәктә һөнәре буенча тел белергә кирәк булса, минем кебек уңайсызланып яшәрме?» – ди ул. Кызын җәйгә берәр татар авылына җибәрергә дә хыяллана. Арина да татар теле дәресен авыр йөк итеп кабул итми. Өйрәнергә теләге зур. Балалар шул. Аларга юнәлеш бирергә генә кирәк. Оясында ни күрсә, очкынында шул булыр, дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр аксакаллар. Өйдә корылган мөнәсәбәтләр мәктәпкә генә ияреп бармый, ә баланы гомере буе озата бара.

Тукай телен өйрәнүгә киртә булган зур мәсьәлә дә чишелә. Дәреслекләр камилләшә башлады. Республика мәктәпләрендә «Сәлам» проекты кертелде. Анда тел аралашу өчен уен формасында өйрәтелә. Ә бит телнең иң зур функциясе дә – мөгамәлә булдыру. Аны башлап җибәрү дә зур психологик киртә. Грамматик нигезләрне өйрәнүгә артык күп игътибар биреп, аны тагын да катлауландырдылар. Сөйләм теле тәҗрибәдә камилләшә!

Ананың балага иң зур бүләге – тел. Кечкенә кызымны балалар бакчасына илткәндә, бер татар баласының әнисенә «мама» дип эндәшүен ишеткәч, сорамый түзә алмадым.

– Ник «мама», «әни» түгел?

– Рус телен камил белмәгәнгә хурландым. Балам да оялмасын, кечкенәдән өйрәнсен, – ди ханым.

Шуның өчен «мама»га да әйләнергә риза. Соңыннан ул «даваника» булачак. Шулай дәвам итсә, тел дә, мәдәният тә, хәтер дә, шәхес үзе дә югалачак – ә болар тәрбиянең төп нигезләре. Дәүләт ярдәме генә түгел, милли үзаңыбыз булганда гына, безнең буыннар чылбыры өзелмәячәк, нәсел дәвам итәчәк. Ә бу – кешенең җирдәге иң төп миссиясе.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

ФИКЕР



Казан шәһәренең 180 нче гимназиясендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «Сәлам» укыту проекты авторларының берсе – Рөстәм БӘХТИЕВ
.

Татар телен укытуга каршы ата-аналар укыту методикасының гаять катлаулы булуын, сүз запасы булмаган балаларга грамматика укытылуын төп аргумент итеп китерә иделәр. Дәреслекләрнең катлаулылыгын укытучылар үзләре дә инкарь итми. Бүген татар теленнән яңа – бөтенләй башка алымнарга корылган дәреслекләр әзерләнә. Шуларның берсе – «Сәлам» дәреслеге.

– Әлеге проект 2016 елда Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы инициативасы белән башланып китте. Дәреслекнең авторлары – мәктәп укытучылары үзләре. Авторлардан тыш, командада методистлар, редакторлар, рәссамнар да, дәрестә кулланылачак видеоматериаллар әзерләүче видео-төркем дә бар.

«Сәлам» уку-укыту әсбабы яңа форматта, балалар өчен кызыклы контент белән заманча технологияләр – аудио, видео кулланып әзерләнде. Төп игътибар сүзләр өйрәнүгә, телне куллану күнекмәләре бирүгә юнәлгән. Ул уеннар, җырлар, әкият геройлары аша башкарыла. Балалар турыдан-туры грамматика өйрәнми, ләкин ул укучыга мисаллар нигезендә җайлы гына сеңдерелә. Әйтик, тартымлы исемнәрне өйрәнгәндә бала уеннар, җырлар ярдәмендә сүзләрне дөрес төрләндерергә өйрәнә.

Узган ел беренче һәм икенче сыйныфлар өчен әзерләнгән дәреслекләр Казан мәктәпләрендә инде сынау узды. Беренче сыйныфлар өчен дәреслек биш мең тираж белән басылып чыкты. Быел икенче класслар өчен басылачак.

Әлеге әсбап балаларга гына түгел, әти-әниләргә дә ошый. Дәреслек укытучының иреген чикләми. Уен формасы, җырлар, әкиятләр кулланганлыктан, бала ялыкмый, дәрес җанлы, кызыклы уза.

Дәреслекне әзерләгәндә чит телләрне укыту, аеруча инглиз телен укыту тәҗрибәсенә таяндык. Ике ел дәверендә «Сәлам» проекты үзен аклады. Әти-әниләр арасында туган тел дип, рус телен сайлаучылар булса да, күпчелек татар телен сайлады. Һәм алар арасында рус милләтеннән булган балалар да күп. Бала бит ул милләтче түгел. Матур дәреслек тоттырып, кызыклы итеп укытсаң, ул теләсә кайсы телне бик рәхәтләнеп өйрәнә.

ТЕЛӘК БУЛСА...



Политолог, блогер, журналист Руслан АЙСИН

■ Күпләр телне аралашу коралы дип кенә фикер йөртә. Теләсә кайсы тел ул аралашу өчен генә хезмәт итми. Ул – дөньяны аңлау һәм мәгънәви яктан чынбарлыкны күзәтү коралы. Дөнья безгә тел аша гына ачыла. Шуның аша безгә дине дә, әдәбияты да, мәдәнияте дә, әхлагы да, тәрбиясе дә керә. Ул милли үзаң формалаштыруның аерылгысыз бер өлеше дә. Телебез белән аерылып тормасак, без башка халыкларга кушылабыз да юкка гына чыгабыз.

■ Без – зур дәүләтләр тоткан, кайчандыр империя булып яшәгән милләт, бер кечкенә генә проблема аркасында үз телебезне саклый алмасак, милләт буларак бик вакланып, тарихи процесска йогынты ясый алмаслык бер төркемгә әвереләбез. Ә бу бит шәхси абруйны да төшерә. Безнең артта бөек тарих, бөек шәхесләр, бөек әдәбият ята. Кол Галиләр чорында хәтта урысның да андый әдәбияты булмаган.

■ Телебезнең дәрәҗәсен күтәрик дисәк, безгә башка халыкларның тәҗрибәсен карарга кирәк. Әйтик, яһүдләрнекенә. Безнең проблемабыз һәм тарихи тәҗрибәбез аларныкы белән уртак. Яһүдләр ике мең ел дәүләтсез яши. Яһүд дәүләте төзелгәч, төп игътибарны үз телләрен торгызуга багышлыйлар. 40 ел эчендә иврит телендә сөйләшүчеләр 20 проценттан 60 процентка җитә. Уңышларының сере – мотивация. Яһүд телен өйрәнгән кешеләргә алар стипендия түли. Ә яхшы укучыларга Израильгә барып ял итү мөмкинлеге бирелә. Казанда да яһүд мәктәбе бар. Баласын анда укытырга урысы-татары да атлыгып тора. Берсе дә, ивритны өйрәнмибез, ул безгә кирәкми, дими. Бу престижлы мәктәптә укыйсың килә икән – өйрәнәсең.

Татар телен өйрәнүләрен теләсәк, без дә шундый татар мәктәпләре ачыйк.

Мәскәүдә андый татар мәктәбе бар. Анда татар теле һәм әдәбияты фән буларак укытыла. Керергә теләүчеләр бик күп. Чөнки анда уку абруйлы санала. Абруйлы мәктәптә татар телен өйрәнү дә комачаулык тудырмый. Язучы Дмитрий Быков бер лицейда әдәбият фәнен укыта. Күренекле кеше укытканга, әлбәттә, мәктәпнең даны зур. Бу тәҗрибәне бездә дә кулланып була бит. Идеяле кеше күп акча да сорамый. Атнасына ике сәгать укытырлык вакытын да таба ала.

■ Заманында татарны мәхәллә системасы саклап калган. Хәзер моны булдыру мөмкин түгел, диярләр. Казанны чолгап алган бистәләрне карагыз сез, анда күбесе татарлар. Җирле үзидарәләр нигезендә бик күп әйберләр эшләргә була. Законга каршы килми ул.

Тагын бер вариант – экстерриториаль мәхәллә кору. Кайдадыр бергә җыелып, татар мохите тудыра алабыз. Казанда җиде район, аларның һәрберсендә дә мәдәният йортлары бар. Шушында бер татар китапханәсе, балалар өчен түгәрәкләр, аралашу мәйданчыгы – әнә шундый мохит булдырып булмыймы? Паркларда да татарлар җыела торган мәйданчык ачарга мөмкин. Моны эшли алырдай актив яшьләр бар. Әллә кайдан эзләп тә йөрергә кирәкми. Әйтик, «Сәләт» оешмасы. Ул яхшы оештырылган, республиканы гына түгел, бөтен татар дөньясын колачлый. Яшьләрнең милли үзаңын үстерүдә ул да зур ярдәм була алыр иде.

■ Милләтнең сәяси лидерлары, идеологлары урам буйлап акча эзләргә тиеш түгел. Фикер ияләре көндәлек проблемалар белән мавыкса, аларның энергиясе башкага китә. Роман Абрамович берничә ай элек 20 ел дәвамында яһүд оешмаларына 500 миллион долларлык ярдәм итүе хакында мәгълүмат чыгарды. Татарстанда татар эшмәкәрләренең меңәр кешелек форумнары уза. Чит төбәкләрдән килгәннәре Татарстаннан ярдәм сорыйлар, республика базарларына керәселәре килә. Аларга булышырга кирәк, ләкин бер шарт белән: без сезгә булышабыз, ә сез үзегездәге татар мәктәбенә булышасыз. Без, мәсәлән, шушы максаттан «Татар фонды»н төзергә алындык. Ул бүген теркәлү уза. Ниятебез – мәктәп укучыларында татар телен өйрәнүгә мотивация уяту.

■ Югары мәктәбе булмаган халыкның киләчәге шикле. Безгә Милли университет бик кирәк. Ләкин аның концепциясе җентекләп уйланылмаган әле. Мин үзем аны Европаның берәр элиталы университетының филиалы итеп күрәм. Шундагы берничә профессорны чакыртып, лекцияләр укытсаң, студентларны чит илләргә тәҗрибә тупларга җибәрсәң, яхшы белем бирсәң, эшкә урнаштырсаң, аның даны бик тиз таралачак. Үзебезнең дә дөньякүләм билгеле галимнәребез бар. Аны хәтта Милли университет дип атау мөһим дә түгел. Бөтен фәннәр дә тулаем татар телендә укытылмаска да мөмкин. Иң мөһиме: милли карашлы егет-кызларны туплау – милли карашлы элитаны булдыру. Казакъстан Президенты Назарбаев тарафыннан андый программа булдырылган. «Килашак» (Киләчәк) дип атала ул. Алар сәләтле балаларны чит илдә укыта.

■ Тарихын белмәгәннең киләчәге юк, дибез. Без тарихны беләбез, ә киләчәк турында уйланмыйбыз. Сан ягыннан Россиядә икенче урында торган милләт булсак та, сыйфат ягыннан аксыйбыз – милли үзаң югарырак булу кирәк.

■ Тагын бер проблема – татар юристларының булмавы. Милли телләр белән бәйле проблемалар тугач, чит төбәкләр бездән ярдәм сорады, ә Татар конгрессында аларга ярдәм итәрдәй юристлар командасы юк. Татар мәктәпләренең уставларын әзерләргә кирәк. Мәктәпләр – автоном учреждениеләр, алар устав белән эшли. Юристлар булмау сәбәпле, без ул механизмны куллана алмыйбыз. Безнең ике корал бар – хокукый һәм мәгълүмати кораллар...

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.



ГАҖӘЕП БАЛАЛАР ЯКИ АТЫЛГАН ЙОЛДЫЗЛАР



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПТӘН ГЕНӘ БАШЛАНМЫЙ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАНДА. БАЛАНЫ БИЛӘҮДӘ ЧАКТА УК ГЫЙЛЕМГӘ ӨЙРӘТҮ МОДАСЫ ХӨКЕМЛЕК ИТӘ.

2 яшьтә – укый, 3 яшьтә яза белгән, 4 яшьтә мәктәпкә үк илтеп утыртырга әзер кебек безнең балалар. Һавалы ата-аналарның хыялы шул ул – вундеркиндлар. Ә ул хыял артында нәрсә ята? Бу хакта уйланырга теләк тә юк, вакыт та җитми. «Минеке иң яхшысы булырга тиеш!»

Вундеркинд сүзе немец теленнән «гаҗәеп балалар» дип тәрҗемә ителә. Гадәттә, вундеркинд дип нинди дә булса бер өлкәдә сәләте белән аерылып торучыларны атыйлар. Сәләт – билгеле бер акыл эшчәнлеген гамәлгә ашырырга этәрүче шәхси үзәнчәлек. Статистика буенча, 50 баланың берсе уртача сәләтле, меңнән берсендә югары сәләт булса, даһилар миллионга бер генә туа. Талант 5 яшьләргә 50–60% беленсә, 8 яшьләргә тулысынча диярлек ачыла. КФУ доценты, танылган психолог һәм психотерапевт Рамил Гарифуллин аңлатуынча, вундеркиндлар яшьтәшләреннән аермалы буларак, акыл ягыннан тизрәк үсеш алалар, тик кайберләре билгеле бер яшькә җиткәч, үсеш тукталып, гади балаларга әйләнә. Алар арасыннан бик сирәк очракта даһилар да чыга. Кешелекне алга җибәрү өчен бу балаларга акылны табигать бүләк итә. Тик аның никадәр кыйммәт икәнен алар үзләре генә белә торгандыр. Нигездә, бер юнәлештә артык сәләтле бала башка өлкәләрдә калыша. Вундеркиндны башында күп нольле

саннарны тапкырлап-бүлүче бик җитди сабый дип кенә күзаллау хата булыр иде. Талант төрле яклап ачылырга мөмкин. Интеллектуаль сәләтлеләр – бик күп мәгълүматны тиз арада отып алучылар, психомотор вундеркинд – физик яктан тиз өлгерүчеләр, социаль сәләткә ияләр, яшьтәшләрен генә түгел, зурларны да үз артларыннан ияртүчеләр. Үзсүзле балалар белән бутамаска! Алар тиз аралашучан, лидер сыйфатлары булган бик сөйкемле сабыйлар. Музыка, рәсем белән «җенләнгән» иҗади сәләткә ияләре дә бар.

«Аю да аппагым, керпе дә йомшагым» дигән кебек, бик күп ата-аналар үз балаларын нинди дә булса даһи талант иясе итеп күрә һәм ул сәләтне үстерү өчен бөтен тырышлыгын куя. Чутлап бетергесез акча түгәргә дә әзер. Ярый ла сабыйның да теләге булса! «Минем балам башкалардан акыллырак булырга тиеш» дигән һавалы уйларын чынга ашырырга теләп, мәктәпкә кергәнче үк уку программаларын үзләштерәләр. Ә бу тәрбия җимеше исә урталык таба алмый интегә. Яшьтәшләре белән аңа кызык түгел, ә зурраклар аны җитди кабул итми, хәтта ул балага карата хөсетлек туарга да мөмкин. Ә моның сабый күңелендә нинди эз калдыруын, кызганыч, киләчәк кенә күрсәтә.

Сәләт – зур йөк

Тарихка күз салсак, вундеркинд балаларга мода СССР вакытында туа. Ул чор сәясәте буенча, бөек милләтләрнең балалары башкача булырга тиеш тә түгел! Совет иле вундеркиндларының язмышын бөтен дөнья күзәтә. Тик аларның тормышы бер дә кызыгырлык түгел шул. Ул елларда совет һәм чит ил матбугаты Паша Коноплевның акылга сыймаслык сәләтенә дан җырлый. Ул 3 яшендә авыр математик биремнәрне чишә. 5 яшендә үзлегеннән пианинода уйнарга өйрәнә. 8 яшендә физиканы су урынына эчкән Паша 15 яшендә университетка, 18 яшендә аспирантурага керә. Якты киләчәк көткән яшүсмернең көннәрдән бер көнне психикасы бирешә. Үз-үзенә кул салыр хәлгә җиткән Пашаны туганнары психик авырулар сырхауханәсенә яткырырга мәҗбүр була. Ул, аннан чыга алмыйча, 29 яшендә вафат була.

Узган гасырның 80 нче елларында танылган тагын бер бала – Полина Осетинская. Зур осталык белән пианинода уйнаган кызчык 6 яшендә ил буйлап гастрольләрдә йөри. 8 яшендә яттан 30 сәгатьлек музыкаль әсәрләр уйнаган Полина үсмерлек чорына җиткәч, өеннән чыгып кача һәм журналистларга сәләтенең «серен» ача. Баксаң, гаилә таркалып, кызны үзенә тәрбиягә алган әтисе бала чакта кулын имгәтә, шунлыктан профессиональ пианист була алмый кала. Хыялын кызына күчереп, аннан даһи музыкант ясарга карар кыла. Кызга исә сәләт мыскыллаулар һәм даими җәзалаулар аша бирелә. Күптән түгел Осетинская әтисенең тәрбия «алымнарына» багышланган китабын чыгарды.

Сәләтле балаларның язмышы, нигездә, фаҗигале тәмамлана. Аларның үз талантларыннан башлары әйләнә, йә акыл үсеше тукталып, «гади кеше» дәрәҗәсенә төшү хурлыгын күтәрә алмыйлар. Араларында бәхетлеләр бик сирәк. 11 яшендә Мәскәү техник университетына укырга кергән Савелий Косенко шул ук яшьтә физика фәне буенча дәреслек язып, Гиннесс рекордлар китабына эләгә. Дөрес, әнисенең дә өлеше зур була. Ике югары техник белеме булган ана баласын бишектә чакта ук укырга-язарга өйрәтә. Хәзерге вакытта Канадада компания башлыгы булган Савелий балачагын искә төшерергә яратмый. Ул укуда «тиз алдыру»ның мәгънәсез булуын таный. «Даһи балаларның дуслары юк, аларга кырын карыйлар, ә иң мөһиме: бәхетле һәм бер кайгысыз вакытларын югалталар», – ди боларның барысын да үз җилкәсендә татыган вундеркинд.

Вундеркиндны башында күп нольле саннарны тапкырлап-бүлүче бик җитди сабый дип кенә күзаллау хата булыр иде.

Даһимы, уңышлы кешеме?

Сәләтле балаларның фаҗигале язмышы өчен ата-аналар җаваплы. Ничек тәрбиялисең бит баланы! Казанда яшәүче Саша Мишагинны әнисе Юлия гап-гади бала итеп кабул итә. 6 яшендә башында триллионнарны бүлеп тапкырлаган, интеграллар таблицасын ятлаган улын вундеркинд дип санамый.

– Мин Сашаны биләүдән төшүгә үк төрле түгәрәкләргә алып чапмадым, – дип сөйли Юлия. – 5 яшендә генә санарга өйрәттем. Үзем гуманитар өлкәдә эшләгәч, аңа гел китаплар укыдым. Ә ул уенчык касса белән уйнарга яратты. Бер көнне аның шул уенчыкта санауга мөкиббән китеп утырганын күреп алдым. Бераз өйрәтеп тә алгач, ул анда 16 мең төрле саннар эзлеклелеген санап чыгарды. Мин улым белән кечкенәдән үк үз күреп, зурларча сөйләшәм. Аңа бервакытта да «җу-җу», «мәм-мәм», «пи-пи» дип әйткәнем булмады. Сәләтен күреп, математика серләренә баганалап тапкырлауны төшендерүдән башладым. Соңрак Сашаның саннарны күрү белән үк истә калдырганын да аңладым. Ул шул рәвешле квадрат, куб, интеграллар таблицасын ятлады. Ниндидер максатлар куеп, көчләп өйрәтмәдем, кызыксынуын күреп, аңа ярдәм генә иттем...

Бала көннәр буе санап кына утырмый. Ул тыңларга ярата. «Сәгатьләр буе сөйләсәң дә, авызын ачып тыңлаудан туктамый», – ди әнисе. Гуманитар өлкәдә эшләгән Юлия бар белгәнен улына сөйли, белмәгәнен аның белән бергә өйрәнә.

– Киләчәктә Сашаны кимчелеклелек комплекслары булган даһи математик итеп күрәсем килми. Шуңа да гыйлемне төрле яклап бирергә тырышам. Тарих, география, әдәбият дөньясы белән таныштырам. Ә Саша барысын да отып бара. Хәзер, математикадан бераз читкәрәк китеп, иҗат белән шөгыльләнә башладык.



■ Исәпләү җиһазы алып биргәч, кечкенә математик ярты ел буе аннан аерылмый. Саша сәләтле балаларга багышланган федераль каналларның тапшыруларында катнашып, бөтен ил халкын да шаккаттыра.

Бар нәрсәне тиз отып алуы Сашага озын шигырьләр ятларга ярдәм итә. Ә ул аларны эмоцияләрен кушып, артистларча сөйли. Шигырь сөйләүчеләр бәйгесендә катнашып, шәһәр буенча призлы урыннар яулады, концертлар да алып бара. Укытучылары мактап туя алмый, Сашага исә сәхнә ошый...

Бәхетле балачагы булган кеше, үскәч, иртәме-соңмы, уңыш казанмый калмый ул.

Әнисе дә канәгать: улы кешеләр белән мөнәсәбәт корырга өйрәнә. Юлия улының сәләтенә табынып яшәүче әниләрдән түгел, тиешле урында тәнкыйтьләп тә ала.

КИҢӘШ

Күпьеллык тикшеренү мәгълүматларына караганда, балаларның 5% ы даһилык чаткылары белән туа. Тик йөздән берсенең генә сәләте ачыла. Сабыйдан даһи кеше үстерү мөмкинлеге бик аз, шулай да сынап карарга була. Моның өчен үзенчәлекле билгеләре булган баланы аера белү мөһим. Даһи балада булган сыйфатлар:

- ул яшьтәшләре белән аралаша алмый, күбрәк өлкәннәргә тартыла;
- бик кызыксынучан һәм бу сыйфат еллар үткән саен көчәя генә;
- яңа һөнәрләргә мөстәкыйль рәвештә өйрәнә (санарга, укырга, рәсем ясарга);
- һәрвакыт камиллеккә омтыла;
- эмоциональ яктан тотрыксыз;
- бары тик бердәнбер яраткан шөгыленә генә өстенлек бирә;
- кече яшьтән үк сәбәп-эзлеклелек бәйләнешен кора белә.

4-5 яшькә кадәрге балагызда әлеге сыйфатларны күрсәгез, озакка сузмыйча белгечкә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Тәҗрибәле балалар психологы, йә гыйлемле укытучы баланың акыл үсеше дәрәҗәсен билгеләп, нормадан күпмегә артык булганын әйтә алачак.

– Бәлки, мин таләпчән әнидер, әмма башкарылган эш камил булырга тиеш. Моңа исә ялкаулык һәм замана чире булган гаджетлар комачаулый. Сашаны әлегә смартфон, компьютер уеннарыннан коткарып кала алдым. Билгеле, «ярамый» сүзе белән генә түгел. Аларның зыянлы икәненә үзенең төшенүен телədем. Баш мие төзелешен, аңа компьютер уеннарының тәэсирен өйрәндек. Ул хәзер «компьютер уйнаганнарның баш мие тавык түшкәсе кебек тип-тигез, ә китап укыганнарныкы матур: сырлы-сырлы» дип уйлый. Мин мәгълүматны балага төптән аңлатып бирү ягында. Сөйләшүдән соң, аңа уйларга урын калдыру мөһим. Ә «юк» һәм беттекитте – шуның белән нокта куелды түгел инде...

Сүз дә юк, Сашага Аллаһы Тәгалә сәләт биргән, күпкырлы гыйлемле булуы исә әнисенең тырышлыгы нәтиҗәсе. Өйдән торып эшләгән ана, бик күп вакытын балага багышлый. Дөрес, театр түгәрәге белән шахмат секциясеннән кала, башка популяр белем бирү үзәкләренә дә йөртми. Бары тик үзе генә бар нәрсәне, хәтта тормыш кагыйдәләрен аңлата. Быел Саша беренче сыйныфка укырга бара. Мәктәптә «биш»легә генә укуны да, киләчәктә Нобель премиясе алуны да максат итеп куймый. Бар хыялы – трамвай йөртүче булу. Математика нигә кирәк булачак дигән сорауга да җавабы гап-гади: «билетны да үзем сатачакмын».

Кечкенә вундеркиндка – күп вакыт

Вундеркиндларны яшьтәшләре үсештә куып тота икән, моның өчен кайгырасы юк. Статистика буенча, аларның 8% ы гына даһи була. Алар инде, алда язганымча, кешелек үсешен дәвам иттерүчеләр. Аллаһы Тәгалә иңнәренә зур йөк салганнарның бәхетле тормышы турында бернинди статистика алып барылмый. Шунысы билгеле, аларның гомере гади кешеләрнекеннән 10–15 елга кыскарак.

Дөньяга килгән сабыйны ничек бар шулай кабул итеп ярата белү мөһим. «Табигать интеллектуаль яктан камил бала бирә икән, бу ата-анага тагын да җаваплылык өсти», – ди Рамил Гарифуллин.

– Вундеркинд балаларга табынып яшәү – ата-ананың зур хатасы. Мондый баланы да башкалар кебек үк нәрсә начар, нәрсә яхшы икәнен танытып үстерү мөһим. Вундеркиндларга сокланмаска, ә бәлки сәләтен үстерү өчен шартлар тудырырга кирәк. Алардан медиашәхес ясау да ялгышлык. Дан-шөһрәт үсешкә комачаулый. Танылу кечкенәләр өчен генә түгел, өлкәннәргә дә зур сынау...

Шуңа да вундеркиндларны, нигездә, өйдә укыталар. Быел Казан федераль университеты тарихында беренче тапкыр иң яшь студент укый башлады. Ул – Казанда яшәүче 14 яшьлек Лина Мөхәммәтҗанова. Башкаланың бер мәктәбендә белем ала башлаган кызны ата-аналары өйдә укытуга күчерә. Ул Санкт-Петербургтагы мәктәпне тәмамлый. Уку йортына документлар тапшырганда да гаилә журналистлар белән очраштырмауны шарт итеп куя.

– Сәләтле балаларны тәрбияләгәндә аларны уңайлы мохиттә генә яшәтү дөрес түгел. Ихтыяр көчен үстерү

өчен әледән-әле камиллек чикләрен арттырып тору зарур. Һәрвакыт авырлыкларны җиңеп торганнарның гына тормыш кыйммәтләре югалмый. Бу балаларны гыйльми педагоглар кулына тапшыру да аларның киләчәге өчен зур табыш булачак. Психологларга йөртүдән дә читенсенмәскә кирәк. Вундеркиндларда, нигездә, социаль акыл түбән була. Аларга кешеләр белән аралашу, мөнәсәбәтләр кору авыр бирелә, – дип сөйли Рамил Гарифуллин. Санаулар буенча, акыл иясләрендә, гади кешеләр белән чагыштырганда, психик тайпылышлар ешрак очрый.

Сәләтле баламы, һавалы анамы?

Ата-аналарның иң зур хатасы – гап-гади баладан вундеркинд ясарга тырышу. Дөрес, тырышлык – талантның аерылгысыз ярдәмчесе. Тик баланың үй-теләкләре белән туры килү дә мөһим бит әле. Ярый да балага көннәр буе скрипкада уйнау яки саннар боткасында кайнау ошаса. Кайбер яшь әниләрнең максатлары: билөүдән үк укырга-язарга өйрәтеп, күпләрне шаккаттыру. Балаларым белән урамга чыккач, комлыкта уйнаучы сабыйларын күзәтеп утыручы әниләрдән ераккарак алып китәргә тырышам. Аларның сөйләшүе, гадәттә, 2-3 яшьлек балаларын чагыштыруга кайтып кала. «Ике генә хәреф беләме? Без бөтен алфавитны өйрәндек, санау да унга түгел, иллегә кадәр» кебегрәк ярышу ул. Мәктәпкә баргач, яшьтәшләре телләрен чыгара-чыгара квадрат ясарга өйрәнгәндә, ул балага ни кызык кала соң?! Дәрес белән кызыксынуы бетеп, ялкауга чыгарга да ерак калмый. Ә аналар чаң кага: мәктәпкә кадәр бөтенесен белә иде, укытучылар укыта белми!

Ә бу ата-аналарда акча эшләү өчен күпме хезмәтләр булдырылды. Моны куәтләп, федераль каналларда сәләтле балаларның һөнәрен күрсәтүче тапшырулар ясала башлады. Болары – минем кебек әниләрдә кимчелеклелек комплексы тудыручылар. Шәхсән мин андый тапшыруларны караганда үземне баласы белән шөгыльләнмәгән юньсез ана итеп тоя башлыйм. Килешәм, ул тапшырулар итәк-чабуларны җыярга ярдәм дә итә торгандыр.

– Бу тапшыру – шоу. Анда шундый ук балалар, аларның бары тик хәтерләре бик көчле. Ә бу бала үсешен күрсәтүче факторларның бер өлеше генә. Башка юнәлешләрдә күрсәткечләре түбән дә булырга мөмкин. Күбесе нәрсә сөйләгәннәрен аңламый да. Бу – бары тик ата-аналарның тырышлыгы белән даими өйрәтүләр нәтиҗәсе. Бала тормыш хакында фикер йөртә башлагач кына өлгереш чорына керә,– дип аңлата психолог.

Триллион саннар белән «уйнаганы» да, әллә ничә уен коралында көй чыгаручылар да Бала булып кала. Даһимы ул, сәләтлеме, башкалар хәреф өйрәнгәндә кашык тотып ашый белмәгән сабыймы – барысына да бер генә нәрсә кирәк: ярату һәм наз, тирә-ягы тулы уенчыклар булу да комачауламас. Йолдыз атылу – матур мизгел, әлбәттә, тик күктә алар никадәр озаграк балкыса, шуның кадәр күбрәк сөендерә.



Солтания ГАТАУЛЛИНА, психолог:

Хәзерге ата-аналар балаларын кече яшьтән үк укытырга омтыла. Шул рәвешле әйләнә-тирәне тизрәк танып беләчәк дип уйлый. Укыту һәм танып белү яки үсеш – икесе ике төрле төшенчә. Укыту – махсус биремнәр аша нәрсә дә булса эшләргә өйрәтү. Ә үсеш – әйләнә-тирәне шөгыль аша танып белү. Әти-әниләр күбрәк беренчесен сайлый. Чөнки ул алар өчен иң уңайлысы. Бала бишектән төшү белән үк, аны төрле түгәрәкләргә биреп, баш мие эшчәнлеген күнектерә башлыйлар. Әниләр махсус биремнәр аша мәктәпкә әзерлибез дип уйлый. Бу бик зур хата! Баланы читлеккә бикләп, кече яшьтән иреген чикләп, уңай нәтиҗәгә ирешеп була микән?

Нейрофизиологияне, баш мие зоналары үсеше табигатен берәүнең дә үзгәртә алганы юк әле. Һәр яшьтә аның билгеле бер өлешен үстерү зарур. Мәсәлән, 1 яшьтән 3 яшькә кадәр баланың төрле анализаторлар аша тоемлавын, хис-тойгыларын, сүз байлыгын, сөйләмен үстерү өчен уңай. Әгәр шул яшьтә үк балага саннар һәм хәрефләр өйрәтә башлыйбыз икән, баш миенең актив үскән өлешен (нигездә, ул эмоцияләр өчен җавап бирә торган кисәге) тоткарлыйбыз, ул буш булып калачак. Киләчәктә исә ул начар гадәтләр белән тулырга мөмкин. Күз алдына китереп карагыз, бу яшьтә баланың иреген чикләп, мәҗбүри өйрәтү 10 яшьлек баланы җенси якынлык кылырга мәҗбүр итү белән бер дәрәҗәдә психологик җәрәхәт ясауга тиң. Бу киләчәктә психосоматик авырулар китереп чыгара (ашказаны-эчәк, шикәр авырулары). Бала курка башлый, үз эченә бикләнергә мөмкин.

Нормаль үсеш өчен, иң беренче чиратта, әйләнә-тирәне танып белү мөһим. Ул махсус биремнәр, төрле карточкалар аша түгел, ә сөйләшү, аралашу, күзәтүләр аркылы эшләнә. Мәсәлән: бу – песи, аның дүрт аягы, койрыгы, ике колагы, ике күзе, борыны бар, ул йорт хайваны. Гаджетларны читкә куеп, социаль челтәрләрдән чыгып, бала белән сөйләшергә генә кирәк. Әйләнә-тирәне тану иртәдән үк башлана бит: балага ботка пешерәсез. Аның алдына тәлинкә белән смартфон куйганчы әңгәмә кору зарур. Ботканы ничек пешергәнегезне, аның үсәргә ярдәм иткәне хакында эмоцияләр белән кызыклы итеп сөйлисез икән, күз яшьләрсез, мультфильмнарсыз гына да баланы ашатып була. Бала өчен ул әле әйләнә-тирәне тану буенча менә дигән дәрес тә!

PRESSA

ДОУЛА



Фото: www.pixabay.com

«Тулгагым иртәнге биштә башланды. Баладан тиз генә котылмаячагымны белә идем. Элина да моңардан хәбәрдар иде – беренче балам бит. Әмма өчпочмаклар күтәреп озакламый килеп тә җитте. Тулгагым тәмам көчәймичә, бала тудыру йортына бармаска хәл иттем. (Бу әле болай гына, узар дигән өмет тә юк түгел иде!) Доулам килгәнче өйне җыештырырга тырышып карадым, булмады – кул селтәдем. Ишектән керүгә, ул миңа массаж ясарга кереште: тулгак көчәйде. Тулгаклар арасында Элина өемне тәртипкә салырга, иремә кичке аш әзерләп куярга да җитеште! Кичке унберләр тирәсендә җыенып, бала тудыру йортына чыгып киттек. Юлда да, барып җиткәч тә ул гел бил тирәсенә массаж ясап торды. Бер минутка да янымнан китмәде! Су китереп бирде, минем белән бергә сулады, тулгаклар вакытында йөзен чытты, минем белән бергә ыңгырашты, хәлемне белергә теләп өзгәләнгән әнигә төне буе «смс»лар язып торырга да өлгерде... Тулгак ачысы белән чытырдап ябышканда ничек Элинаның кулын сындырмаганмын – улым тугач, моңа шаккаттым! Ике тулгак арасында: «Мин беркайчан доула булмаячакмын! Коточкыч хезмәт ләбаса бу!» – дип уйлаганым истә. Бала табучы хатынны көйләп бетерү өчен нинди сабырлыклар кирәк!
Элина бер тәүлеккә якын янәшәмдә булды. Ул да йокламады, ул да борчылды. Ә балам тугач, миннән артыграк сөенде! Икенче бала алып кайтырга ниятләсәм, янымда Элина булмаса, мин аны ничек табармын?!»
Озынрак булса да, Мәскәүдән, бер танышымнан килгән бу хатны тулысынча китерергә уйладым. «Доула» дигән сүзне ишеткәнегез бармы, шундый яңа һөнәр барлыгын беләидегезме? (Яңа дип... Америка антропологы Дан Рафаэль үзенең тикшеренүләрендә бу терминны инде 1969 елда ук кулланган икән.) Кем соң ул доула, бала табучы хатынга ничек булыша, аның вазыйфалары нинди? Бу хакта без доула Фатыйма ШӘЙДУЛЛИНА белән сөйләшәбез.

Кендек әбисе дисәм, аңлавымча, аңардан да аерыла. Акушер дип тә әйтеп булмый. Психолог кына да түгел. Кем соң ул доула?

– Доула – грек сүзе. Аны «кол хатын» дип тәрҗемә итәләр. Бала табучы хатынның колы, димәк. Күпләр доуланы өйдә бала табарга җөрьәт иткән хатыннарга булышучы дип кенә белә. Һәм шуңа күрә аларга мөнәсәбәт тә үзгәрәк. Юк, доула ул баланы өйдә таптыручы түгел. Ул, гомумән, таптыручы түгел. Аның акушер белән берниди уртаклыгы юк. Доула – әни кешегә бала тапканда ярдәм итүче. Иң якын кеше кебек, бу сәгатьләрдә аңа таяныч, терәк булучы. Куркуларыннан арынырга булышучы, кыюлык өстәүче. Бала табучы хатынның нинди теләге бар – шуны берсүзсез үтәүче. Ул хәтта: «Мин үзем генә калырга телим, син, бар, балаларны кара», – дисә, һич карусыз, бу хатынның өлкән балаларына күз-колак булырга чыгып китүче... Кулыннан сыйпап, иң кирәк сүзләрен табып, аны тынычландыручы... Бала тапкан хатыннар белә: табиб та,

акушер да боларның берсен дә эшләми. Эшли дә алмый, чөнки моңа вакытлары юк – берьюлы берничә хатын бәби табарга да мөмкин кайчак. Аннан бу аларның вазыйфасына да керми.

Бала көткән арада доулалар әзерли торган курсларда укыдым, халыкара мәктәпне тәмамладым. Бала тапканда үземне ничек тотарга өйрәнү өчен кирәк булды болар миңа. Улымны өйдә таптым. Европада гадәти күренеш бу, кайбер штатларны исәпкә алмаганда – Америкада да. Ирем өйдә табуыма каршы килмәде. Әмма үзе ярдәм итәргә дә алынмады – янымда доула булды. (Бөтен ирләр дә доула ролен башкара алмый. Күбесе каушап кала һәм аның куркуы җәмәгатенә дә күчә. Ә бала табучы хатынга бик тыныч булырга кирәк.)

Доула турында укый торгач, үзем өчен яңа бер дөнья ачтым. Мин булачак әниләргә күбрәк мәгълүмати ярдәм күрсәтәм: аларны гыйлем ягыннан баетам.

Булачак әниләрне күбрәк нинди сораулар борчый?

– Күбесенең күңелендә курку бар аларның. «Туганым (танышым) бала тапканда шундый хәл килеп чыкты. Минем белән дә алай булмасын өчен нишләргә?» – диләр. (Үзем дә башка юллар эзләүгә шушы сәбәп аркасында керештем бит. Туганнан туган абыем белән аның хатыны икенче балаларын бик озак көттеләр. Әмма бала туганда ниндидер катлаулыклар килеп чыккан – анысы безгә сер. Җиңгине дә, баласын да коткарып кала алмадылар. Барыбыз өчен дә бик зур хәсрәт булды бу... Әни кечкенә сеңлемне тапканда миңа 16 яшь иде. Инде күп нәрсәне аңлый идем, шуңа күрә табибларның әнигә мөнәсәбәтен дә нык хәтерләп калдым. «Баланың дөньяга килүе башкача да буламы икән?» – дип, шул чакта ук уйлана башладым. Иң авыр хатирәләр белән генә бәйле булырга тиеш түгел бит бу көн!)

Үзебезгә ярдәм итү өчен гап-гади нәрсәләрне белү җитми безгә кайчак. Бала табучы хатынны табиблар гел күзәтеп тора: аналык ничә бармак ачылган, кан басымы күтәрелмәгән яки төшмәгәнме, нарасыеның йөрәк тибеше ишетеләме... Алар шушы саннар белән эш итә. Ә бит бала тапканда хатын-кызның үз-үзен тотышы күпкә мөһимрәк. Бу катлаулы процесста аның гормональ һәм нерв системасы да катнаша. Әгәр хатын-кыз каушый, курка икән – бала тудыру катлаулана.

Бала тапканда окситоцин гормоны бик зур роль уйный. Аны мәхәббәт, ышану, ияләшү гормоны дип атыйлар. Оялчан гормон дип тә йөртәләр. Гипофиз аны хатын-кыз бик тыныч халәттә булганда гына эшләп чыгара: беркем комачауламаганда, тирә-юньдә беркем сөйләшмәгәндә, якты ут янып тормаганда... (Ачыктан-ачык әйткәндә, оргазм вакытында эшләнеп чыга торган гормон ул.) Шушылар ук бала тапканда да кирәк: русча аны «три Т» дип атыйлар (ягъни теплота, темнота, тишина). Кызганыч, бала тудыру йортларында моның берсе дә юк. Хатын-кыз анда берничек тә үзе генә кала, тынычлана алмый. Нәтиҗәдә, «бала тудыру эшчәнлеге сүлпән», дип, аңа ясалма окситоцин кадыйлар. Һәм кинәт көчле тулгак – түзә алмаслык авыртулар башлана. Хатын-кыз организмы авыртуны баса торган гормон – эндорфин эшләп чыгарырга өлгерми. (Окситоцинны үзебезнең организм эшләп чыгарганда, ул әкрен-әкрен генә тәэсир итә – тулгак та әкренләп көчәя бара. Гомумән, бу ике гормон бер-берсен куган ике дулкын кебек: окситоцин тулгакны көчәйтеп җибәрә, аның артыннан ук килеп, эндорфин авыртуны баса.) Аңа авыртуны баса торган уколлар салалар, һәм ул инде көчәнүне сизми башлый – кайчан көчәнергә икәнен белми. Аерылу, «ертылу» шуның аркасында килеп чыга. Болар бала тудырганнан соң булган чорны да катлауландыра: теккән җөйләр яшь әнигә озак вакыт утырырга мөмкинлек бирми... Менә шушы гап-гади нәрсәләрне белсәләр, палатада үзләре генә калуга, һичьюгы утны сүндереп куярлар иде. Ә алар, киресенчә, ялгыз калырга курка, гел яннарына кемнедер чакыралар, үзләрен карап торуны таләп итәләр. Нәтиҗәдә, бала табу коточкыч авыртулар белән генә истә кала... Европада өйдәге кебек шартлар тудырылган махсус бала табу үзәкләре бар. Мәскәүдән Балига кадәр дә шундый үзәкләрне эзләп бара халык. (Бала табуга «иҗади якын килүчеләр» инде болар!) Ул үзәкләрдә бала табучы хатынны гел борчып тормыйлар. Утлар сүндерелгән – шәмнәр генә яна. Җылы. Окситоцин гормоны өчен иң кулай шартлар! Бала табучы әни янәшәсендә исә – доула. Ул ананы тынычландыру өчен барысын да эшли. Ә тынычлангач, бала тудыру процессы җиңелрәк бара башлый. Европадагы статистика мәгълүматлары буенча, бала тапканда доула катнашса, баланы ярып алу – 50 процентка, бала тудыру вакытының озынлыгы – 25 процентка, ясалма окситоцин салу очрагы – 40 процентка, ә авыртуны баса торган уколлар ясау 60 процентка кими.

■ Доула һөнәре турында үзем бала көткәндә белдем. Без ул чакта ирем белән Берләшкән Гәрәп Әмирлекләрендә яши идек. Көнбатыш илләренең бик күбесендә доула хәтта бала тудыру йортларының штатында ук бар. Булачак әни, табибны, акушерны сайлаган кебек, аны да алдан сайлап куя ала. Доула Мәскәү шәһәре өчен дә яңалык түгел инде. Әмма Казанда бала табучы ана янына әлегә бары тик якыннарын – ирен, әнисен, апасын яки сеңлесен генә кертәләр. Тик бездә дә тиздән бу күренешкә мөнәсәбәт үзгәрер дигән өмет бар. Ире, әнисе булмаган хатын-кызны дискриминацияләү дә бит әле бу.



Бүгенге яшьләр ана булуга күпкә җаваплырак карый.

PRESSA

Сүз уңаеннан: доуланың махсус медицина белемле булуы мәҗбүри түгел. (Әмма кешенең физиологиясе, бала табу буенча мәгълүматы булырга тиеш, әлбәттә.) Әйткәнемчә, ул бала тудыруда турыдан-туры катнашмый. Хәтта өйдә бәбиләргә хәл иткәндә дә, бөтен җаваплылык хатын-кызның үз өстендә, доулада түгел. Кайчак табиблар белән арадашчы ролен үти, әмма бәхәсләшми, аларга үз фикерен такмый, нидер таләп итми. Аның төп миссиясе – ярдәм итү, бәбиләүче хатынның хәлен җиңеләйтү.

Мин үзем гарәп һәм инглиз телләре укытучысы. Казан федераль университетын тәмамладым, балалар бакчасында эшләдем, мәктәптә укыттым.

Тууга анасының мәхәббәтенә күмелмәгәнгә, кайгыртуын тоймаганга сабыйлар елакка әйләнә дә.

Булачак әниләр сезнең яннан нинди киңәшләргә баеп китә?

– «Бала тудыру йорты ишегеннән ачып кергәндә, сез мәгълүматлы булырга тиеш», – дим аларга. Әни булу – хатын-кыз тормышында җаваплы адым. «Акча түләнгән, табиблар белән сөйләшенгән, алар ярдәм итәчәк, нәрсә эшләргә икәнен әйтәчәк», дип уйлау дөрес түгел. Синең өчен баланы беркем дә тапмаячак. Табиб барысы өчен дә җаваплы, дип әйтү дә шартлы рәвештә генә әйтелә. Табибка гына салынырга һич тә ярамый, әйе, ул үз эшен башкара, әмма әни кеше дә үз хәлен аңларга тиеш. Табибның: «Алай итикме, болаймы?» дигәненә, «теләсәгез нишләгез», димәсен. Бу очракта кайсы хәерлерәк икәнен дә әйтә алсын. Үзенең хокукларын да якласын. Нидер булса, баласын кулына тотып, киләчәктә проблемалары белән ялгызы гына калачак бит ул.

Баладан котылгач, хәлсезләнеп калган хатын-кыз: «Хәзер миңа ял кирәк, ә бәләкәчемне әлегә табиблар карый», – дип уйлый. Яңа туган баланың да әле генә бик зур стресс кичерүеннән күпләр хәбәрдар түгел. Тууга ул моңарчы белмәгән әллә никадәр яңа кичерешләр белән очраша: салкын, суык, тавыш... Аны төреп алып китәләр дә, сабый үз куркуы, үз хәсрәте белән япа-ялгызы кала. Ә бит аңа бу минутларда иң кирәге – ана кочагы, ана назы. (Доула янәшәдә булса, анага озаклап баласын кочаклап утырырга ярдәм итә дә инде.) Һәм әлеге контактның тәнгә-тән булуы бик мөһим. Анада булган микрофлора балага күчәргә тиеш шулай. Бу – аның иммунитетының нигезе.

Чит илләрдәге бала табу үзәкләрендә бала тууга ук кендек җебен кисәргә ашыкмыйлар – соңгылыктан кан агып бетүен көтәләр. Бала тууга киссәң, 30 процент кан соңгылыкта кала, димәк, сабый беренче минутларында ук шулкадәр кан югалта. Олы кеше белән мондый хәл булса, аңа кан салырлар иде...

Яңа туган сабый өчен иң файдалы сөт – угыз сөте. Тудыру йортында исә балага озаклап имәргә дә ирек бирмиләр – сәгатьләп кенә китерәләр. Ә бит ими имү бала өчен, ашаудан бигрәк, әнисе белән бәйләнеш ул. Әниләр үзләре үзгәрмичә, бала тудыру йортларындагы хәлләр үзгәрмәс, мөгаен.

Үземә мөрәҗәгать иткән кызлар белән алар бәби тапкач берничә ай буе аралашып торабыз әле. Сораулары һич кимеми. Хатын-кызга формага кире кайту да бик мөһим бит. Моның өчен берничә ай кирәк әле. Бигрәк тә беренче ике атна, гомумән, кырык көнгә кадәр булган вакыт әни өчен авыр көннәр. Эчке органнары төшмәсен өчен, эчләрен махсус шарф белән бәйләп куярга тәкъдим итәм мин аларга. Эчне күтәртү өчен массаж ясарга да өйрәтәм. Бала тапкан ана күбрәк ятып торырга тиеш.

Кыен, авыр минутларда без бит иң-иң якыннарга гына таянабыз. Доула дөньяга яңа кеше тудыручы әнигә шул якыннарын алыштыра. Хәер, нигә алыштыра дим әле, ул шуларның берсенә әйләнә.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

ФИКЕР



Ильмира ГАЛИМОВА, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш акушер-гинекологы:

– Мин үзем Европада, Америкада булган бу тәҗрибәгә бик уңай карыйм. Бала тудыру процессы бик озак дәвам итә. Кайчакта хатын-кызлар: «Яныма сирәк килделәр», – дип зарланалар. Беренчедән, бер табиб та, акушер да бала табучы хатын янында кизү тора алмый – андый мөмкинлек юк. Икенчедән, килә алмаганга түгел, хатын-кыз әлеге вакытта безнең ярдәмгә мохтаҗ булмаганга да килмибез: ул мониторга тоташтырылган, аппаратлар барысын да хәбәр итеп тора – бәбиләүче хатын һәрдаим күзәтү астында. Ә хатын-кызга бу гына җитми, ул янында да кемдер булуын тели. Доула шушы бушлыкны тутыра да: һәр үтенечен үти, массаж ясый, сулыш алу гимнастикасын искә төшерә... Чит илдә күп доулаларның психология яки медицина буенча махсус белемнәре бар, алар доулалар ассоциацияләрендә әгъза булып тора. Шуның өчен хәтта иминиятләштерү компанияләре дә бу төр хезмәтне таный: алар өчен тотылган чыгымнарны каплый. Безнең республикада да әлеге мәсьәлә өлгереп җитте: акушерлык берлеген доулалар белән таныштыру кирәк. Бер үк изге эштә катнашабыз – дөньяга яңа кеше тууда булышабыз. Доула тормышыбызга кереп китсен өчен (ә ул һичшиксез керергә тиеш!), башта бер утырып аралашу кирәк. Без аларны танып белергә тиеш. Әмма Татарстанда, кызганыч, доулалар әлегә берниндн оешмага да берләшмәгән. Арада бер лидер килеп чыгарга тиештер инде... Булачак әни белән аның туачак сабыен кем кулына ышанып тапшырганны белмичә, сәламәтлекләренә куркыныч янамавына инанмыйча, «Мин – доула», – дип килгән берәүне дә бала тудыру йортына уздыра алмыйбыз. Чынлыкта, берләшсәк, бала табучы хатын-кыз моңардан отачак кына.

«ГАИЛӘ – КОМАНДА УЛ»



Нияз
ИГЪЛАМОВ

Лев Толстойның «Бәхетле гаиләләр барысы да бертөрле бәхетле, бәхетсезе генә – үзенчә», дигән гыйбарәсе миңа һәрвакыт сәер тоела иде. Миңа калса, бәхетле гаиләләр дә үзенчә бәхетле, чөнки һәркем «бәхет» төшенчәсенә үзенчә мәгънә сала бит. Бер пар өчен табигый булган нәрсә, икенчеләре өчен бөтенләй гаҗәп тоелырга мөмкин. Кайчандыр күршедә шундый бер яшь алкоголиклар гаиләсе яши иде: кешегә тимиләр, бәйләнмиләр, яшел еланга әвәслекләрен искә алмаганда, аларның бәхетле гаиләсе фикердәшләр, дуслар дигән тәэсир калдыра иде.

Аббат Прево «Манон Леско»да язганча да була. Яшь һәм бәхетсез Кавалер де Грие җилбәзәк мәгъшукасының хыянәтенә түзәргә мәҗбүр. Манонны беткән хатын дип атау җиңел, ләкин уйлап карасаң, Европа мәдәниятендә бу образның Маргарита Готье, Эмма Бовари, Катерина Кабанова, Настасья Филипповна, Анна Каренинадан йөз елга иртәрәк җенси мәхәббәт һәм яшьли үлем символы булып китүе очраклы булдымы икән? Адәм баласының табигатенә салынган психологик сәбәпләр аркасында, укучы шушы мәхәббәт газапларында бәргәләнүче хатынны кызгана, ә бит бер дә аның лаеклы һәм тугры ирен түгел! Отелло Дездемонаны буып үтерә, ләкин менә биш гасыр инде тамашачы Отелло белән бергә хәсрәтләнә. Верона гашыйклары Ромео белән Джульетта турындагы повесть бөек мәхәббәт тарихы булып санала. Таһир һәм Зөһрә, Ләйлә һәм Мәҗнүн, Галиябану һәм Хәлил... Гарәбтә дә, Шәрыкта да гашыйкларга җәмгыять белән мөнәсәбәтләр кору җиңелдән булмаган. Чөнки теләсә кайсы җәмгыять кеше бәхетенә көнләшеп карый.

Әдәби геройлар дөньясыннан гади кешеләргә күчик. Һәм нәрсә күрәбез? Драматик мисаллар җитәрлек – күрә белгән язучылар гына юк. Ире кыйный, эчә, балаларын кыерсыта, ә хатыны барыбер китми, дус кызларына, яратам, дип елый. Яки ире күтәреп кенә йөртә, ә хатыны аның бөтен дуслары белән йоклап чыгарга әзер. Мондый хәлләр безнең әйләнә-тирәдә азмы? Болары, билгеле, артык күзгә ташлана торган мисаллар. Еш кына бер тапкыр кыйный, бер тапкыр хыянәт итә. Алга таба балалар үстерәләр, ипотека түлиләр, планнар коралар. Читтән караганда, бәхетле гаилә дияргә дә ярый. Ә иң мөһиме: барысы да иҗтимагый мораль кысаларына сыя. Бәхетле диярлек гаиләләр бездә көнләшү хисе уятмый.

Шулай да чын-чынлап бәхетле парлар юкмыни? Әлбәттә, бар, югыйсә гаилә институты күптән ишелгән була иде инде. Ничек бәхетле була ала соң алар?

Алтын урталык, бөтен кешегә дә ярардай бәхет рецепты юктыр ул. Бу фани дөньяда озаграк яшәгән саен, адәм баласы – үзенә генә хас кануннары, физикасы, химиясе булган аерым бер галәм дигән фикергә киләм. Татар гаиләләре, андагы мөнәсәбәтләр дә башка халыкларныкыннан әллә ни аерылмый. Минемчә. Ә ислам, диярсез. Татарлар – җир йөзендәге иң дөньяви халыкларның берсе. Билгеле тарихи вакыйгалар сәбәпле, шәригать татарлар өчен бердәнбер канун булмаган, Россия Империясендә яшәве белән генә дә. СССР турында әйтеп торасы да юк. Ә Советлардан соңгы чорда ислам күпчелек татарлар өчен, яшәү рәвешеннән бигрәк, декоратив җирлек кенә. Никаб кигән татар кызы бер көнне инстаграмга никахыннан фото куя, икенче көнне Урта диңгез ярларыннан ярым шәрә килеш сәлам юллый – көлке бит. Ислам нормалары да көнкүрешкә шартлы рәвештә генә керә. Ихластан инанган кешеләр дә бар. Ләкин мин үзем андый булмадым, булмам да.

Минемчә, бәхетле мөнәсәбәтләр кору өчен партнерларның тигезлеге – иң мөһиме. Интеллектуаль яктан: юкса дәрт сүрелүгә, сөйләшер сүз дә калмаячак. Социаль яктан: миллионер кызы эшче малае белән бәхетле булганны күргән юк әле. Мәдәни яктан: мин Земфираның иҗатына мөнәсәбәтләре туры килмәгән өчен аерылышкан бер парны беләм. Дин, тел, милләт кебек җитдирәк мәдәни каршылыклар турында әйтәсе дә юк. Ләкин ике кеше башта ук тигез мөмкинлекләргә ия була алмый. Тигезлек бирнә түгел, аны лотореяга да отып булмый. Көн саен бер-береңне түбәнсетмичә генә, компромисслар аша гына тигезлеккә ирешеп була.

Тагын бер мөһим нәрсә – үзара ихтирам. Ышаныч. Аңлау. Гафу итә белү. Эгоизмың белән көрәштә шәхес үсеше. Болар барысы да тигезлектән чыга. Интеллектуаль, социаль, мәдәни тигезсезлек икән, нинди аңлашу яки ышаныч турында сүз йөртергә мөмкин?

Гомумән, әлеге мәсьәләләрдә мин аксакал түгел. Кырыкка җиткәндә, хаталарыма абынып кына нидер аңлый башладым. Ихтимал, бу фикерләрем шуның белән кыйммәттер дә – алар коры фикерләүдән генә тумаган, ә тәҗрибә аша килгән. Йомгаклап, гүзәл затларга шуны әйтәсем килә: ханымнар, туташлар, беренче чиратта үзегезне хөрмәт итәргә өйрәнегез, бәһагезне белегез. Теләсә кемгә батып барганда саламга ябышкан кебек ябышмагыз, нидер килеп чыкмаган икән, тормышта, ким дигәндә, тагын бер шанс була әле. Үзегезне түбәнсетергә юл куймагыз, корбан итмәгез. Аллаһ сезне ирләр хисабына үзегезне раслап яшәү омтылышыннан сакласын. Дәү әнием – татарлардан беренче педиатр Суфия Госманова тормышында күп нәрсәләргә ирешкән һәм ярты гасырдан артык бәхетле гаилә корып яшәгән кеше буларак, ир – баш, хатын – муен, дип әйтә торган иде. Муен баш белән дошманлашып яшәми. Һәм истә тотыгыз: ир белән хатын мөнәсәбәтләре – ерак дистанциягә чыгу ул, ләкин ярышка түгел. Ярыш булган хәлдә дә, гаилә әгъзалары арасында түгел. Сез – команда.



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.

«БӘХЕТЛЕ БУЛМЫЙ КАРА...»

Филисә ХӘКИМОВАның тормыш кагыйдәләре



Исемемнең дә «бәхетле» мәгънәдәгесен кушканнар. Җиде буын әби-бабаларым, үзләре туган, яшәгән җиргә – Рыс, ягъни «бәхет капкалары» дигән исем биргәннәр. Шуннан соң бәхетле булмый кара?! **БӘХЕТ ИСӘ АЯГЫМА УРАЛГАН ДА, КАЙЧАК АТЛАРГА ДА ИРЕК БИРМИ СЫМАН.**

Күңелем яктысында төнге ут күбәләгедәй бихисап уйлар уйный. Күч-күч шул туктаусыз хәрәкәт эченнән гомернең иң гамьле, фәлсәфи, хыялый, сагыну-сагышлы мизгелләрен барлыйм. Кагыйдә дигән сүзне бигүк яратмыйм. **ӘММА БИК КҮП КАГЫЙДӘ-КАНУННАР БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛЕБЕЗДӘ, ҖАНЫБЫЗДА УТЫРА.** Кайчак мирас булып, кайчак тәрбия...

Сагыш. Сагыну. Моң. Гамь. Дога. Җир. Күк. Ипи. Су. Ут... Тагын... **ИҢ ЯРАТКАН КАДЕРЛЕ СҮЗ БУЛЫП ТА, ӘЙТӘ АЛМЫЙЧА, БИК ОЗАК КҮҢЕЛДӘ ГЕНӘ РӘШӘ ТӨСЛЕ ТИБРӘНЕП ТОРГАНЫ – УЛ ӘНКӘЙ СҮЗЕ.** «Әни» дип беренче тапкыр 40 яшьтә бик гүзәл кайнанама гына дәштем... «Әткәй» сүзен дә еш әйтә алмадым, чөнки аннан аерым үстем. Быел әткәмә Коръән багышлаттым. Әбекәм белән бабыкамның да чардуганнарын яңарттым.

Әнкәм бу дөнья белән хушлашканда миңа 3 яшь, энем Фәриткә 9 ай иде. Ә өченчебез әнкәй белән китәчәк... 21 яшьлек гүзәлләрдән-гүзәл әнкәм-фәрештәмнең тәне дә, бәгыре дә ут кебек янган. Соңгы сүзе дә ут чәчкән: «Һай, аның җан көйдергеч Филисәсе бар бит әле!» Нигә шулай диде икән? **ҮЗЕМНЕ БЕЛГӘННӘН БИРЛЕ ШУҢА ҖАВАП ЭЗЛӘП АЧЫРГАЛАНДЫМ.** Киләчәктә мин тарыячак шактый авыр сынауларны күзаллапмы икән?

Бабыкам ак җәймәне ача да, әле җып-җылы әнкәбезне безгә күрсәтә. Фәрит: «Әннә!» – дип, ими сорап, аның күкрәгенә сарыла. Ә мин зур: «Тимәгез, уятмагыз, үзе торыр», – дим... Әткәйдән әлерәк кенә откан җырымны җырлап, энемне «юатам». «Биек тауның башларында, / Аерым-аерым түтәлләр. / Без аерылдык – ятим булдык, / Аерылмасын бүтәннәр. / Без хәзер Сак белән Сок кебек бер-беребезне күрә алмабыз инде... **ӘЛЕ БУ ЮЛЛАРНЫ ЯЗГАНДА ДА АНЫ САГЫНЫП САРГАЯМ.**

МИҢА БӨТЕН НӘРСӘНЕ БИШ ТАПКЫР ЧАЙКАРГА, БИШ ТАПКЫР СӨРТЕРГӘ КИРӘК. Әбекәйдән күчкән сыйфат.

КЕШЕДӘ ИҢ БЕРЕНЧЕ ГАШЫЙК ИТКӘН НӘРСӘ – УЛ АНЫҢ ТАВЫШЫ. Илүсә Саттарова килә иде безгә Минзәлә театрыннан. Хәзергә кадәр аның «Сибелә чәчәк» спектаклендә әйтә торган бер җөмләсен хәтерлим: «Минем чәчкәм чит бакчада үскән...» Аның тавыш тәсмере белән ничә йөз мәртәбә кабатлаганмындыр шуны.

Әгәр синең рухыңа, йөрәгеңә, хисләреңә туры килсә, **КАЙВАКЫТ СӨЙЛӘШМӘГӘН КЕШЕНЕ СӨЙЛӘГӘНЕНӘ КАРАГАНДА КҮБРӘК АҢЛЫЙСЫҢ.**

Безнең яшьлек шагыйре Равил Бохараевның «Белый минарет» дигән китабыннан менә бу юлларны үзем өчен язып куйдым әле: «Поделись со мной молчаньем, возьми меня с собой, чтобы поддержать твою лестницу в небо». **КҮККӘ БАСКЫЧ КУЮ ДА, АНЫ ТОТЫП ТОРУ ДА ҖИҢЕЛЛӘРДӘН ТҮГЕЛ.**

ТЕАТРГА ХӘЗЕР ЧАЛБАР ДА КИЕП БАРАЛАР, Ә БЕЗ ИҢ МАТУР КҮЛМӘГЕБЕЗНЕ САЙЛЫЙ ИДЕК. Сәнгать бөеклеге белән очрашу көне бит ул театрга бару.

Язучы турында язарга утырам икән, миңа аның барлык әсәрләрен укып чыгарга кирәк. Шагыйрь икән – шигърияттен белергә. Актер икән – һәммә рольләрен искә төшерергә. Тарихи әйбер икән – тарихның төбенә төшәргә... **ҮЗЕМНЕ ТУТЫРАМ-ТУТЫРАМ, ӘММА АННАРЫ АНЫ БУШАТУ ДА ҖИҢЕЛ ТҮГЕЛ.**

РӘНҖҮ ДИГӘН АВЫР СҮЗДӘН ҮЗЕМНЕ КҮПТӘН АЗАТ ДИП ИСӘПЛИМ.

«Азат хатын»ның редакторы Асия Фәритовна университетка килеп: «Бер талантлы журналист быел безгә килсен әле», – дип сораган. Флорид Әхмәтович Әгъзамов мине язып куйган. Әмма мине телевидение тарта! «Безне кире каккан кеше юк иде әле», – дип, Асия Фәритовна бик гаҗәпләнде шулчак... Әмма вакытлар үткәч, «Сөембикә»гә әйләнеп килергә туры килде. **КҮП ЧАК ШУЛАЙ ӘЙЛӘНГЕЧ ЮЛЛАРДАН ЙӨРИМ МИН.**

КОМПЬЮТЕР КУЛЛАНМАВЫМ ЗАМАННАН АРТТА КАЛУЫМДЫР ИНДЕ.

КҮЗ ЯШЬЛӘРСЕЗ, ҖАННЫҢ ГЫНА ЕЛАП ТОРГАН ЧАКЛАРЫ БУЛА. Шатлыктан да...

Мин – бер хыялый! Заманында кемнәр генә булырга хыялланмадым! Тракторист, геолог, космонавт... Романтика эзлим, әмма беләм: романтика бик зур кыюлык, ихтыяр көче, батырлык таләп итә. Мәктәптә укыганда, ике ел буе миңа Мәскәүдән бандероль белән «Астрономия» дигән журнал килеп торды. Балачак дустым әле дә кайткан саен, көлеп, хыялларымны искә төшерә: «Рәмзилә, мин барыбер йолдызларга очачакмын дисең». Җаныбыз йолдызлардан иңгән ич. Ничек анда очмый кала аласың ди. **ТОРМЫШ БИК КЫЗЫК: ҮЗЕҢ ҮТИ АЛМАГАННЫ КАЙЧАК СИҢА ПАРАЛЛЕЛЬ РӘВЕШТӘ КИТЕРЕП КУЯ.** Мәсәлән, геолог ирең итеп.

БӘХЕТСЕЗЛЕК ЭЧЕНДӘ БУЛА ТОРГАН БӘХЕТЛӘР ДӘ АЗ ТҮГЕЛ. Әгәр шул яшеренгән бәхетләрне тоя алсаң, ул инде үзе зур бәхет.

Тугыз айлык чакта төшкән гаҗәеп бер фотосурәтем бар. Үзем дә, бәхетем дә түп-түгәрәк... Егыла күрмәсен, дип, яшеренеп кенә әнкәм куллары тотып тора. Аның белән «бергә» төшкән бердәнбер фото... **ВАКЫТ-ВАКЫТ ТОТЫП**

Фото: Ксения Богданова

PRESSA

ТОРГАН КУЛЛАРЫН АЛА ДА, МИНЕ КҮЗӘТӘ КЕБЕК: егылудан сабак ала белдемме? Хаксызга рәнҗетелдем – кичерә алдыммы? Сабырлыгым төкәнмәсме? Шатлыгым, яратуым кимемәсме? Яңа сынаулар ялгыш тез чүктермәсме?

МИНЕ ИҢ СОКЛАНГАНДЫРГАНЫ – БИШ ВАКЫТ НАМАЗНЫ МИНУТЫН КИЧЕКТЕРМИЧӘ УКЫГАН КЕШЕЛӘР.

Әнкәйнең ике кыз туганы – Чибәр апа да, Алма апа да минем өчен барысын да эшләргә әзер иделәр. Җанны бүлеп бирү шулай буладыр ул... Мин дә аларга шулай игелекле булырга тырыштым. Чибәр апамны авырыксынмыйча 9 ел карадым, җизнәмне тәрбияләдем. Гомер буе мех берләшмәсендә эшләгән, 29 яшендә Ленин орденына лаек булган Фәйрүзә апам. Алма апам да, авырган вакытларда: «Син килсәң, җаннарым рәхәтләнә», – дия иде. Әбекәйгә дә язмыш мине болай гына ташламаган... 12 еллап урын өстендә ятты ул – 9 яшьтән аны карадым. **РӘХМӘТКӘ ҺӘРВАКЫТ РӘХМӘТ БЕЛӘН ҖАВАП БИРЕРГӘ КИРӘК.**

ХАТИРӘЛӘР КЕШЕ ӨЧЕН БИК ҖИҢЕЛ ЙӨК ТҮГЕЛДЕР. Ул барыбызда да катлам-катлам. Без бит Җирдән яратылган, язмышларбыз да Җиргә охшаш. Анда да катлам-катлам комнар, ташлар, челтерәгән чишмә сулары... Аннан уңдырышлы туфракның игеннәре, җир тулы чәчкәләре...

ИҖАТЫҢ, ТӘРБИЯҢ, ГЫЙЛЕМЕҢ... БУЕНЧА ЮГАРЫЛЫККА ИРЕШЕРГӘ МӨМКИН, ӘММА ИРЕШКӘННЕ САКЛАУ ШАКТЫЙ АВЫР. Шул югарылыкта кала алмадым дип, үкенгән чакларым минем дә булды.

Син үзеңне яратмыйсың дип әйтәләр кайчакта. **Ә ТОРМЫШ МИҢА ҮЗЕМНЕ ТҮГЕЛ, ӘҮВӘЛ БАШКАЛАРНЫ ЯРАТЫРГА ӨЙРӘТТЕ.** Ятимлекнең кайтавазы шундый.

КЕШЕ НИНДИ ГЕНӘ УРЫНДА УТЫРСА ДА, ҮЗЕН НИЧЕК КЕНӘ БӘЯЛӘСӘ ДӘ, ХАТАЛАРДАН ХАЛИ БУЛА АЛМЫЙ. Хата дигәнебез күпмедер дәрәҗәдә сынау, сабак бит ул. Адәм баласы шул сабакларны үтә-үтә генә хакыйкатьне аңлыйдыр.

65 ЯШЬТӘ МАШИНА РУЛЕ АРТЫНА УТЫРДЫМ. (Һәм икенче көнне үк, берәүгә дә әйтмичә, 400 чакрымдагы туган авылыма кайтып киттем!) Журналист буларак, Аграновскийлардан үрнәк алып, үзебез аша үткәреп язабыз дип, аның кебек унар көн таксида эшләп карарга хыялланган буын без. Апас районында тапшыру әзерлим шулай. Урак ахырына якынлаша. «Бирегез әле миңа штурвалны», – дим. Рөхсәт итәләр! Соңгы покосны узам, һәм районда урып-җыю тәмамлана!

ЯЗГАНДА, КҮЗЕМНЕ, КҮҢЕЛЕМНЕ ИРКӘЛӘП, КАРШЫМДА ЧӘЧӘК, ҺИЧЬЮГЫ БЕРӘР КОРЫГАН БОТАК-ЧАТАК КЫНА БУЛСА ДА ТОРЫРГА ТИЕШ.

Бик матур урман юлы. Әкрен генә җиккән ат бара. Тәгәрмәч юлына сулар җыелган. Дилбегәне бабыкам тоткан. Ә мин гел артка карап утырам... «Бүген, хәзер яшәп калырга кирәк» дигән сүзне күп әйтәләр. Ә галимнәр «хәзерге» дигән мизгел «хәзер» дигәнче узып китә, үткән белән киләчәк кенә бар» дип фаразлый. **МИН ДӘ АРТКА КАРАП АЛГА БАРАМ ИКӘН.**

ХАТЫН-КЫЗ МӘХӘББӘТЕ ӨЧЕН КӨРӘШЕРГӘ ТИЕШ. Мин иң күп көрәшүчеләрнең берсе булдым бугай... Хатын-кызга бу сүз бигүк килешеп тә бетми, бер карасаң. Чынлыкта, бу күңел, хис көрәше. Мәхәббәт тә, ир-ат та – язмыш бүләге ул... Хәер, бүләк кенә микән...

Телевидениедә канатланып, очып эшләп йөргән, әллә ничә гомергә торырлык 17 ел!.. Мөхәммәт абый Мәһдиевнең актерлар йортында зур иҗат кичәсен үткәрергә әзерләнәбез. Мәскәүдә мондый кичәләрне 50 кешелек төркем оештыра, ә без өч-дүрт бөртек... Кызлар: «Филисә апа, тизрәк килегез, телефонда Мөхәммәт абый!» – дип дәшәләр. Коридорның икенче башыннан йөгерәм. Аягымда – биек үкчәле туфлиләр. Өстәлдә яткан трубканы алам. Мөхәммәт абыйның беренче сүзе: «Карале, син уң аягыңа катырак басасың икән ич!» Башта сүзсез калам, билгеле. Аннан: «Рәхмәт, Мөхәммәт абый. **МИН БИТ БҮГЕНГӘЧӘ БӘХЕТТӘН КАЙСЫ АЯГЫМНЫҢ ҖИРГӘ ТИЯР-ТИМӘС ЙӨРҮЕН БЕЛМИ ИДЕМ»,** – дип, аны шаккаттырам.

КИМ ДИГӘНДӘ, ӨЧ-ДҮРТ МАТБУГАТ БАСМАСЫ АЛДЫРАБЫЗ. Төн – безнеке!

МИНЕМ ӨЧЕН ТУГАН ҖИР – ӘГЕРҖЕ РАЙОНЫ КӨЧЕК АВЫЛЫ. Шунда үстем. Чишмә башым, кадерле хатирәләрем аның белән бәйле.

Туган җир, дидем. Ә бит дөньяга аваз салган җирем башка – Удмуртиянең керсәң чыга алмаслык кара урманнары эчендәге кечкенә бер станция. Соңгы мәртәбә 1955 елда Фәритне җирләргә әбекәй белән бардык без анда. 5 яшь иде энемә. Урман эшендәге әткәйне Мәскәүгә укырга җибәрәләр. Тәрәзәгә капланып, гел аны көткән Фәрит. Боз ашаган... **УЛ ИСӘН БУЛСА, БӘХЕТЕМ ТҮГӘРӘК БУЛЫР ИДЕ...** Аны озата, күреп кала алмаган әткәй, кайткач, бер иптәше белән каберне казый. Ләхеткә төшеп җиткәч, аңын югалта – каберне кире күмеп куялар.

«Узганнардан түгел, мин халкыма. / Киләчәктән урын барлыйм...» Нури ага Арслановның «Атлантида» шигыре минем өчен Атлантида һәм милләт зурлыгында! Өч тапкыр тапшыруга керттем – сыздылар. Дүртенчесендә – туры эфирга Нури ага үзе килде. Әмма «Атлантида»ны укырга барыбер рөхсәт булмады. **АКСАКАЛ АЛДЫНДА ТЕЗЛӘНЕП ЕЛЫЙСЫМ КИЛДЕ.** Ни кызганыч, тапшыруда берничә мәртәбә «татар» сүзе кергәнгә генә дә эфирга үтмәгән очраклар булды.

Бер әйбәт сыйфатым бар – кешенең байлыгыннан көнләшмим. Сөенәм генә! **НИГӘ ӘЛЕ БАШКА ХАЛЫКЛАР ЧЕРЕП БАЕГАНДА, БЕЗ МЕСКЕН, ЯРЛЫ БУЛЫРГА ТИЕШ?!**

«Сөембикә»дә чыккан «Норихиро – чын татар» дигән мәкаләмне еш искә төшерәм. Казан университетына килеп, Флера апа Сафиуллинада дәресләр алган, «Татар халкының XX гасыр башы иҗтимагый-сәяси тормышы» дигән темага кандидатлык диссертациясе якларга әзерләнгән аспирантларның берсе иде Норихиро Наганаве. Татарча сөйләшеп утырдык! «Бездә тел проблемасы бар инде, бөтен милләттәшләребез дә туган телне белмиләр», – дим. Ул уйланып торды, аннан: «Японча белмәсәк, японнар булмас, Япония булмас бит», – дип куйды. **НИНДИ АСЫЛ МӘГЪНӘ!**

ЮЛЫМДА ОЧРАГАН ҺӘР КЕШЕДӘН ҮРНӘК АЛЫРГА ТЫРЫШТЫМ. Телевидение, анда эшләгән затлы, зыялы рус журналистлары да күп нәрсәләргә өйрәтте. Яшьләр тапшыруы редакторы Мария Гавриловна Шувалова онытылмый. Миңа, студент кызга: «Филисә Назиповна», – дип кенә эндәшер. Нәрсә турында сүз чыкса да: «Сез аны беләсез», – дип сөйләр. «Сөембикә»дәге остазым Эльмира апа Әдиатуллина да шулай үсендерә иде.

Авылыбызның зираты тау өстендә. Ерак түгел чишмәләр ага. Җәйләрен җиләк эчендә утыра. Кешенең җаны төсле җир җиләге... Безнекеләр шунда. Ихтимал, шунда кайтылыр. **МӘҢГЕЛЕК ӨЧЕН АННАН ДА МАТУР ҖИР ТАГЫН КАЙДА БАР?!**

МОНЫ МИН ГЕНӘ ЭШЛИ АЛАМ, МИН ГЕНӘ ТАРТА АЛАМ ДИП, БӨТЕН НӘРСӘНЕ КОЛАЧЛАРГА ТЫРЫШАМ – ӨСТЕМӘ ЙӨК ӨЯМ. Хатын-кыз өчен шактый зур кимчелек.

Әнкәйнең бер батист кофтасын әле дә саклыйм. Бигрәк нәфис гәүдәле булган ул... **ЯГЫМЛЫ, МИҢА КАРАТА ЙОМШАК КҮҢЕЛЛЕ КЕШЕЛӘР ОЧРАСА, ГЕЛ ӘНКӘЙНЕ ХӘТЕРЛӘТӘЛӘР.** Остазларым Розалина Нуруллина, Лена Таҗиева, Әминә Сафиуллина, Роза Туфитулловада әнкәм яктылыгын, әнкәм кайгыртуын күрдем.

ӘТКӘЙНЕ ЭЗЛӘП ИКЕ ТАПКЫР БАРДЫМ. Башта I курсны тәмамлагач. Аңа хәтерем калган иде ул чакта – бер тапкыр да әнкәйне искә төшермәде... Икенче тапкыр 2002 елда: «Әткәй, дөнья хәлен белеп булмый, шулай яшәлде инде, бәхиллегеңне бир», – дип кайттым. Соңгы күрешү булды... Әткәй кулгә юкә кабыгы салган – мунчала әзерли. Бер бәйләм мунчала сорап алдым. Җаныма, тәнемә шуннан да кадерлерәк, йомшаграк нәрсә булмады... Хәзергәчә саклыйм. Озата чыккач: «Җирдә әнкәң кебек кеше башка юк...» – диде. Ниһаять, күз яшьләре белән ярату сүзләрен дә ишеттем!

Авылда бер тамчы су кебек охшаш игезәк кыз туган Миннеһәдә апа белән Миңнур апа бар иде. Миңнур апа – республика күләмендәге данлыклы ферма мөдире, XXV съезд делегаты. Икесе дә хикәятләп, сурәтләп сөйләү осталары. Аларның әниләре Фатихәттәй үзе чыгарган җырларыннан гына бер сәгать эчендә бер дәфтәр яздырган иде. Без инде илле елдан артык авылга шушы нигезгә сагынып кайтабыз... Бу йортта гомергә капка-ишек ачык. Кем килеп керсә дә, якты йөз, сый-хөрмәт. Бәлеш пешәр, мунча ягылыр, мамык түшәк-ястыклар җәелер. Торуга, теләңне йотарлык эремчек коймагы, шәңгә пешәр... (Аларның кайчан, ни арада пешкәнен генә белгән кеше юк!) Һәдә апаның улы Рөстәм Нурмөхәммәтов 20 ел инде авыл җирлеге башлыгы вазыйфасын башкара. Олы җанлы, һәрнәрсәне акыл белән эш итүче җитәкче. Авыл халкы әйткәнчә, Көчекнең алтын баганасы. **АВЫЛНЫ ДА, ШӘҺӘРНЕ ДӘ, КЕШЕЛЕКНЕ ДӘ ШУШЫНДЫЙ КЕШЕЛӘР ТОТА.** Миңнур апаны көз көне җирләгән идек, җәйнең беренче атнасында Һәдә апаны озаттык. Соңгы тапкыр, үкенечле, сагынулы бер елау белән үксеп, шул көннәрдә еладым. Мирас китә, моңнар китә. Дәвер үзе китә...

ТУГАН ТЕЛ УЛ – НИЧӘ ГАСЫРЛАР ДӘВАМЫНДА ҮСКӘН, ТАМЫРЛАРЫ ТИРӘНГӘ КИТКӘН ИЛАҺИ ЧИНАР АГАЧЫ ТӨСЛЕ. Белепме, белмичәме, үзе утырган шул агачны, шул ботакларны үз татарыбыз үзе кисүдән сак булса иде.

Бакчадан кайтам. Алма вакыты. Күтәрә алган кадәр күтәрдем – үзебезгә караганда алма кызганычрак инде безгә... Никадәр ашыксам да, электричкага соңга калдым. Иллеләп машина узгандыр, ник берсе туктасын?! Күккә, болытларга карап: «И-и Раббым, бер генә шәфкатьле бәндәң дә калмадымыни соң?!» – дип үрсәләнеп әйтеп куйдым. Һәм имәнеп киттем: гаҗәпсенүдән болытлар хәрәкәтләнеп куйды... Ул да түгел, юлның теге ягына бер ак машина туктады. «Апа, 5 минуттан әйләнеп киләм, кирәк җиреңезгә алып барырмын», – ди. Озакламый килеп тә җитте. «Теләчедән иртән үк чыккан идем инде», – ди. Теләк... Теләче... Ходай үзе безгә «теләче» дип әйтә түгелме? **ХИКМӘТЛӘР АДЫМ САЕН...**

ТУГАН ҖИРЕНДӘ ЯШӘГӘН КЕШЕНЕҢ БЕР ХӘСРӘТЕ КИМ ШУЛ – ҖИРСҮ-САГЫНУЛАРЫ АЗРАК...

Ни аяныч, кеше кадере китә барган заман. Хәер, һәрчак һәр заман кешене үзенчә кадерсезләгән... Кадер-хөрмәтнең асыл нигезе – гаилә. Кадерле булу минем дә иң зур бәхетем. Аны тәшкил итүче газизләрем – үземә дә җаным күк кадерлеләрем – Роза, Эльвира, Равил; Шәүкәт, Әдилә; Гөлфия, Марсель, Руслан... **ҖИРДӘ КАДЕР КИЧЕ КЕБЕК ИЛАҺИ, ТЫЛСЫМЛЫ ТӨШЕНЧӘЛӘР БАР. КАДЕР ДИЮ ДӘ ШУЛ ОЛУГ ФӘЛСӘФӘ ТАМЫРЫННАН.** Раббыбыз һәр адәм баласына кадерле булып туу, яшәү һәм кадерле вакытта саубуллашу, хушлашулар насыйп итсә иде.

Гөлнур САФИУЛЛИНА әзерләде.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

МОРЗА КЫЗЫ МӘРЬЯМ СОЛТАНОВА ТАРИХЫ БЕЛӘН МИНЕ ИКЕНЧЕ БЕР АКЧУРИНА – НӘФИСӘ ФӘЙРҮЗ КЫЗЫ ТАНЫШТЫРДЫ.

Уфа – әлеге асыл нәселнең ике кызы өчен дә язмыш төяге булган җир. Гомумән, Адаш морза нәселе Акчуриннарның географиясе бик киң – туган төбәкләре Темниковтан алып, Саратов, Сембер, Самара, Түбән Новгород, Троицк, Уфа, Казаннарны буйлый...



Ландыш ӘБҮДӘРОВА



Мәрьям Акчурина портреты. Вәкил Шәйхетдинов эше.

МОРЗА КЫЗЫ

Уфаның тарихи өлешендә – Тукай урамында, Диния нәзарәте каршындагы София аллеясында урнашкан ике катлы кызыл кирпеч бина архитектур стиле белән дә, тарихи йөзе белән дә бик күп мәгълүмат саклый. XIX йөз ахыры – XX йөз башында ул вакыттагы Спас һәм Фролов (соңрак Воскресение) урамнары кисешкән урында төзелгән бу йорт кайчандыр Беренче мөселман хатын-кызлар комитеты рәисе Мәрьям Тимербулат кызы Солтанова-Акчуринаныкы булган. Ишек катындагы тимердән челтәрләп эшләнгән козыректа «МС» хәрефләре бар...

– Мәскәүдән Уфага күчеп кайткач, София аллеясында йөрергә гадәтләндем. «МС» дигән язулы йорт яныннан узам, ләкин аны ерак туганым Мәрьям Тимербулат кызыныкы дип уйламыйм да. Уфада Мостай Кәрим урамында урнашкан мәдрәсә дә Мәрьям Солтанова исемен йөртә. Кызыксынып киттем. Шул вакыттарак бер тарихчы танышым кунакка килгәч, телевизор карап утырганда: «Нәфисә, кара, синең апаң турында сөйлиләр», – дип кызыксынуымны тагын да арттырып җибәрде. Солтанова Уфада хәйрия эшләре белән шөгыльләнгән, дип сөйлиләр, ә аның чыгышы, нәселе турында ләм-мим. Шуннан эзләнә башладым, Мәрьямнең Сембер байлары Акчуриннар кызы икәнлегенә инандым, тарихын

өйрәндем. Мәскәүдә каберен эзләп таптым, – боларны Нәфисә Акчурина сөйли.

XX йөз башының күренекле нумизматы, искиткеч бай китапханә иясе (аның китапханәсендәге сирәк китаплар турында 1914 елда Ризаэтдин Фәхретдин дә яза) Хәсән Акчурин чакыруы буенча Гурьевкада атна-ун көн кунак булып кайткач, Тукай дусты Галиәсгар Камалга: «Алар безнең кешеләр түгел. Горничнаялары няня кебек ашатаэчертә, йокларга яткыра. Йоклыйм дисәң дә, йоклый алмассың», – дип, тәэссоратлары белән уртаклаша. 1909 ел була бу. Тукайны поезддан каршы алырга икешәр тройка атлар җигеп, Барыш станциясенә Хәсән Тимербулат улы үзе килә. Шагыйрьне Акчуриннар йортында бәйрәмчә киенеп каршы алалар, коридоры кышкы бакча итеп бизәлгән бүлмәгә урнаштыралар. Габдулла Тукай хөрмәтенә көн саен мәҗлес оештыралар, кунак исә көндезләрен Хәсәннең китапханәләрендә була, фабрика цехларына кереп йөри.

«Безнең кешеләр түгел»... Тукайның әлеге сүзләре бүген инде метафора булып яңгырый. Бу ярлык милләтебезнең тулы бер социаль катлам кешеләренә 1917 елда тагылган да шуннан бирле аннан котыла алганыбыз юк. Алар өчен түгел, беренче чиратта үзебез өчен котылу кирәк тә бит. Туктаусыз хәйриячелек белән шөгыльләнү, халыкны мәгърифәтле итәм дип, җаныңнытәнеңне фида итеп яшәү өчен адәм баласының рухи кыйммәтләре нинди югарылыкта булырга тиеш?

Аслиһи-нәслиһи

Мәрьям Тимербулат кызы – XIX–XX йөзләрдә Сембер губернасының һәм Идел буеның беренче гильдия сәүдәгәрләре һәм мануфактурачылары Акчуриннар кызы. Сембер губернасының Барыш станциясеннән өч-дүрт чакрымдагы Гурьевка авылында Тимербулат Акчурин гаиләсендә туган. Тимербулат Курамша улы исә Сембер Думасының гласные итеп сайланган, Гурьевкада постау фабрикасы тоткан, постау, трико, шинель тукымасы җитештергән. Уфада берничә йорты булган. Акчуриннар мәктәпмәдрәсәләр төзегән, талантлы яшьләрне Сембер, Казан, Троицк, Уфа, Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Кырымга җибәреп укыткан.

Тимербулат Курамша улын халык бик яраткан, диләр. Хәтта революция вакытында бөтен бәхетсезлекләренең башы байлардан, дип ышанып, аларны катлам буларак юк итәргә ярсыган халык яраткан Тимай баен яклап чыккан. Тимай бай үзе аларны 1881 елгы ачлыкта үлем тырнагыннан йолып калганны онытмаганнар. Ул вакытта Акчурин Иске Тимошкино авылында ярлылар өчен бушлай ашханә ачкан. Көн саен анда 150–320 кеше ашап чыга торган була. Моның өчен көн саен 10 пот тирәсе ипи, өчәр пот ат яки сарык ите, 30 фунт тары ярмасы, 5 фунт тоз киткән. Рус-япон сугышы вакытында Гурьевкадагы фабрикасы каршында яралылар һәм авырулар өчен дәваханә ачкан, ә 1905 елда Иске Тимошкинодагы зур янгыннан соң зыян күргән меңгә якын кешене азык-төлек, кием-салым, утын, орлык белән тәэмин иткән, акча биргән.

– Менә шундый гаиләдә тәрбияләнеп үсә Акчуриннарның балалары, – ди Нәфисә ханым. – Безнең анда «капиталист», «буржуазия вәкилләре» дигән төшенчәләр тискәре хисләр уята. Ә алар, чынлыкта, тапкан малларын кешеләргә өләшүдән тәм табып яшәгәннәр, аны яшәү рәвешенә әйләндергәннәр. Китап сүзенә бик ихтирамлы булганнар, аң-белемгә омтылганнар. Акчуриннар балаларын олы тормышка чыгарып җибәргәндә (өйләндергәндә, кияүгә биргәндә), аларга китапханә бүләк итә торган булганнар. Мәчет, мәктәп-мәдрәсә салырга кушканнар һәм моның өчен акчалата ярдәм иткәннәр. Аңлы, максатчан рәвештә мәгърифәтчелек белән шөгыльләнгәннәр. Ул заманның морзалык билгеләре – белемгә сусау, үз заманына тиң белем үзләштерергә тырышу Акчуриннарга да хас булган.

1886 елда Тимербулат Курамша улы Казан гимназиясен тәмамлаган кызы Мәрьямне Оренбург Диния нәзарәтенең бишенче мөфтие Мөхәммәдьярның улы Арыслангали Солтановка кияүгә бирә. Яшь гаилә Уфада таш мәчет каршындагы йортта яши башлый. Шуннан бирле гомеренең ахырынача Мәрьям Солтанова халыкка хезмәттә була.

«Хезмәт эчендә йөз мәккә» икәнлегенә хаҗия күптән инанган була, күрәсең.

Хәйрияче Мәрьям

Мәрьям бәхетле булганмы? Бу сорауга җавапны гасырдан артык вакыт узгач, төгәл генә әйтеп булмый инде. Аны белгән кешеләр дә, көндәлекләр дә, хатлар да калмаган диярлек. Ул калдырган мирас – кылган игелекләре.

– Арыслангали белән Мәрьямнең үзләренең балалары булмаган. Ләкин алар өйләнешүгә үк Спас урамындагы йортларында мөселман гаиләләреннән булган кызлар өчен мәктәп ачалар. Укыту бушлай, яңача ысулда алып барыла. «Галия» мәдрәсәсе төзелә башлагач, Мәрьям ханым 900 аршын сары, 100 аршын яшел төстәге постау бирә. Хәсән Акчурин шактый суммада акча белән ярдәм итә. Шәһәр Думасының гласные буларак, Арыслангали Солтанов ярлы гаиләләрдә үскән, ләкин укуда үрнәк 10 гимназистка стипендия булдыра. Уфаның ярлы мөселманнарга ярдәм итүче хәйрия попечительлеген оештыручыларның берсе. Мәрьям Тимербулат кызы да иреннән калышмый. 1906–1914 елларда ул – Уфадагы Беренче мөселман хатын-кызлар җәмгыятенең рәисе. Комитетның мөселман хатын-кызларын мәгърифәтле итү максатыннан мәктәпләр, китапханәләр, уку заллары ачу белән шөгыльләнә, укучы кызларга стипендияләр белән булыша. Мөселман малайлар һәм картлар өчен приютка да Солтанова җитәкләгән комитет ярдәм итеп торган, – дип сөйли Нәфисә Акчурина Солтанованың хәйрия эшчәнлеге турында.

XX йөз башында Россиядә мөселман хатын-кызларның 70 тән артык

оешмасы була, ләкин Солтанова җитәкләгәндә, Уфаныкы бөтен төрки дөньяга танылa. Мәрьям Тимербулат кызы балаларга гына ярдәм итеп калмаган. Мәсәлән, аның турында хатирәләрендә Әхмәтзәки Вәлиди-Тоган рәхмәт хисләре белән искә ала. Вәлиди «Госмания» мәдрәсәсендә укытканда, Мәрьям ханым аңа китапханә бүләк итә, акчалата ярдәм итә. Киләчәктә дөньяга танылачак галим, тюрколог, тарихчы өчен мон-

Исталекләрдә Мәрьям ханымның бик сабыр, күркәм холыклы булуы турында язалар.



дый ярдәмнең ни дәрәҗәдә зур байлык икәнен чамалавы кыен түгел. «Шушы ярдәмнән файдаланып, мин Европадан гарәп телендә, Бомбей, Калькуттадан фарсы телендә басылган тарихи хезмәтләрне яздыртып алдым, шулай ук Европа китапханәләрендә саклана торган фарсы тарихчылары Мирхонда һәм Хондермир хезмәтләрен, «Бабурнамә», шәрык кулъязмаларының күчермәләрен кайтарттым... Шул рәвешле, Мәрьям ханым ярдәме белән мин тарихи китапханә иясе булып киттем...» – дип яза Вәлиди.



Нәфисә Акчурина: «Йортның кемнеке икәнлеген белсеннәр өчен тактаташ куярга кирәк иде – 2016 елда истәлекле такта эленде».

– Үзе дә җәдиди белем алган Мәрьям заманының алдынгы карашлы кешеләре белән аралашып яшәгән. Толстой белән дә хат алышкан, – ди Нәфисә Акчурина.

Билгеле булганча, Лев Толстойның 90 томлыгының 31 ен хатлары алып тора. Ул хатлар арасында Мәрьям ханымның ире Арыслангалинең бертуганы Сәлимгәрәй Солтанов язганы да бар. Хат 1896 елга карый. Автор Лев Николаевичка ни өчен аның китапларын тәрҗемә итәргә алынуын аңлата, моның өчен рөхсәт сорый (хатның өзеген оригиналда бирәбез):

«...Так как между моими единоверцами, как-то: среди башкир, татар, сартов и т. д., читающих на русском языке весьма мало, то я с удовольствием беру на себя труд перевести Ваши произведения на тюркское наречие. ... Также покорнейше прошу не отказать мне в переводе статьи Вашей «Стыдно». Все три перевода будут изданы отдельной книгой. По распродаже издания половину прибыли думаю пожертвовать в пользу недостаточных студентов-магометан Московского университета. Смею просить принять уверения в истинном почтении и искренней любви к Вам, покорный слуга Вашего Сиятельства Салим-Гирей Мухамедьярович Султанов, сын оренбургского муфтия. Адрес: Уфа. мужская гимназия. Ноябрь 10 дня, 1896 года».

Мәрьям ханымның ире Арыслангалинең Ясная Полянада булып кайтуы билгеле. Боларның барысы да Солтановларның Толстой гаиләсе белән аралашуы турында сөйли.

1913 елда, ире вафатыннан соң, Мәрьям Солтанова әтисе бүләге булган йортны ятимә кыз балалар өчен приютка вакыф итеп тапшыра. Бер катлы йортта уннан артык бүлмә була: сыйныф бүлмәләре өчен дә, яшәргә дә, тегү-чигү эшләренә өйрәнер өчен дә урын җитәрлек. Бу вакытта янәшәдә генә вензель белән «МС» хәрефләре төшерелгән мәгълүм йорт төзелгән була инде. Приют кызларын Солтанова азыктөлек, кием-салым белән генә тәэмин итеп калмый, аларны укытып, алга таба эшкә урнаштыру, кияүгә бирү кебек аналарча кайгыртучанлыкны да үз өстенә ала. Кайбер мәгълүматларга караганда, Мәрьям Солтанова приюты 1920 елларга кадәр эшли. 1925 елгы белешмәдә Тукай урамы, 29 нчы йорт совет хезмәткәренең фатиры итеп күрсәтелгән...

– Мәрьямнең фаҗигасе нидә?

– Революциядәдер. Совет власте урнашуга, рәсми рәвештә хәйриячелек бетерелә, чөнки бу күренешләр инкыйлаб принципларына каршы килә: һәммәсе дә тигез, беркемгә дә ярдәм кирәк түгел. Мәрьям ханымның тормыш мәгънәсе – кешеләргә ярдәм итеп яшәү. Икенче яклап, 1917 елдан соң, әгәр син бай икән, син бернинди хәйрияче дә, меценат та түгел, ә сыйнфый дошман, эксплуататор...

Мәрьям Солтанова-Акчурина 1928 елның мартында 70 яше тулырга бер ел кала, Мәскәүгә дәваланырга киткән җиреннән, авыруы көчәеп, гүр иясе була.

* * *

Мәрьям ханымның туганы икәнен белгәч, Нәфисә Фәйрүз кызы Мәскәүгә барып, аның каберен зиярәт кылырга була. Таныш тарихчы хатыны белән, ярдәмгә студентлар да ияртеп, Данилов зиратына китәләр. Бер көн эзлиләр, икенче көн... Өченче көнне яңгыр ява башлый, Нәфисә ханым үзе генә чыга. Эзләп-эзләп тә таба алмагач, бичара булып, эскәмиягә килеп утыра. «Йа Аллам, кабере янында рухына дога кылырмын дигән идем, шушында гына кылам инде», дип, еларга җитешеп утырганда, күзе бер чите яңгырдан юылган кабер ташына төшә. «...Тимербулат кызы» дигән сүзләрне укып, кабер ташындагы язуны тулаем ачып карый: Мәрьям... Яңгыр дип тормый, кабер ташына кунып, ак канатлы бер кош, әй, өздереп сайрый шул мизгелдә...

Чыганаклар, фотолар белән ярдәм итүе өчен Нәфисә Акчуринага рәхмәтлебез. Мәкаләдә тарихчы Наил Таировның «Акчуриннар» китабыннан мәгълүматлар файдаланылды.

БУРЫЧ ГАФУ ИТЕЛМИ



Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

Ходай каршында кем хәерлерәк: бурычка керүчеләрме яисә кермәүчеләрме?

– Пәйгамбәребез: «Кешегә әйбер сорап бару ул үзеңнең битеңне тырнау белән бер», – ди. Шуның өчен, әлбәттә, сорамау – хәерлерәк. Пәйгамбәребез тагын болай ди: «Әгәр кеше баер өчен бурычка сорап йөрсә, бу очракта ул гомергә хәерче булып калыр». Азрак аңлатып китим. Мәсәлән, имам Газали әйтә: «Тормышын яхшыртыр өчен бурычка акча алып тора икән, бу кеше – ахмак», – ди. Ашарга ризыгың, кияргә киемең, торырга урының, дару алырга, якын кешеңне җирләргә акчаң булмаса, бурычка керергә мөмкин. Ә калган нәрсәләр өчен сорау – тормышны бизәү дип атала. Бездә хәзер күбрәк тормышларын бизәр өчен акча сорыйлар. Мәсәлән, машина алу өчен. Ә бит кеше машинасыз да яши ала. Акча җыеп, үзе сатып алса – бер хәл әле, ә түли алмаячагын белә торып, бурычка чумуны, әлбәттә, ахмаклык дип атап кына була. Менә шуның өчен дә Россиядә хәзер кайтарылмаган бурычлар саны 13,5 триллионга җиткән инде. Кредит – шул ук бурычка алып тору ул. Өстәвенә, хәрам дә әле.

Тормышыңа куркыныч янамаса, дин буенча бурычка акча алып торырга киңәш ителми. Хәтта тыела.

Бурычка акча сорап килгән кешене кире бору дөресме?

– Әгәр аның нәрсә өчен алып торганын яхшы беләсең икән (әйтик, машина яңартырга, фатирны киңәйтергә), андыйларга акча бирмәскә киңәш итәм. Тормышны яхшыртырга икән – уңайсызланмыйча баш тарта аласыз. Мондый сәбәп белән алганда, гадәттә, бурычны күп вакытта озак кайтаралар. Тормышлары беркадәр алга киткәч, ул кешеләр бу бурыч турында оныталар. Акча килеп чыккан саен, аны кабат тормышны яхшыртуга тоталар.

Бар шундый кешеләр, бурычлары була торып та, чит илгә ялга чыгып китәләр, өсләренә яңадан-яңа кием, өйләренә яңа җиһаз, техника алалар. Ә бит бурычны кайтару беренче чиратта торырга тиеш. Игътибар итсәгез, авырлык күрүче, фәкыйрьрәк кеше, бурычка алса, аны тизрәк кире кайтара.

Тормышның ниндидер авырлыгы аркасында бурычка сорап килсәләр, бу вакытта аларны буш җибәрмәү бик зур савап санала. Әгәр сиңа шундый гозер белән килгәннәр икән, беренче чиратта шуны аңларга кирәк: бу кеше үзенең горурлыгын җиңеп, баш иеп килгән. Аны кимсетергә ярамый. Чынлап торып мохтаҗ икән, мөмкинлегең булса булышырга тырышырга кирәк. (Мохтаҗ булмаса, әйткәнемчә, «юк» дия дә аласың.) Мондый кешегә бурычка акча бирсәң, сиңа сәдака биргән савабы языла. Әле бит ул акчаның кире кайтмавы да мөмкин. Кире кайта торган булса да, савап барыбер языласак. Акча алган кеше, «бер айдан кире кайтарам» дип китеп, әйткән көне җиткәч: «Әле кайтара алмыйм, бераз көтеп тора алмыйсыңмы?» – дисә, бу очракта синең сәдака савабың икегә тапкырлана. Әгәр инде бирә алмавын күреп, бу бурычны син аңа гафу итсәң, савап тагын да күбрәк языласак. Тик аның үзенә дә бу хакта әйтергә кирәк.

Шәригать ягыннан караганда, туганыңа акча биреп торуның савабы ике-өч тапкыр күбрәк. Тик моны туганлык хисләрен саклап кала алганда гына эшләргә кирәк. Кешеләр хәзер зәгыйфь: аларның йөрәге акчага, малга бәйләнгән. Бурычны кайтармасалар, аралар бозылу да бар. Шуңа да якыннарыңа бурычка биреп тору тагын да четерекле.

Галимнәр, дустыңа бурычка биреп торма, диләр. Аңа акча биреп, ул сиңа кайтара алмаса, кәефең китәр дип түгел, түләр вакыты җиткәч, исенә төшерерсең дә: «Мин аны болай да кайтара идем бит», – дип, ул үпкәләр, арагыздан кара мәче узар, диләр.

Бурычка алып, аны кире кайтармаучылар Ходай каршында гөнаһлы саналамы?

– Әгәр кеше бурычын кайтармаса һәм син аны гафу итмәсәң, ә ул кинәт вафат булса.... Ислам дине буенча, мондый очракта, мираска бүлә башлаганчы, иң беренче аның малыннан бурыч түләнә. Малыннан да бурыч кире кайтарылмаса, ул аны теге дөньяда – Кыямәт көнендә кире кайтарачак: үзенең изгелекләрен-савапларын сезгә бирәчәк. Изгелекләре юк икән, сезнең гөнаһларны үзенә алачак. Пәйгамбәребез: «Бурыч беркайчан да гафу ителми», – ди. Акча биреп торган кеше гафу итмәсә, Аллаһы Тәгалә аны гафу итә алмый. Хәтта шәһидләрнең (ә алар Аллаһ юлында вафат булучылар – урыннары турыдан-туры җәннәттә санала) бурычлары да гафу ителми.

Шул ук вакытта бурычны кайтара алып та, моны эшләргә ашыкмаучыларны «залим» дип атый Пәйгамбәребез. Гаделсез кеше, ягъни мәсәлән. Мондый кешегә карата ислам дәүләтендә, әлбәттә, чаралар күрелә – малы тартып алына.

Кешегә бурычка бирәсең икән, ул акчаның кире кайтмаслыгы белән ризалашсаң гына бирәсең. Дөрес, шәригатьтә мондый әйбер юк. Акча биргәндә күңелеңә авыр булмасын өчен галимнәр биргән рухи киңәш кенә бу. Беренчедән, югалтуы белән ризалашырлык сумманы гына бирү кирәк. Әгәр ниндидер зур сумманы югалту белән килешмәячәксең икән, син аны кешегә бурычка бирмә генә. Ул акча йә кайта сиңа, йә юк. Төрле хәлләрнең килеп чыгуы бар тормышта. Бурычка алган кеше сине алдап йөрергә дә мөмкин. Авыр хәлгә калып: «Теләсәң нәрсә эшләт, бернәрсәм юк, бирә алмыйм», – дип әйтүе дә бар.



Роза
САБИРОВА

Бездә тагын яңа исем: бүген Роза Сабированың дебюты. Ел дәвамында «Сөембикә»гә берничә язмасын җибәреп, өметле автор икәнен раслаган иде инде ул. «Нурлат районы Югары Нурлат авылында туып-үстем. Мәктәп елларыннан ук иҗат белән мавыгам. Әйләнә-тирәдә булган вакыйгаларга битараф кала алмыйм», – дип язган Роза үзе турында. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган, Мәскәүдә социаль-гуманитар институтның логопедия бүлегендә белем алган. Нурлат шәһәрендәге «Алсу» балалар бакчасында педагог-логопед булып эшли. Туган җирендә үзен яраткан эшенә һәм гаиләсенә багышлап яшәве белән бәхетле. Хатын-кыз йөрәге аша үткәреп, булган хәлләргә нигезләп язылган тормышчан хикәясе укучылар күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз.

ҮЗ КОЯШЫМ ЧЫКМАС ДИМӘ...

(Хикәя)

Җәй эссе көннәре белән башланып китте. Чөгендер басуында да эшнең иң кызган мәле. Бер хатын-кыз башына өчәр гектардан артык кишәрлекләп бүленгән җирдә кул белән чөгендер сирәкләүләр җиңел түгел шул. Баш өстенә ут-сөңгесен төбәп торган кояшны беразга булса да сүрелдерерлек бер болыт кисәге күренсә икән?! Су эчсәң дә, эчмәсәң дә, авыз гел кибеп тора. Кызларның бу челләдә өйдән алып килгән чәйләре төшкә кадәр үк бетеп, җылынып үз тәмен югалткан сулары да инде әллә кайда, ызан башында ук калган.

– Ярый, тагын бер генә буразнаны чыгыйк та, аннан, эчне күптерсә дә, теге җылы суны эчеп килми дә булмас, – диде Әдилә үзенә булышырга килгән кунак кызларына.

– Уф, ардырды... Очы-кырые бармы бу басуның, Әдилә апа? Кояшын әйтер идем тагы... кыздырыпмы-кыздыра. Күр әле тәнемдәге загарымны, Самарага кайткач, дус кызларым шаккатыр. Авылга кунакка китәм дип безне алдап, Сочида булгансың син, диярләр.

– Әйе, Ләйлә, авыл кызларының Сочие дә, курорты да шушы инде... Загарың турында сорасалар, шулай дип әйтерсең. Мин чөгендер басуындагы курорттан кайттым гына әле диярсең...

Менә шундый инде ул кызлар, ару-талулары өстенә, сусаудан әлсерәгәндә дә, бер-берсенә төртмәле сүзләр әйтешеп көлешеп алалар. Кичкә таба җеп өзәрлек хәлләре калмаса да, клубка чыгып, егетләрнең башларын әйләндереп керергә дә өлгерәләр.

Әдиләләргә Самарадан кунакка кайткан апалы-сеңелле Ләйлә белән Энҗегә дә атна-ун көн чөгендер басуында бил бөгәргә туры киләчәк. Әниләренең бертуган апалары – Әдиләнең әнисенең йөрәк өянәге көчәеп китү сәбәпле, йорттагы егерме биш сутый бәрәңге бакчасы белән чөгендер басуындагы җир дә Әдилә иңнәренә менеп кунаклаган иде. Кунак кызларының бик вакытлы кайтканнарына апа белән җизни рәхмәтле булса, кызлар исә клубка чыгып дискотекаларда туйганчы биеп күңел ачудан бик канәгать иде. Бизәнеп-ясанып клубка чыгулары үзе бер бәйрәм ләбаса.

– Кара әле, Әдилә апа, бүген клубка теге кыска кара итәгемне кисәм, озын кунычлы кара чулогым белән килешерме дим?

– Килешер, Ләйлә, матур кызларга бар нәрсә дә килешә. Син безнең авыл егетләрен үзеңә

гашыйк итеп бетердең инде. Шаштырасың аларны тиздән, Ләйлә.

Әдиләнең сүзләрен хупламаган Энҗе, киресенчә, бераз апасын битәрләп ала:

– Апа, син карап кына кылан мондагы егетләр белән. Урлап калсалар, шушы авылда гомер буе чөгендер утап интегәчәксең. Аннары син кичә теге егет янында артыграк боргаландың түгелме?! Үзең миңа замечание ясыйсың, үз тәртибең дә примерный түгел бит.

– Алай димә, Энҗе. Теге егет дигәнең безнең күрше Илдар ул. Бик акыллы һәм тәртипле. Кыюсызрак кына. Андый егетләр янында бераз боргалансаң да ярый, танышып китәр өчен кемдер башлап сүз кушарга тиеш бит инде.

– Юк, Әдилә апа, син апаны димләмә әле, ул 17 дә генә, аның әле укып бетереп югары белем аласы бар.

Унберенчегә күчкән Ләйлә зифа буй-сынлы чибәр кызга әйләнгән иде инде. Күзен сирпеп бер караса, егетләрне әсир итә дә куя. Клубта бөтен авыл егете кунак кызын гына күзли иде. Егерме бер яшенә җитсә дә, Әдиләдә әле егетләр кайгысы юк. Гәрчә шундый уңган кызны авыл апалары үз килешнәре итеп күрергә теләүләрен гел сиздереп кенә торсалар да.

Кич җитеп, чөгендер басуыннан кайтуга, кызлар Зария апа ягып куйган мунчада юынып чыгалар да бизәнергә-ясанырга керешәләр. Аннары аннан-моннан капкалап, тизрәк клубка ашыгалар. Зария апа көн саен бер үк сүзне кабатлап озатып кала:

– Зинһар, таңга кадәр йөрмәгез, тагын иртүк торасыгыз бар. Әдиләнең яллары беткәнче шул чөгендер зәхмәтеннән котыласы иде бит...

Аннары кунак кызларына ымлап, Әдиләгә карап тагын дәвам итә:

– Берүк, кунак кызларын үзләрен генә калдыра күрмә. Бергә китегез, бергә кайтыгыз. Башыгызны югалтып йөри күрмәгез, дим. Кыз язмышы кыл өстендә, кылдан төшсә, тел өстендә, диләр. Ишетсен колагыгыз!

Бу үгетне көн дә ишетеп торганга, ярар-ярар дигәнне аңлатып баш кагудан ары узмыйча, кызлар үзара нидер сөйләшеп-көлешеп, тиз генә чыгып китү җаен карыйлар.

Бу көнне дә клубка якынлашуга, Әдилә «крутой» машина янында телефоннан сөйләшеп торган бер ят егетне шәйләп алды. «Бу да сезнең кебек кунак егетедер инде», – диде ул кызларга. Таныш егет булмагач, исәнләшеп торуны кирәксенми генә эчкә уздылар.

Кунак егет Әдиләнең дусты Мәдинәгә таныш булып чыкты. Динар атлы бу егет Норлатныкы ди. Авылга да беренче генә килүе түгел икән. Үзе кебек крутойлар белән кызлар күзләргә килгәли, имеш...

Әдилә эсселе-суыклы булып китте. Ишек кырында авыл егетләре белән сүз алышып торган мут күзле ят егет Әдиләләр ягын күзәтә иде. «Кайсыбызны күзли соң бу?! Мине түгел, билгеле. Әллә... әйе, Ләйләне...»

Шулай уйларга өлгермәде, чү, «Привет!» – дип, Әдиләгә эндәшә түгелме соң бу. «Познакомь меня с сестрой», – ди. Каршысына килеп баскан Динарның әрсез карашыннан югалып калган Әдилә:

– Бездә кунак кызлары тел яшерми, үзең таныш, – диде, авыл кызларына хас шаянлык белән.

Шул кичтән Динар, «Самарочка» дия-дия, Ләйләнең күңелен яуларга керешә. Үз дәрәҗәсен белгән чая шәһәр кызының гына Динарга бик исе китмәде. Күңеле торган саен күрше егет Илдарга тартылуын тойган кыз, тора-бара Динар белән очрашудан бөтенләй баш тартты.

Кунакта никадәр кызык булмасын, бер ай чамасы вакыт кай арада үтеп китеп, апа белән сеңелнең дә китәр көннәре җитте.

– Әдилә апа, үзең дә Самарага кунакка кил, көтәбез! – дип хушлашты Энҗе.

– Гаепләп китә күрмәгез, тагын кайтыгыз, яме, – дип өзгәләнде Әдилә, кызларны җибәрәсе килмичә үз кочагына алып.

– Солнышко, не скучай без нас, – дип саубуллашты Ләйлә дә. – Алай-болай Динар минем белән кызыксынса, син минем белән элемтә тотмыйсың. Окей?

– Ярый, Ләйлә, берни дә әйтмәм. Мин үзем дә синең Динарны түгел, Илдарны сайлавыңа бик шатмын!

Кунак кызлар киткәннән соң, Әдилә өчен җәйнең үз төсен җуйган көннәре бер-берсенә ялганып үтә торды. Сирәк кенә дус кызы Мәдинәгә ияреп клубка чыккаласа да, биюләргә катнашмыйча, тыныч кына бер почмакта утыруны кулай күрде кыз. Динарның да клубта башка кунак кызлары белән гыйшык-мыйшык уйнап йөргәненә әллә ни исе китмәде. Киресенчә, ярый әле Ләйләне сорап йөдәтми дип сөенде генә. Үзе Әдилә белән исәнләшә исәнләшүен, башка сүз катмый. Беркөнне машинасы белән артларыннан акрын гына ияреп тә кайтты. Инде Мәдинәгә күз салуы бугай?! Юк, Мәдинә үз өйләренә таба борылды, машина юлдан тайпылмады. Әдиләләр капка төбенә якынлашуга машинасыннан сикереп төшкән егет Әдиләгә эндәште:

– Слушай, когда Самарочка еще приедет? Забыть ее до сих пор не получается, – диде.

– Белмим, Динар. Ул берни дә әйтмәде. Кая да булса китеп, ял итәргә исәбе бар иде бугай аның.

– Хмм, странно, вроде все так хорошо начиналось... Современная городская девушка, а выбрала себе какого-то простого деревенского пацана...

– Һәркем үз күңеленә хуш килгәнне сайлый. Ярар, Динар, сау бул, мин өйгә керәм, – диде Әдилә сүзне озынайтасы килмичә.

– Постой, подожди, айда постоим, поговорим, – дип үзсүзләнде егет.

– Минем синең белән сөйләшер сүзем юк, Динар.

– Ох-ох, какие мы важные, – дип машинасына таба борылды егет.

Һәм ни гаҗәп, Әдиләнең сөйләшер сүзем юк диюе Динарның мин-минлегенә тидеме, шул көннән башлап тәкәббер егет Әдилә артыннан йөри башлады...

Әле бер ел элек кенә Арча педагогика көллиятен тәмамлап кайтып, районрагы бер чуаш авылы мәктәбендә татар теле укытып йөргән кыз, җәйге

PRESSA

бетмәс-төкәнмәс эшләрдән тәмам туеп, августның унбишеннән сөенә-сөенә эшкә чыкты. Укучылары, башка милләт балалары булуга карамастан, үзен яратып, Адиля Минияровна дип, бер алдына, бер артына төшеп каршы алдылар. Күренеп тора, сагынып өлгергәннәр!

Көзнең беренче айлары яңгырлы һәм салкынча булса, октябрь азагында көннәр кинәт җылынып, әбиләр чуагы башланды. Рәхәтләнеп хозурланып калырлык алтын көз! Тик Әдиләнең күзенә көзнең бу матурлыгы күренми. Үзен бимазалап торган сорауларга төгәл җавап табалмыйча интегеп йөргән көннәре. Йә, нигә кирәк булды инде аңа бу Динар?! Үзен генә яратканлыгы, башкаларны санга сукмавы йөзендә ярылып ята. Янәшә бастырып куймасаң да, пар түгелләр икәнен үзләрен белгән һәркем әйтеп бирә ала югыйсә. Юк, бер көн күрми торса да, Динарны юксына башлый Әдилә. Күреп очрашканнан соң, күңел кайтаргыч кыланышларын кат-кат күз алдыннан кичереп, инде ничәнче мәртәбә башка ул якка әйләнеп тә карамаска дип сүз бирә дә, ял көннәре җитүгә, үзен кабат Динар килеп алганны көтә башлый. Ул шимбәдә дә дәресләрен бетереп чыгуга мәктәп капкасы төбендә иномаркасында йокымсырап утырган Динарны күргәч, күрешү сөенеченнән болай да көләч йөзенә кояш үзе кунгандай булды. Их, шул шимбәдән соң алда үзенниләр көтәчәген белсә, бичара кыз машинага утыру түгел, башын алып җир читенә качар иде дә бит...

Кайтырга чыккач, олы юлдан борылып, машинасын аулаграк урынга туктаткан Динар, мут күзләрен уйнатып, Әдиләне кочагына алды. «Җитәр бу недотрога белән кошки-мышки уйнап йөрергә. Бүген үз дигәнемә ирешәм и точка», – диде ул үз-үзенә.

Нәфесенә ирек биргән егетнең кочагыннан ычкынырга талпынган кыз чынлап та мәче авызына эләккән тычкан хәлендә иде... Әлбәттә, үзенчә карышып маташты ул. Тик бу өлкәдә шактый тәҗрибә туплаган егетнең көчле куллары кызны үз кочагына бөтереп алып, тагын да кыза барган азгын дәрте Әдиләгә кымшанырга да ирек бирмәде. Егет кочагына сеңеп беткән кыз бер мизгелдә үзенең йомшара башлавын тойса, икенче мизгелдә ул моңарчы тоймаган гайре табигый авыртудан каты ыңгырашып, кычкырып җибәрде...

...Бу рәвешле якынлык кылудан кыз баланың тәне генә түгел, җаны да өтеп алгандай куырылуга карамастан, үз хаҗәтен үтәп өлгергән Динарны, гүя, алыштырып куйдылар. Күз яшьләренә буылган Әдиләне йомшак сүзләр белән юату урынына мыскыллы елмаеп:

– А ты, оказывается, кроме меня никому и не нужна была??? Но теперь, надеюсь, проблем не будет. Ворота открылись, – диде һәм берни булмагандай кул сәгатенә күз сала-сала киенергә керешә.

Оятыннан җир тишегенә кереп китәргә әзер булган Әдилә үз капка төпләрендә ничек машинадан төшеп калганын да, ничек өйләренә кереп егылганын да хәтерләрлек хәлдә түгел иде. Бәхетенә, әти-әнисе өйдә булмыйча, кайтуына ягылып куйган мунчага барып, тәненең кул тигән бар җирен күгәрткәнче ышкып юганнан соң гына бераз үз хәленә кайткандай булды.

Намусына көч килеп, кылган гамәле өчен гафу үтенер дип, күңеле белән Әдилә көн дә Динарны көтсә дә, шул шимбәдән егетнең эзе суынды. Гүя, Әдилә исемле кыз булмаган да...

Яңа ел киче дә килеп җитте. Яшьләр белән берлектә Әдилә дә Мәдиналәрдә Яңа елны каршыларга булды. Салатлар ясаганда, банкада калган тозлы кыяр суын түйганчы эчеп куйды да, үзе дә абайламастан:

– Кызлар, минем тозлы кыяр ашыйсым килә, – дип, тәлинкәгә үрелде. Мәдинә бу сүзләрне көлкегә борып:

– Алай-болай буйга узмагансыңдыр бит? – дип куйды.

Кызның шул мизгелдә зиһене чуалып китте. Чыннан да, аның организмында төрле үзгәрешләр бара түгелме? Айлык күреме тукталганны да салкын тиюгә генә юрау, үз-үзеңне вакытлыча гына алдап яшәү бит ул. Табын артында беркемгә күтәрелеп карарга базмыйча үз эченә бикләнеп утырган Әдилә, Яңа ел таңында икәүдән-икәү калгач, Мәдинәгә Динар белән үзенә бәйле хәлләрне сөйләп бирде.

– Кем-кем, тик безнең авыл кызлары арасыннан нәкъ менә синең бу көнгә төшәсең башка сыя торган хәл түгел, – дип, Мәдинә ахирәтенең күңел ярасын кабат кузгатып алды да, тиз арада тест үтәргә кушты. Тест дигәннәренең ни нәрсә икәнен ишетеп тә белмәгән Әдилә аптырап торган арада, җиңгәсенең запас тестын табып алып, аның йөкле булуын раслап та бирде.

– Мәсхәрәсе ни тора. Үлеп китүең мең артык. Әни белән әти ничек кичерер, аларның күзләренә ничек карармын? – Дустының күзләрендә яшәү дәрте сүнгәнен күреп, Мәдинә:

– Зинһар, тынычлан. Елап утырудан эш узган, нидер эшләргә кирәк. Бәлки, башта Динарның үзе белән сөйләшеп карарга дыр, әйдә, бергәләп уйлашыйк әле, – дип, Әдиләне тынычландырырга маташты.

– Нишләргә? Мин бит аның адресын да белмим, – дип карышты Әдилә.

– Әтисе – районның билгеле кешесе. Аны белмәгән кеше юк. Әнисе – зур кибетләр хуҗасы. Бик акыллы хатын, диләр. Улы белән, бәлки, үзе үк сөйләшер?

– Белмим, белмим, – дип өзгәләнде Әдилә.

– Беләсеңме, белмисеңме – башка чара юк. Тик мин синең урыныңда булсам, башта үз әнием белән киңәшер идем. Кешедән ишеткәнче, үз авызыңнан ишетсә, Зария апага да җиңелрәк булыр. Җайлы кеше бит ул, ярдәм итү әмәленә керешми калмас.

Әйе... Бу хәлемдә әнидән кала кем каршына барып егыла алам, дип үзен түгел, инде ишетәсе хәбәрдән авыруы кабат көчәячәк әнисен кызганудан җаны сыкрап, әнисенең иңенә хәсрәт өстәп сарылган Әдиләнең үз хәле дә мөшкел иде. Ана кеше өчен илдә-көндә йөз аклыгы булыр дип үстергән газиз баласының мондый хурлыклы хәлдә калуы үлемгә тиң булса да, Зария бердәнбер кызы хакына Динарның әти-әниләре белән сөйләшеп карарга булды.



Рәсем: Наталья Васильева

Зур кибет хуҗабикәсенең элеккеге яхшы танышы икәнен белгәч, Зария бер мәлгә югалып калса да, үзен тиз генә кулга алып өлгерде:

– Әй, Сафия, дөнья түгәрәк диләр, дөрес икән. Ни хәлләрең бар, кызый?

– Зария, синме бу, кыз?! Кай тарафта яшәп ятасың? Сине күрмәгәнгә дә биш былтыр...

– Башыңа төшсә башмакчы буласың икән, бердәнбер кызымны синең улыңа яучылап йөрим менә.

Сафиягә улы аркасында кызының нинди хәлгә таруын сөйләп биргәннән соң, ни җавап ишетәм дип куркып калган Зарияне булачак кодагый кочаклап ук алды.

– Никах була, Зария, монда эш пешкән инде. Бар, кайтып кызыңны тынычландыр. Әтисенә дә, Динарга да үзем әйтермен. Кара әле син аны, ирлегеләп иткән дә качканмы? Менә бит ә, кемне үстергәнбез диген. Бик азды шул ул, артык байлыкка чыдаша алмау шулдыр инде... Безне дә санга сукмый башлады. Ә кызың сине җибәреп дөрес эшләгән. Шулкадәр иркен тормышта яшәп, туачак оныгыбызның ярым ятим булып үсүенә юл куймаячакбыз!

Никах көне дә, загста язылышу вакыты да яшьләрнең үзләреннән башка гына хәл ителеп, өлкәннәр шул хәстәргә кереште. Булачак кода-кодагыйларның үзара килешү нәтиҗәсендә никах мәҗлесе кыз йортында үткәрелеп, туй мәшәкате тулаем егетнең әти-әнисе өстенә төшәчәк иде. Никах укытырга ике көн калгач, Динар, берни булмагандай, Әдиләләргә килеп керде. Ясалма елмаеп, хәл-әхвәлләрне сорашкан булды. Телен көрмәкләндереп булса да, озак килми йөргәне өчен гафу да үтенгәндәй итте.

– Безне әти-әниләр белән туганнар көтә, сине алып килергә куштылар, – диде үзенең килү максатын ачыклап.

Әдилә бераз икеләнгәннән соң, күңеле тартмаса да, Динарга ияреп машинага чыгып утырды. Юлда барганда Динарның килделе-киттеле сүзләреннән икеләнүе көчәя генә барса да, ни булса шул булыр, әти-әнине күпме утка салырга була, бәлки, яшәп китәрбез әле, дигән уйлар белән үз-үзен юатырга тырышты...

Хан сараедай зур йорт капкасыннан килеп кергәч, Динар, күр, без ничек яшибез дигән кыяфәт чыгарып, машинадан башта үзе төште һәм, уңъяк ишекне ачып, Әдиләне күтәреп аягына бастырды да, ычкынып китмәсен бу дигәндәй, җайсыз гына култыклап та алды. Мәрмәр баскычлардан күтәрелеп, затлы металлдан эшләнгән ишек ачылып китүгә, әти-әнисе, туганнары урынына кунак бүлмәсендә кәеф-сафа корып утырган өч-дүрт исерек егетне күргәч, бер мизгелдә күз аллары караңгыланып китеп, башыннан әллә нинди шомлы уйлар узган кыз, куркуыннан калтырап:

PRESSA

– Динар, кемнәр бу? Әти-әниең кайда? Ник мине мондый мәҗлескә алып килдең? – диярлек көч тапты.

– Ха, какие родители, я сегодня устроил мальчишник. Сначала познакомишься с моими друзьями, вместе отметим наш никах. У нас общаг. Пусть мои друзья тоже попробуют такую сладость, как ты!

Ул да булмады, дусларым дигәннәренең берсе, маймыллана-маймыллана:

– К вашим услугам, мин Вадим булам, – дип, үзе белән таныштырып, кулындагы чәркәсен Әдиләгә сузды. – Динар сайлый белә красоткаларны. Лакомый кусочектан авыз итә калсак, Динарның иң преданный дусты буларак, мин беренче булырмын, надеюсь.

Шайтан суыннанмы, башка нәрсәдәнме күзләре калайланган бу иблис токымын күргәч, кылт итеп исенә төшкән Ләйләнең сүзләре Әдиләнең миен бораулап алды: оле җәй көне үк Әдиләнең Динарга карата хисләреннән хәбәрдар булган Ләйләнең кисәтүе рас килде кебек. Телефоннан сөйләшкәндә: «Сак була күр, Динар наркотиклар да куллана бугай ул», – дигән иде.

Хәле китүдән куллары белән ишек тоткасына ябышып чак басып торган Әдиләнең саклану инстинкты югалганнан-югала бара. Динарда Әдилә кайгысы юк.

– Что застряла у порога, проходи, привыкай к такой жизни, ты же сама добивалась роскошной жизни, – дип, табындагы дуслары янына ашыкты. Ишек катына дус дигәннәрнең тагын берсе чыгып, инде икәүләп Әдиләне эчәргә кыстый башладылар. Бусының оятсызлыгы чик-чаманы белми торган булып, куллары белән Әдиләнең күкрәгенә үрелгән иде, кыз, җан ачуы белән тегене этеп җибәргәндә, бар гәүдәсе белән ишеккә терәлүе булды – ишек ачылып китте. Әдилә тышка атылды. Бер-ике адым атларга өлгермәде, галәмәт зур овчарка өреп килеп чыкты. Шушы эт тарафыннан ботарлап ыргытылган гәүдәсе күз алдына килеп басып, ничек йөрәге ярылмагандыр?!

– Рекс, нельзя! Ко мне! – дигән кырыс тавышка туктап калган эт, борылып, капкага таба чапты. Әдиләнең исән-имин калуына сәбәпче булган хуҗалар, өйдә хәвеф-хәтәр барлыгын сизгәндәй, хәлиткеч минутта кайтып керделәр. Машинадан сикереп төшеп, абына-сөртенә атлаган Сафия ханым Әдиләне кочаклап ук алды:

– Ни булды, балакай?! Әдилә сездәме дип, кодагый шалтыраткач, ни дияргә белмәдем. Динар безгә никах алдыннан дусларым белән утырып алабыз дигәч, каршы килмәскә булып, үзебез дә бераз ял итәрбез дип, дусларыбызга кич утырырга китеп барган идек. Сине алып киләсен әйткән булса, өйдән чыгып китә идекме соң без?!

Сафия ханымның кочагына сыгылып төшкән кызны Фәрит ага тотып калды. Үзен берни булмагандай итеп тота белгән Динар да көтмәгәндә кайтып кергән хуҗалардан шүрләп калган дуслары белән өйалдына чыгып баскан иде инде. Әле генә үзләрен секс бомба санаучы калай әтәчләр, хуҗаның ачулы карашы белән очрашудан куркып, тизрәк чыгып таю ягын карадылар. Улының чираттагы башбаштаклыгын күреп, ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җиткән Фәрит ага ир-ат көче белән кизәнеп Динарның яңагына сугып җибәрде. Әнисеннән кисәтү ишеткәндә дә, әтисен үз ягына аудара белеп яшәргә күнеккән Динар, гомерендә беренче тапкыр әтисе сугып җибәргәннән түгел, ә бәлки, әтисенең күз карашында чагылган ләгънәт угыннан куырылып, җебеп төште.

– Сафия, Әдиләне өйгә алып кер. Тынычлансын, чәйләп алыгыз! Бу малай актыгы белән ничек сөйләшергә икәнен мин үзем белермен.

– Кызым, Әдилә! Монда булган хәлләрне кодагыйга сөйләп, зинһар, әниеңне хафага сала күрмә инде, яме, – диде Сафия ханым.

– Иии, Сафия апа, бу хәлләрдән соң нинди никах турында сүз булуы мөмкин?! Ул бит мине мыскыллауның соңгы чигенә җитеп, сине минем дусларым да татып караячак, безнең барысы да уртак диде. Шул кешене ничек мин үз ирем итим?!

– Алай кырт кисмә әле, Әдилә! Туачак сабыең, безнең бердәнбер оныгыбыз хакында уйла. Никахсыз туган балаңа зинадан туган ярлыгы тагылачак. Аннары Фәрит Фарисович та районның күренекле кешесе, аның абруена да тап төшермәскә иде бит. Бердәнбер дә булгач, әтисе кирәгеннән артык ирек куйды шул! Хәзер аның бар өмете – туачак оныгында. Их, оныклар күрү бәхетенә ирешсәк, белер идек ничек тәрбияләргә, ди.

Ата үз дигәненә ничек ирешкәндер, кул беләнме, тел беләнме, Динар ишектән керә-керешкә Әдилә каршысына тезләнеп, гафу сорарга кереште.

– Адиля, прости, пожалуйста! Это же шутка была. Мои друзья просто играли на твоих чувствах. А я тебя обожаю. – Аннары әнисенә карап: – Мам, ты же хорошо знаешь моих друзей, все замечательные ребята.

– Нинди мам булыйм мин сиңа? Авыз тутырып әни дип тә әйтә белмисең бит. Атаңның бил каешы эләкмәгәнгә игелексез бала булып үстең син. Дусларыңны әйтер идем тагын, барысы да үз ишләрең – бездельниклар! – Сафия ханымның сүзләрен куәтләп, Фәрит ага да үз фикерен ярып салды:

– Моннан ары берсенең дә эзе булмаячак минем йортымда! 25 кә җитеп тә акылга утырмагач, үзеңнең дә һәр адымың контрольгә алыначак. Бу соңгы сүзем!!!

Динарның икейөзләнеп гафу үтенүләре әтисенең басымы астында гына икәнен яхшы аңлаган Әдилә, бернинди үгеткә дә карамыйча, булачак никахтан баш тартып, өенә кайтып китә ала иде, билгеле. Ләкин килен булып төшкәнче үк үз кызларыдай кабул итеп, үзен дә, туачак сабыен да яман ярлык тагылудан араларга әзер торган мәрхәмәтле ата белән ананың гозеренә каршы ничек каршы килсен.

Күз яшьләре белән башланып, ай буе яшь койдырган гыйнварның соңгы көне туй белән тәмамланды. Динарның никахлы һәм законлы хатынына әйләнгән Әдилә зур йортка килен булып төште. Килен булып төшүенең беренче атнасында ук кайнана өч айлык көмәнле Әдиләне таныш гинекологына алып китте.

Озак кына караганнан соң, УЗИның ике яралгы күрсәтүен әйткән табибка Сафия ханым сөенчегә дип акчалата бүләк сузганда, ике диган сүзне ишеткән Әдилә чак һушыннан язмады. Динарга хатын да, бала да кирәк түгеллеген белгәнгә, бала туганчы торырмын да, аннан аерылырмын, бер баланы ничек тә үстерермен әле дип күңеленә киртләп куйган иде ул.

Әдиләнең карынында ике яралгы үсә дигән яңалыкны кайната белән кайнана үзләренә күк капусы ачылгандай кабул итсә, үзем генә, үземә генә дип яшәргә күнеккән Динар, киресенчә, бу хәбәрдән көнчелек чиренә сабышты. Ата-ана байлыгын хәтта шул яралгылар белән бүлешү дә аның өчен үлем белән бер иде.

Тагын ике айдан карындагы сабыйларның берсе малай, берсе кыз икәнлеге ачыкланды. Сөенечләреннән нишләргә белмәгән Фәрит белән Сафия ничек тә Әдиләнең кәефен күтәрергә, күңелен күрергә тырышсалар, Динар моңа үртәлеп, киресен эшли. Шактый юанайган Әдиләгә төсен җуеп тоныкланган күзләре белән карап тора да: «Ну и досталась мне женка, баба деревенская», – дип, кулын селтәп чыгып китү җаен карый.

Күпмедер вакыттан соң аның «энә»гә үк утырганы билгеле була. Бердәнбер улларының шушы афәткә дучар булуына үзләрен дә гаепле санаган ата белән ананың йөрәгенә кан сава... Биш-алты ай бергә яшәү дәверендә үзен ир хатыны итеп тоярлык иркә-наз күрмәсә дә, Динарга карап Әдиләнең дә йөрәге әрни. Вакыты белән ул аны кызганып та куя. Тайгак юлдан китмәсә, нинди асыл ир-егет буласы да бит?!

Әле иллегә дә җитмәгән өрлектәй ир булган әтисе белән кырык бишен яңа тутырган, әле җиләк кебек чагындагы әнисе инде бар өмет-ышанычларын баглап, якты дөньяга аваз саласы оныкларын көтәләр. Динарга да, Әдиләгә дә туры килсен дип, йөз исем арасыннан Данияр белән Диләрә исемен сайлап куйдылар...

Һәм, ниһаять, җәйнең матур таңында Әдиләнең тулгагы башланып, тиз арада ашыгыч ярдәм машинасын чакырттылар. Динарның гадәттәгечә өйдә кунмавы сәбәпле, бала тудыру йортына киленен Сафия ханым озата барырга тиеш булды.

«Әдиләне урнаштыруга шалтыратырсың, сине үзем килеп алырмын», – дип калган иренең килеп җиткәнен көткән арада, унбиш-егерме минут элек үзләрен алып килгән ашыгыч ярдәм машинасы кабат тудыру йорты янәшәсендәге авыруларны кабул итү бүлеге ишеге төбенә үк килеп туктады. Сафия ханым, таң белән кайсы бәхетсезенә ни булган икән, дип уйларга өлгермәде, машинадан авыруны төшергәндә, носилкада авыз-борыныннан кан китеп аңсыз яткан үз улын күреп, җан авазы белән «әй балам, балам» дип сулкылдап, улы өстенә авып китә язды...

– Передозировкага охшаган – диде шәфкать туташы.

Көннең кыл уртасында бер-бер артлы ике сабый яшәү даулап җиһанга аваз салганда, бу шатлыклы хәбәрне хәсрәт дәрьясына күмеп, реанимациядә үз аңына киләлмәгән Динар 26 яшендә бакыйлыкка күчте...

* * *

Хикәямнең нигезендә моннан ун еллар элек булган вакыйгалар ятканга, укучыларны Әдиләнең бүгенге язмышы кызыксындырмый калмас. Хәзер Самарада яшәп яткан Әдилә, чын татар мохитен саклап, андагы милли җанлы татарлар белән бер казанда кайный. Килен булып төшкән йортында үзенә җил-яңгыр тидерми, балаларны карап-тәрбияләп үстерешкән кайнатасы белән кайнанасына мең рәхмәтле ул. Акыл иясе булган кайнатасы балаларга 3 яшь тулгач: «Кызым, синең үз тормышың булырга тиеш, кайсы шәһәрдән телисең, сайла, квартира алып бирәбез», – диде, килененә тормыш офыкларын киңәйтүдән курыкмаска киңәш итте. Әдилә Самараны сайлады. Үзе өчен бик якын булган туганнары Ләйлә белән Илдар гаиләсе дә Әдиләне үз яннарына китерәселәре килә иде. Ләйлә дигәннән, исегездә булса, хикәямнең башында унберенче сыйныфка күчкән кыз, бүген инде Самара шәһәренең күренекле клиникасында педиатрия бүлегенә җитәкчелек итүче балалар табибы. Язмышын гади авыл егете белән бәйләгән Ләйлә үзен бик бәхетле хатын-кыз итеп саный. Кулларыннан бар эш килгән Илдарның кечкенә булса да үз төзелеш фирмасы бар. 5 һәм 3 яшьлек ике уллары үсеп килә. Хикәямдә телгә алынган кунак кызы Энҗе турында да беләсегез киләдер. Инглиз телен камил белгән кыз Америкага ук китеп барган. Белем эстәвен Калифорния университетында дәвам итә.

Данияр белән Диләрә һәр каникул саен Нурлатка кайтып, дәү әти белән дәү әниләренең көтеп алган шатлыклы мәшәкатьләренә әйләнә-әйләнә, әле яңа гына унберне тутырдылар. Сафия ханымны балаларны артык иркәлисең дип ачуланса да, үзе дә кырыс булып кылана гына. Бердәнбер улларының төсе булып яралган оныклары өчен Раббыбызга рәхмәтле алар. Динарның фаҗигале вафатыннан соң дин юлына бастылар. Үз оныкларына да дини тәрбия биреп, милли рух сеңдерергә тырышалар.

Хикәямнең төп герое Әдиләнең Самарага китеп чын татар мохитен саклап яши диюем, тормыш офыклары киңәеп, үз күгендә бәхет булып балкыр өчен үз кояшының чыгуы белән бәйле. Самара зыялыларының балаларына татар теленнән дәресләр биреп йөргән Әдиләне татар иҗтимагый үзәгенә чакырдылар. Бүген ул укытучы да, оста оештыручы да... Күгендә балкыр өчен калыккан үз кояшы белән дә ул шушы үзәктә танышты. Дөресрәге, таныштырдылар. Егерме ел су асты көймәләрендә йөзгән Инсаф, хәрби пенсиягә чыккач, үзе туып-үскән Самарага кайтып төпләнә. Хезмәте аркасында гаилә кора алмаган егет буйдак исеме күтәреп кырыкка җитә. Аңарда үз телен өйрәнәсе килү теләге уяна. Милли җанлы туганнары аны шушы үзәккә алып килә. Калганы Инсаф белән Әдиләнең уртак сере. Уртак сер дигәннән, бу бәхетле гаиләдә тупырдап торган уртак бала – 3 яшьлек Әмир үсеп килгәнен әйтмәсәк, хикәябез тулы булмас иде. Күкләрендә үз кояшларының балкып торуына өметләнеп кавышкан ир белән хатынга бәхетле озын гомер телик.



ДАЛА КЫЗЫ

«Сөембикә ханбикә» дип сөеп искә ала аны халык. Һәм сагына. Ханбикәсе итеп тә, асыл килене итеп тә, далалардан ирек хисен сеңдереп үскән сөекле кызы итеп тә. Ә аның рухы яраткан халкына кабат-кабат кайта: дастаннар булып, башкаланың йөрәгендә урнашкан манарасына ай булып, югары сәнгать әсәрләре булып... Милләт кызларының күңел түрендә Сөембикә горурлыгы ята, ил агаларының йөрәгендә – фаҗигасе. Һәрбер яңа буынның хәтерендә аның язмышы кайтаваз булып яңара. Шуңа да «Сөембикә» операсы бөтен дөнья өчен мәдәни вакыйга булса, халкыбыз өчен ул хәтер яңарту, яраткан ханбикәсе алдында баш ию булып кабул ителә. Опера – сәнгать патшалыгының таҗы ул, чөнки әлеге сәнгать әсәре бик күп иҗат әһелләренең уртак иҗат эшчәнлегеннән туа. «Сөембикә» операсы да М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры җитәкчелеге башлангычы белән үз тирәсенә бик күп иҗатчыларны җыйды, берничә ел рәттән туктаусыз эш барды, һәм озакламый без бу эшнең нәтиҗәсен күрәчәкбез. 27 сентябрьдә М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрында «Сөембикә» операсының дөньякүләм премьерасы була. Операның музыка авторы – композитор Резеда Ахиярова, либретто авторы – Татарстанның халык шагыйре, Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Харис. Операның дирижеры – Ренат Салаватов, сәхнәгә куючы режиссер – Юрий Александров (Санкт-Петербург), художник – Виктор Герасименко (Мәскәү). Сөембикә партиясен Гөлнора Гатина башкара. Премьера турында сөйләшүне нәкъ менә аның белән башладык.

КАЙТА КАЗАНГА


«Алтын Урда» балетыннан күренеш. Шәрык биюе.

Гөлнора, Сезнең музыкаль гаиләдән икәнегезне беләбез. Әниегез Левиза Чалбашева Кырымның атказанган артисты, вокал җырчысы. Опера сәнгатенә ничек килдегез?

– Академик вокалдан башканы белми дә идем. Әнием беренче укытучым булды, Симферопольдә П. И. Чайковский исемендәге музыка училищесында аның классында укыдым. Җыр сәнгатенә мәктәптән үк кереп киттем, ләкин үземне беркайчан да эстрадада итеп күрми идем, шул ук вакытта опера да минем өчен ачык түгел иде әле. Нәкъ менә Казанда опера театрында үземнекен табуыма инандым. (Гөлнора Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә Зилә Сөнгатуллина классында укыган (2012). – *авт.*)

Сез 2012 елдан Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры солисты. Репертуарыгызда итальян, рус операларыннан рольләрегез дә бар. Шулай ук татар опералары да Сездән башка үтми. Образлар тудырганда, аерма сизеләме?

– Минем өчен теләсә кайсы опера үзе бер гомер кебек. Иң мөһиме: рольләремдә «яшәү»; итальян, рус, татар опералары дип аерып караганым юк. Һәрбер җырчы үзенең героен тоярга тиеш, алай гына да түгел, җырчының образга типаж ягыннан туры килүе дә мөһим дип саныйм. Югыйсә җансыз, «коры» вокал гына тыңларга туры киләчәк. Режиссер бу нечкәлекләрне дә тотып ала белә һәм шуны күрсәтә икән, аның кадерен белергә кирәк. Тамашачы өчен матурлык мөһим. Матурлык исә һәрнәрсәдә булырга тиеш: тышкы кыяфәттә, тавышта, актер уенында. Спектакль вакытында, актер үз урынында түгел, дигән уй ялгыш кына да булырга тиеш түгел.

Мин, актриса буларак, рольләремне бик җентекләп эшлим, образны сәхнәдә күз алдына китерәм. Әгәр дә үземне шул амплуада күрмим икән, ул рольгә алынмыйм. Роль тавышка гына түгел, ә эчке халәтемә дә, холкыма да туры килергә тиеш. Беренче чиратта – актерлыгым. Артык

PRESSA

Рәүфәл МӨХӘММӘТҖАНОВ, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, «Мактау билгесе» ордены кавалеры

– Россия дөнья күләмендә музыка жанрында, гомумән, сәнгатьтә саллы урын били. Опера театрының дөнья сәнгате пространствосында үз урыны бар. Рус опера мәктәбе ул итальян, немец, французларның опера мәктәбе кебек үк, югары музыкаль жанрның бер өлешен тәшкил итә. Татар мәдәнияте Россия мәдәнияте, ә Россиянеке дөньякүләм мәдәниятнең бер өлеше буларак, һәр яңа вакыйга бүгенге мәгълүмат заманында тиз арада яңгыраш ала, шуның белән дөньякүләм әһәмияткә ия була. Мәсәлән, безнең театрда куелган «Җәлил» операсын сентябрь аенда гына да Mezzo каналыннан өч тапкыр күрсәттеләр. Әлеге француз каналын бөтен дөнья карый. Рус опералары гына алыгыз: һәркайсы халык телендә йөргән таныш шәхес турында. Әгәр тамашачыдан: «Сөембикәнең кем икәнен беләсезме?» дип сорасак, ул бихисап риваятьләрне, аның Казан үзәгендәге символикасын искә төшерәчәк. Тарихи шәхес буларак, Сөембикә турында каршылыклы фикерләр, бәхәсләр әле дә тынмый. Бу образга бик күп иҗат кешеләре мөрәҗәгать иткән. Аның турында бик аз беләбез, хәтта аның йөз-кыяфәтен дә күреп түгел, ә риваятьләрдән генә чамалый алабыз: бик чибәр булган, диләр. Шунысы гына мәгълүм: аның язмышы бик катлаулы. Ләкин операда Сөембикә шәхесе генә түгел, Россия дәүләтенең формалашу тарихы да чагыла. Милли опералар гына түгел, гомумән, яңа опералар бүген сирәк туа. Әлеге идея барлыкка килүгә, Рөстәм Нургали улы Миңнехановка мөрәҗәгать иттем. Чөнки теләсә кайсы идеяне тормышка ашыру өчен ярдәм, хуплау кирәк. Опера – күп чыгымнар сорый торган жанр. «Сөембикә» операсы да күпләрнең иҗади тырышлыгы белән туды. Музыкасын Резеда Ахиярова язды, либреттосын Ренат Харис иҗат итте. Режиссеры – Санкт-Петербургтан Юрий Александров, сәхнәгә куючы художник – Мәскәүдән Виктор Герасименко. Башкаручыларыбыз төрле: яшьләр дә, өлкәннәр дә бар. Һәммәсе – үз эшенең осталары. Опера музыкаль яктан катлаулы, ике телдә җырлыйлар. Татарлар аралашкан сәхнәләрдә – татарча, руслар белән аралашканда – русча. Мәсәлән, Иван Грозный партиясе рус телендә башкарыла.



хәрәкәт ясамыйча да, бөтен барлыгың белән образыңны тоярга һәм шуны опера буена алып барырга була.

«Сөембикә» операсының премьерасы татар милли мәдәниятендә вакыйга буларак көтелә. Сөембикә – халкыбыз өчен кадерле образларның берсе. Операда Сөембикә партиясен башкаручы буларак, аны нинди итеп күрәсез?

– Беренче чиратта, Сөембикә минем өчен үз-үзен корбан иткән, әмма шул ук вакытта язмыш сынауларын горур күтәргән хатынкыз. Улы Үтәмеш өчен, бөтен халкы өчен җаваплылык шушы хатын-кыз җилкәсенә төшә. Аллаһка ышанычыннан кала, ярдәм итүчеләре дә юк, ә аңа Казан ханлыгын бердәнбер яклаучы да булырга туры килә!

Сез Урта Азиядә тугансыз, Кырымда үскәнсез. Еш кына «Казан – туган йортым кебек», дисез. Сөембикә дә Кырымнан була. Аның өчен дә Казан үз йортына әйләнә. Рольне өйрәнгәндә мондый уртаклыкларга игътибар иттегезме?

– Адәм баласының тормышында бернәрсә дә болай гына барлыкка килми, эзсез югалмый. Әйе, мин чыннан да Кырым далаларында – бабам Риза Чалбашевның туган җирендә үстем. Ул – ногай татары. Моны Сөембикә белән уртаклык дип кабул итәргәме, юкмы – анысын белмим. Ләкин Ренат Харис либреттосын укыганда, дала кызын күз алдына китерү җиңел булды.

Казан, һичшиксез, минем туган йортыма әйләнде, чөнки монда үземне иҗади шәхес, җырчы буларак таптым. Казан консерваториясен тәмамлап, шушында югары белем алып, бары тик татар репертуарында гына тәрбияләнеп, тормышымны әлеге мәдәнияттән башка күз алдына китерә алмыйм. Казан опера театрына килү белән эшләгән беренче ролем – хыялымда йөрткән «Шагыйрь мәхәббәте»нән Зәйтүнә булды. Резеда Ахиярованың «Сөембикә» дигән опера язуын ишетүгә, яңа әсәрнең нинди тавышка, нинди өслүбтә язылуын



Гөлнора ГАТИНА, опера җырчысы

■ П. И. Чайковский исемендәге Симферополь музыка училищесын (2007), Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен (2012) тәмамлаган.
■ 2012 елдан М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында эшли.
■ Ф. Шаляпин исемендәге вокал җырчылары фестивале лауреаты (Кырым, 2005 ел).
■ О. Петрусенко исемендәге вокал җырчылары конкурсы лауреаты (2008).
■ С. Сәйдәшев исемендәге вокал җырчылар конкурсы лауреаты (2008).
■ «Vissid'arte» халыкара вокал җырчылары лауреаты (Чехия, 2014).
■ Concorso Per Giovani Cantanti Lirici D'Europa – AsLiCo 67 нче яшь опера җырчылары конкурсы җиңүчесе (Комо, Италия, 2016).
■ Concorso Internazionale di canto lirico Federico II лауреаты (Италия, 2016).
■ Татарстанның «Тантана» театраль премиясе лауреаты (2016).
■ 2015 елның гыйнварында Эльмир Низамовның «Кара пулат» операсында Нәргизә партиясен башкара (Р. Харис либреттосы, режиссеры – Г. Ковтун).
■ 2015 елда Дж. Пуччининың «Мадам Баттерфляй» операсында Чио-чио-сан партиясе белән чыгыш ясый.

«Сөембикә темасы иҗатымда күптән бар иде. Разил Вәлиевнең «Сөембикә» шигыренә иҗат ителгән җырны Резеда Галимова, Венера Ганиева башкардылар. Ул җырны ишеткәч, миннән еш кына: «Бу җыр ария була аламы? Дәвамы бармы?» – дип сорыйлар иде. Ләкин ул мөстәкыйль әсәр. Шулай да Сөембикә, легендар шәхес буларак, һәрвакыт күз алдында тора, аңа багышлап опера язасы килә иде. 1999 елда Бату Мөлеков «Сөембикә» операсын язды, ләкин ул концерт башкарылышында гына калды.

Яңа опера турында сүз чыккач, кыенсынып кына әлеге теманы театрга тәкъдим иттем. Театр җитәкчелеге хуплап каршы алды. Ренат абый либреттосын язды. Либретто бик әйбәт килеп чыкты, текстны бик яраттым.

Сөембикә – минем өчен драматик, романтик образ, ул күпкырлы. Беренче чиратта, аны хатын-кыз буларак ачарга теләдем. Ул бик авыр, аяныч язмышлы хатын-кыз. Ул ярата белә, ләкин аны яратмаган кешесенә кияүгә бирәләр... Улы Үтәмешгәрәйне бик яраткан ана да ул. Искиткеч чибәр булган, диләр. Юмартлыгы турында сөйлиләр: килен булып килгәч, Казан халкын бик яраткан, укымышлы морза кызы буларак, халкының да укымышлы, зыялы булуын теләгән – халыкка китапханәсен бүләк иткән. Көчле ихтыярлы булуы, дөрес карарлар кабул итә белүе белән ул халыкның яраткан ханбикәсенә әверелә. Гомумән, операда ул татар халкының, татар хатын-кызларының иң матур сыйфатларын туплаган символик образ булып бара...»



Резеда АХИЯРОВА, Россия һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай премиясе лауреаты

белгәнче үк, мин бу рольне җырларга тиеш, дип эчтән генә хәл иткән идем. Тиеш, чөнки татар операсын бик яратам һәм хәзинәбезнең нәкъ менә шундый әсәрләр белән тулылануына бик сөенәм.

Гөлнора, Сез чит илләрдә еш буласыз. 2016 елда Италиядә Concorso Per Giovani Cantanti Lirici D'Europa яшь опера җырчыларының халыкара конкурсында җиңеп, Европа буенча турне оттыгыз. Татар, рус, инглиз телләреннән тыш, итальянча да сөйләшәсез. Бер илдән – икенче илгә, бер телдән икенче телгә күчәргә туры килә дигәндәй... Мондый ритмга ничек күнегәсез? Һәм көннәрдән бер көнне читтә торып калмассызмы?

– Безнең һөнәр төрле илләрдә озакка калып эшләү белән бәйле. Әлбәттә, бик җиңел дип әйтеп булмый... Миңа ул физик яктан түгел, ә күңел халәтем ягыннан авыррак бирелә. Теләсә кайсы иҗат кешесе өчен якын кешеләренең, туганнарының янәшәдә булуы мөһим. Хәзер инде бу ритмга ияләштем, күбрәк иҗат дип яшим. Рухыма, җаныма якын кешеләр белән эшлим, аларның фикерләү рәвеше иҗади, бөтен булмышлары белән яраткан эшләренә бирелгәннәр. Алар минем төрле илләрдәге хезмәттәшләрем, укытучыларым. Ярату һәм иҗатка тугрылык берләштергән тандемнар кешене үстерә, мин дә шуның белән яшим, рухланып иҗат итәм. Чит илдә яшәп калыр идемме дигәндә, бу минем өчен зур мәсьәлә. Һәркемнең үз өе була. Аны үстергән, тәрбияләгән, укыткан өе. Ярату, мәхәббәт биргән өе. Боларның барысын да миңа Татарстаным бирде.

Ландыш ӘБҮДӘРОВА.
Фото: Ольга ЛАУТ
һәм театр архивыннан.



Ренат ХАРИС, Татарстанның халык шагыйре, Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

« Сөембикә ханбикә – дөнья тарихында иң күренекле хатын-кызларның берсе. Ул – беренчеләрдән булып мөселман дәүләтләрендә ил белән идарә иткән хатын-кыз. Бүген аның дәүләт эшчәнлеге хакында төрле карашлар бар. Ләкин тарихи шәхесләрнең, хәтта иң бөекләренең дә бик сирәге генә халык теленә керә, риваятьләргә әверелә. Сөембикә үзе исән чакта ук татар халкы аңа багышлап бәетләр чыгарган, җырлар җырлаган. Безнең чорда да аның турында әдәби әсәрләр дә, фәнни хезмәтләр дә туа торалар. Хәтта Казан Кремленең күрке, башкалабызның архитектур символы булган гүзәл манарага да аның исеме береккән. Нәрсәсе белән халык күңелен яулаган соң ул? Әлбәттә, трагик язмышы белән! Әлбәттә, фидакарьлеге, ватандарлыгы белән! Әлбәттә, дөрләп киткәч кенә сүнгән мәхәббәте белән! Безне, опера авторларын һәм театрны Сөембикәнең кеше, ана, сөйгән яр буларак язмышы җәлеп итте.

Казан ханлыгының иң катлаулы чоры – мөстәкыйльлеген югалту фаҗигасе – Сөембикә йөрәге аша үтә. Аның ире Сафа-Гәрәй хан үлеп китә. Сөембикә 4 яшьлек улының – Үтәмеш ханның – регенты булып кала. Хөкүмәт, Мәскәү тарафдарлары һәм Кырым тарафдарларына бүленеп, илне ике якка аера, аның нигезен чатната. Илгә сугыш куркынычы яный.

Казан ханлыгы исән калсын дип, Сөембикә ханбикә үзен корбан итә – канкоешны булдырмау, илнең мөстәкыйльлеген саклап калу шарты белән ул үзен Мәскәүгә әсир итә, ләкин бик каты алдана.

Бәхеткә дип туган дала кызын, / Тәхет биреп, газап чиктердең, – дип, язмышына үпкә белдерә Сөембикә. Мәхәббәт дәрте ташып торган 32 яшьлек гүзәл хатын ир назыннан мәхрүм булу газабына дучар ителә.

Ике ханга мин ханбикә булдым, / Ир хатыны була алмадым, – дип сыкрана, өзгәләнә Сөембикә. Аны Казанның дошманы Шаһ-Али ханга ирексезләп кияүгә бирәләр, улын чукындыралар, Александр дигән исем кушалар...

Менә шундый хәлләр Сөембикәне татар халкының сөекле ханбикәсе итә, җырларына, бәетләренә кертә, риваятьләргә әверелдерә. Аның аянычлы язмышы бүген дә безне дулкынландыра, уйландыра һәм илһамландыра да.

Мине чит дәүләтләр көче белән үз иленә бәхет китерергә тырышу проблемасы да кызыксындыра, борчый. Бу проблемага без «Алтын Урда» балетында да кагылган идек. Морза (тарихи Идегәй) үзенең илен Аксак Тимер гаскәрләре ярдәмендә «бәхетле» итәргә уйлый, ләкин җимерттерә генә. Шул фаҗига, ахыр чиктә, урта гасырларның иң бөек дәүләте булган Алтын Урданы һәлакәткә китерә. Тарихта да, безнең операда да шундый эшне Казан тәхетеннән берничә мәртәбә куылган Касыйм ханы Шаһ-Али башкара. Ул Иван Грозный гаскәрләре белән Казанны ала, ләкин аның тәхетенә утыра алмый. Ул да алдана. Бу – бүгенге көн өчен дә бик гыйбрәтле хәл, минемчә.

Тарихи вакыйгаларга нигезләнсә дә, персонажлары тарихи шәхесләр булса да, «Сөембикә» операсы документаль әсәр түгел. Без, авторлар, бу әсәр белән тамашачыны теләсә нинди чорда да үзгәрешсез кала торган, адәми затны кеше дәрәҗәсенә күтәргән, һәркемнең дә йөрәгендә яшәгән саф хисләр, катлаулы кичерешләр, мәңге ару-талуны белмәс бәхеткә омтылышлар һәм язмыш белән көрәшү мохите аша үткәрергә теләдек. «Сөембикә» – горур рух әсәре. »

«ЯХШЫ КӘЕФ БЕЗДӘН БАШЛАНА!»

«Татар радиосы»ның әлеге сәламләве белән берничә буын үсәргә өлгерде дә инде. Һәм менә 23 август көнне Казанның Таулар-Әмәт урман-паркында 100,5 FM ешлыгында яңа форматта эшләүче радиостанцияләр челтәре үзенең тыңлаучыларын туган көненә җыйды. Дөресрәге, туган көн уңаеннан оештырылган зур бәйрәм иде ул.

Ачык һавада җәйге хитлардан торган Зур концерт, радио ешлыгында яңгыраган җырларның кайта-кайта кабатлануы, интерактив бәйгеләр, лотерея уены... Бәйрәм әнә шундый күңелле мизгелләре белән ерактан ук үзенә чакырып тора иде. Концертны «Татар радиосы»ның танылган диджейлары Гөлназ Сәфәрова белән Айваз Садыйров алып барды. Иркә, Салават Миңнеханов һәм Гүзәлем, Алсу һәм Азат Фазлыевлар, Ришат Фазлыйәхмәтов, Эльмира Сөләйманова, Хәмдүнә Тимергалиева кебек популяр җырчыларның чыгышларын җыелган халык алкышларга гына күмеп калмады, үзләре дә җырлап-биеп күңел ачты. Бар да нәкъ туган көндәгечә! Бәйрәмне сабын куыклары, шарлар, Микки Маус курчаклары, кәгазьдән эшләнгән зур чәчәкләр бизәде. Кунаклар бушлай аквагрим ясатты, фотоавтоматта фотога төште, фудкорт, ягъни ашау-эчү зонасында тәмле ризыклар белән сыйланды. Парк капкасыннан керүгә үк бәйрәм рухы һәркемне рәхәт бер дулкынга күчерде.

Туган көн бүләксез булмый, ләкин «Татар радиосы» тыңлаучыларына үзе сюрприз әзерләгән: уеннарда катнашып, һәркем бүләк ота ала иде. Шулай ук лотерея уенында бәхетеңне сынап карау мөмкинлеге дә бирелде. Иң зур бүләк – «Бәкер» шифаханәсенә ял көннәренә тур юлламасына Алсу Габдрахманова ия булды.

Таулар-Әмәт паркында, хәзергечә әйтсәк, Open Air форматында узган бу бәйрәм казанлыларның хәтерендә иң күңелле җәйге кич булып калыр, мөгаен. Алар янә рекорд куйган: 30 меңнән артык кеше килгән. «Татар радиосы»ның туган көне башкалабызда көтеп алына торган бәйрәмгә әйләнәчәк дигән фикердә оештыручылар. Киләсе елга ул киңрәк масштабта, тагын да күбрәк йолдызлар белән үткәреләчәк дип ышандырып кала алар.

Фото: Александр Шарагин, sharagin.ru















Лилия Сәгыйдуллина Башкортстанның Шаран районы Иске Тамъян авылында матур табигать кочагында, җыр-моңга уралып үскән. Шуңа һәр сүзе, җиткерәсе фикере шигырь юллары булып бөреләнә. Игътибарыгызга Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы мөдире, педагогика фәннәре кандидаты Лилия Сәгыйдуллинаның яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА

САГЫНДЫМ МИН!

* * *

Буриданның ишәгедәй
Ике якка тартылам:
Авылга да кайту кирәк.
Монда да эш тау сыман.

Мондагысы көтеп торыр!
(Без китсәк тә – эш кала...)
Анда әнкәй өзелеп көтә –
Әйтерсең сабый бала.

Сиздермәскә тырышса да,
Көне-төне көткәнен,
Сөйләп тора, көйләп тора
Нурланган өйнең яме.

Сиздермәскә тырышса да –
Әзерләгән табынын.
Эшләргә тиеш эшләр дә
Мине көткән сагынып.

«Күпмегә кайттың, кызым?» – ди.
Күпкә булса – шатлана.
Тагы кайтыр көнне саный,
Чыкканчы ук капкадан...

Минутка сәгать сыйдырам.
Барча эшкә өлгерәм.
Әнкәй янындагы чактан
Мизгелләп гомер чигәм.

Киткән чакта шул чигүне
 Күңелемә саламын.
...Йөрәк, бахыр, белми әле
Чигү генә каласын.

Күзгә күзгә каршында...

Мин күзгегә карарга да куркам!..
Кулларымда – йөз мең җыерчык.
Даһи рәссам салган сурәт нигезе –
Ай һәм еллар сипкән кыйпылчык.

Мин күзгегә карарга да куркам.
Кем уйласын, бу йөз – мин диеп.
Күңелдәге мәңге унҗиделек
Шушы күзгеләргә тиң диеп.

Мин күзгегә карарга да куркам.
Күзгә күзгә бигрәк аяусыз!..
...Күлкә булмәсендә йөрибезме?
Хакыйкатьме шундый – буяусыз?..

«Мин күзгегә карарга да куркам!..» –
Дип язылган унбиш ел элек.
Бүген күзгә, көлеп, күзен кыса:
Ачыласы сере бар кебек...

Сагыш

Сине шундый сагындым мин!
Соксыз калган Сак инде мин.
Җиләк түгел, как инде мин.
Җансыз сурәт хәлендәмен.

Бу сагыну дәрья буар.
Җилгә атсам, давыл чыгар.
Җир-Күкләрдә туфан кубар.
Бу сагышка кем, ни чыдар?

...Ишек ачсаң беркөн килеп
Һәм җан өрсәң миңа – үбеп,
Әкияттәге сылу кебек
Уянырмын. Мең кат үлеп.

Кабат: «Син!..» – дип кабынырга,
Кабат сине сагынырга,
Кабат сиңа табынырга.

Уйдырмам

Мин бит сине уйлап таптым.
Уйлап таптым булмышыңны.
Үземчә бер җайга салдым
Миңа чит-ят тормышыңны.

Шул дөньяңа ямь өстим, дип,
Кердем күңелең бакчасына.
Синең хакка әверелдем
Илаһият чәчкәсенә.

Хозурланды дөньяларың –
Хәйран калдың могҗизага.
Бу гаҗәеп серне ачу
Мөмкин иде сиңа гына...

Мөмкин иде... Мөмкинлекләр
Белән чынлык арасында
Бәхет кошы бәргәләнде,
Очалмый бер канатында.

Башкаларга син – бары син.
Минем өчен – гайре үзгә.
Исем-атсыз үлән дә гөл,
Сөю белән баккан күзгә.

...Мин бит сине уйлап таптым –
Һәм җан өрдем уйдырмага.
Менә кинәт нур өзелде.
...Экранымда – яңа кино.

Лилия Фәттахова исеме инде күпләргә яхшы таныш. Журналларда һәрдаим шигырь, хикәяләре күренеп тора. «Танырсыңмы?» исемле шигырьләр китабы белән дә укучыларын сөендерде инде. Шигырьләрендә һәрчак ниндидер үзгә яңалык, мәхәббәт, сискәндереп куя торган тирән фикер, уйландыра торган фәлсәфә, туган тел язмышы... Аңлашыла да: «Иң яхшы укытучы», «Педагог-остаз» исемнәрен алган мактаулы укытучы да бит әле ул! Лилия Яңа Чишмә балаларына татар теле һәм әдәбияты, тарих, җәмгыять белеме фәннәрен укыта, район мәгариф бүлегендә методист булып эшли. Ә иҗат, шигърият – аның мәңгелек юлдашы.



Лилия ФӘТТАХОВА

КАДЕРЛЕДЕР ЯШӘҮ

* * *

Ә мин көн дә
Бераз гына бүтән...
Бераз гына бүтән
уйлар уйлыйм,
Бераз гына бүтән
көйне сүтәм...
Ялкып киткән
йөрәк белән бергә
Акыл чуалдырган
уем тетәм...
Йөрәк белән
уйлыйм бугай хәзер...
Бераз гына башкачарак кичем,
Бераз гына башкачарак иртәм...
Саксыз кагылганым өчен кичер –
Тик шул уем үзгәртмичә йөртәм...

* * *

Күктән төшкән
бер нур-җепкә
тоташканга җан кендеге,
Шулкадәрле серле микән,
Шулкадәрле кадерлеме
яшәү?!

Ярый әле өзелми ул,
Кем искәртер кемлегеңне?!
Кемнәр сиңа дәшәр?...

Түзә күкләр
кабат-кабат
тулгагының газабына.
Нурга нурлар тоташканга
азагында...
түзә...
Түзә күкләр
Җан авазын
тоеп күзләр карасында...
Белә күкләр
(белә күпләр!)
газаптан соң
Галәм кочар
зур бәхеткә тарасын да...

Күктән төшкән
бер нур-җепкә
тоташканга җан кендеге,
Шулкадәрле серледер ул,
Шулкадәрле кадерледер
яшәү!..

Хәзер беләм...

Таныйм инде,
Таныйм хәзер...
Булды андый гөнаһ:
гомеремнең бәһасенә
шигем үсте борнап...

Көннең яме беткән иде,
Яшәвемнең тәме...
Тып-тын гына
югалырга
исәп иде... әйе...

...Сискәндереп хәбәр килде:
«Кыл өстендә гомере».
Котым очып көтәм менә
Яралтучы әмерен.

Син дә мине
Югалтудан
Шулай куркыр идең...
Хәзер беләм...
Ә ул чакта...
Мин бит сукыр идем.

Хәзер беләм –
Зуп-зур дөньяларда
кеп-кечкенә кеше
Җиһан чаклы
бушлык ясый ала...
Ишетәсеңме?
Ишет!..

* * *

Яшибез без,
гүя, угры-бурлар...
Җаныбызның ак нурларын урлап,
Яшергәнбез күңел түренә...
Яшәвебез
сәдакасын җәлләп
өләшүче фәкыйрь көенә...

Ә бит бай без!
Никадәр нур анда!
Никадәр зур анда хәзинә...
Юл кисешкән саен
бер елмайсаң,
Кул бирешкән саен
бер елмайсаң,
Уй бүлешкән саен
бер елмайсаң,
Һәм елмайтсаң шунда әз генә –
Яктырыплар китәр иде Җиһан
Якты уйлы елмаюлар җыйсаң!
Һәм эләлсәң дөнья күзенә...

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Кечкенә генә Яңа Байлар авылыннан Бөек Ватан сугышына 110 кеше чыгып китә. 41 е генә исән-сау әйләнеп кайта. Ә быел Бөек җиңү көнен каршылаганда Мәхмүтҗан абый Сабиров кына исән иде.

Минзәлә районының Яңа Байлар авылында 1926 елда дөньяга килә ул. Сугыш башланганда үсмер малай гына була әле. «1941 елның җылы, кояшлы июнь иртәсе. Без иркен өйалдыбыз идәнендә абыйлар белән рәхәтләнеп йоклый идек. Кинәт әнинең кайгылы тавышын ишетеп торып утырдым. Ул кемгәдер: «Герман безгә каршы сугыш башлаган, өч кешегә сугышка китәргә хәбәр килгән», – диде. Абыйлары Имаметдин белән Галләметдинне беренче көннән үк диярлек сугышка озаталар. Мәхмүтҗан өйдә берданбер ир булып кала. Урман кискәндә әтиләрен агач басып үтерә. Әнисе белән бергә колхоз эшенә йөри Мәхмүтҗан. Үсмер егеткә йөк ташу эшен билгеләп, ат бирәләр. «Камыт кидерергә буй җитмәгәч, бүкәнгә басып җигә идек атны», – дип искә ала Мәхмүтҗан абый.

Ул арада фронттан кара мөһерле хатлар килә башлый. Мәхмүтҗаннар капкасын да кага кайгы – абыйсы Имаметдиннең батырларча һәлак булуы турында хәбәр килә. «Шундый авыр кичердек без бу кайгыны. Моңа кадәр әтине югалту хәсрәтенә дә бөгелеп төшмәгән әнкәйне тәмам кара сагышка салды ул. Көне-төне, тизрәк сугышка җибәрсеннәр иде, абыем, илем өчен фашистлардан үч алам, дип үрсәләнә идем», – дип искә ала ветеран.

Сугыш тәмамланырга бер ел калгач, Мәхмүтҗан Сабировны да хәрби хезмәткә алалар. Кара диңгез флотына – Феодосия шәһәренә эләгә ул. Шәһәрне фашистлар җир белән тигезләгән: кая карама җимерелгән йортлар, яндырылган корылмалар. Үлгән кеше гәүдәләре, эт үләксәләре сасып ята...

«Шәһәрдән фашистларны куганнар иде инде. Абыем өчен үч алу насыйп булмады. Аның каравы, шәһәрне торгызуда үземне аямыйча эшләдем. Аннары безне Украинага күчерделәр. Монда да шул ук хәл: яндырылган авыллар, шәһәрләр пыскып ята, өйләр җимерелгән, исән калган кешеләр шәүләләр кебек – көч-хәл йөри... Сугыш җимерекләрен торгызуда тәүлекләр буе эшләдек, тиз арада йортлар торгызыла башлады. Бүген хәйран калам: шул җирләрдә кабат җимерүләр бара. Ачы хикмәте шунда: читтән килеп түгел, үзләре үк җимерә, – ди Мәхмүтҗан абый, күңеле әрнеп. – Сугыш беткән көнне мәңге онытасым юк. Башта бу хәбәрдән югалып калгандай булдык. Аннары солдатлар, сөенечтән, һавага ата башлады. Шул пулялардан озак кына бөтен дөнья яктырып торганы хәтердә».

Туган авылына 1950 елда гына кайта ул. Аннары, җиң сызганып, элеккечә атлы эшкә алына. Күрше авыл кызы Минәмирә белән гаилә корып җибәрәләр, ике ул, бер кызлары үсә. Тик менә бер улларының вакытсыз вафат булуы гына җаннарын көйдерә.

Бер-берсен хөрмәт итеп, 37 ел матур гомер итте алар. Минәмирә апаны бакыйлыкка озаткач та, шәһәрдән кайтып йөрүче балаларын катык-сөттән аермас өчен, берүзе сыер асрады Мәхмүтҗан ага.

Хөкүмәт аңа шәһәрдән фатир да бирде, әмма ветеранның гомер иткән йортын ятим калдырасы килмәде. Туган авылы аның өчен иң газиз җир. Оныклары һәм турунналары үсеп килүгә шатланып, күкрәгенә медальләрен тагып, тагын күп еллар Җиңү бәйрәмнәрен каршыларга язсын әле аңа.

Тәнзилә ШӘЙХНУРОВА.
Минзәлә районы, Күзкәй авылы.

Бүген бик күпләр ялгыз яши. Авылга кайтсаң, егетләрнең ялгыз картаюын, ә шәһәрдә күбесенчә уңган-булган, фатирын да, машинасын да булдырган хатын-кызның ялгыз гомер итүен күрәсең.

Үз-үзен белештерә башлауга, һәркем бәхетен эзләргә керешә, тормышка булган максатларын билгели. Кемгәдер ул, беренче чиратта, тормыш кору. Ә кемдер башта үз юлын табарга аннан соң гына гаиләле булырга омтыла. Әлбәттә, бу очракта гаиләдә алган тәрбия дә зур урын алып тора. Мәсәлән, мин үскәндә әти-әнием: «Кызым, башта югары белем алырга кирәк, аннан соң тормышка чыгуны уйларсың», – ди иде. Ә күп кенә яшьтәш кызларым 18–20 яшь арасында, кайсы үлеп гашыйк булып, кайсы «ябышып», кайсы егетнең «яхшы вариант» икәнен чамалап, тизрәк тормыш кору ягын карады.

Институтны тәмамлаганда башта эшкә урнашу, аннан сайлану чоры башлана... Төрле сәбәпләре табылып, ялгыз калу «куркынычын» тоя башлагач кына тормыш корып куя кайберәүләр (үзем дә шундыйлар рәтеннән).

Без университетка укырга кергәч, тулай торак бүлмәсендә дүрт кыз урнаштык. Барыбыз да беренче курс студентлары, барыбыз да математикага гашыйк, һәрнәрсәдә төгәллекне яратучы кызлар (миннән кала барысы да шәһәр кызлары). Авыр, җитди фән өлкәсенә кереп китүебезне аңласак та, яшьлек яшьлек инде. Күңелле студент тормышы, студентларның төзелеш отрядлары, походлар, гашыйк булулар, гаилә кору турында хыялланулар – берсе дә безне читләтеп үтмәде. Әнисе белән генә үскән (әтисе белән аерылышканнар) Гөлиябез генә егетләр белән аралашуны юкка вакыт уздыру дип саный иде. Режиссер Юрий Чулюкинның «Девчата» фильмындагы кебек, барыбыз гөрләшеп кайтып кергәндә Гөлия бүлмәдә йә дәресен карый, йә кул эше (ә кул эшләренә осталыгы искиткеч!) белән утыра. Безнең белән бию кичәләренә дә, киноларга да баруны кирәк тапмады ул. Вакыт уза торды, беребез – өченче курсны бетерүгә, икенчебез – институт тәмамлауга, мин шактый «акыл» кергәч – тормыш кордык. Барыбыз да Казанда төпләндек, аралашып яшибез, Гөлиябез генә һаман ялгыз иде.

Аның ялгыз калу сәбәпләре һәрберебезгә ачык та кебек: әнисе генә үстергән, ирләргә үпкәләбрәк карый, алар белән очрашуны бушка вакыт уздыру сыман күрә. Ул гел яхшы укыды, максатчан, хыялларын чынга ашыра белә (фатир, машина алды, туристлык агентлыгында дәрәҗәле менеджер булып китте, чит илләргә елга дүрт-биш тапкыр бара), тик менә ялгызлыгы...

Беркөнне Гөлиябез өйләнгән кешегә гашыйк булды. Хәзер аның телендә гел ул гына иде. Тик, кавышканчы, Гөлиягә аның өченче тапкыр аерылуын көтәргә туры килде. Дүртенче тапкыр өйләнүче Артурны «төпле түгелдер» дип шикләнүебез юкка булды. Алар барыбызга да үрнәк булырдай гаилә кордылар. Үз йортларын булдырдылар, бакчаларында менә дигән итеп җиләк-җимеш, яшелчә үстерәләр, чит илләргә йөриләр, Артурның беренче никахыннан туган баласы белән аралашып яшиләр. Без барыбыз да аларга кунакка киләбез (чөнки ачык йөз белән, ихлас каршы алганнарын беләбез). 40 ка җиткәндә үз тиңен тапкан Гөлиябез өчен без бик шат. (Кызганыч, Гөлиянең әнисе генә кызының бәхетле көннәрен күрә алмады.)

Иптәш кызымның үз бәхетен таба алуына ихлас сөенеп, бу язмам аша башкаларда да ышаныч тудырасым килә. Мәрхүм әтием туйларда теләк теләгәндә, гел бер сүзне кабатлый торган иде. «Яшьләр, бәхет үз кулларыгызда. Табуыгыз да, югалтуыгыз да үзегездән тора».

Һәркем бу тормышта Аллаһ биргән гомерләрне парлы үткәрсә икән. Икәү булганда шатлыгы арта, авырлыгы кими бит аның.

Гөлназ ИСМӘГЫЙЛЕВА.
Казан шәһәре.

Татарстаннан китеп, Уралда яши башлавыма инде ярты гасырдан артык вакыт узган икән.

Яшьрәк чакта артык сагындырмады да шикелле, чөнки гаиләне кайгыртасы, эшлисе бар, аралашу да күп иде – сагынырга вакыт та калмагандыр.

Хәзер мин Татарстаным белән бер дулкында яшим. Казаннан газета-журналлар яздырам, көн саен «Татарстан–Яңа Гасыр» каналын карыйм. Соңгы елларда авылларда, районнарда халыкның бик кимүен әйтәләр. Мин дә Кама Тамагы районының үзем туып-үскән Ишем авылын искә алып, хатирәләр сандыгын ачтым әле. Без үскән чорларда авылда 130 лап йорт һәм шуның кадәр үк диярлек буш йорт урыннары бар иде. Димәк, инкыйлабка чаклы Ишем бик зур авыл булган. Авылдашлар белән хәбәрләшеп торам: уты, суы, газы булуга карамастан, бүген авылның егермеләп йортында гына кеше яши, калганнары буш тора. Яшьләр өчен авылда бөтенләй дә эш юк икән.

Сугыштан соңгы 10–15 елда авылдашлар колхозда бушка эшләп, күтәрә алмастай салымнар түләп чиләнде. Хыялларында да, телләрендә дә гел «китү» генә иде. Хәтер сандыгыннан ул чактагы җырларны барлыйм. Искитмәле – барысында да «киттем», «китәм»... Әниләр, туганнар турында җыр җырлаганны хәтерләмим. Күрәсең, китү теләге бер яман чир шикелле бөтен җанны, күңелләрне биләгән булгандыр. Армиягә китүчеләрнең җырлап урам әйләнүләре бер бәйрәм кебек була иде. Ватанны сакларга барудан түгел бу күңел күтәренкелеге, ә авылдан, колхоздан котылу шатлыгыннан иде. Авылдан бер ычкына алсаң, анда кире кайту юк инде. Шул китүдән яшәргә җайлырак җир, эшләргә урын эзләп, авылдашларымның күбесе, шул исәптән, үзем дә читтә төпләнеп калдык. Алар да минем кебек туган авылларын уйлап, төшләрендә күреп, сагынып яшиләрдер. Үземнең дә иң яраткан җырым бар иде:

«Китәм инде, китәм инде, / Китәм инде, каласыз! / Ничә еллар күкрәгемдә / Утлар булып янарсыз?!»

Шәһәрләрнең авыл халкы исәбенә үсүе табигый хәл булса да, җире, суы, көтүлекләре булган шул авылда яшәргә теләгән кешегә эш урыннары да булырга тиеш. Ирексезләп оештырылган күмәк хуҗалыклар ирексезләп таркатылды. Хәер, авылрайоннарны кат-кат берләштерүләр, таркатулар, фәнгә нигезләнмәгән законнар, фәрманнар, күрсәтмәләр, буш вәгъдәләр ул хуҗалыкларга яхшылап үсәргә, ныгырга ирек тә бирмәде. Буш вәгъдәләр әле дә өстән явып кына тора. Их, дим, хыялларны сүрелдерми, өметләрне өзми, «китү»ләрне җырламый гына милләтебезгә үз иле – Татарстанда бердәм булып яшәүләр насыйп булсын иде, дим.

Нурислам АЙБУЛАТОВ.
Чиләбе өлкәсе, Чибәркүл шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

ИРЛӘРНЕ ҖӘЛЛӘРГӘ ЯРАМЫЙ!

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

«МОХТАҖМЫ УЛ, МОХТАҖ ТҮГЕЛМЕ, МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ ЧИКЛЕМЕ, ЧИКСЕЗМЕ, ОЛЫМЫ-ЯШЬМЕ – ЯЛГЫШЫП ТА, БЕР СЕКУНДКА ДА ИРЛӘРНЕ ҖӘЛЛӘРГӘ ЯРАМЫЙ.

Синең күңелеңне, җәлләгәнеңне аңламыйлар. Шуннан файдаланалар гына...» Татарстанның атказанган артисты, җырчы һәм музыкант Закир Шаһбанның хатыны Гөлүсә Шаһбан белән сөйләшәбез. Үзен иркә хатын дип атаса да, танылган иренең шөһрәт нурларында коенып кына яшәүче түгел ул. Артистлар тулы автобус руле артында төннәр буе йокламый барган очракта да язмышына үкенми. Ә шулай да... Ачыктан-ачык сөйләшик әле.



Мәктәпне тәмамлагач, классташ кызларым белән Чистай педагогика училищесына укырга киттем. Сагынган саен кайтырга якынрак булсын дип сайладым микән Чистайны?! Әбидә фатирда тордым. Авыл баласы бит, вакытым булганда фатир апасына булышырга да читенсенмәдем. Юдым, чистарттым. Күршедә яшәүче ике малай үстергән ана әбинең бер дә тик утырырга яратмаган «кызына» игътибар итми калмагандыр, мөгаен. «Берсе булмаса, икенчесенә менә дигән килен» дип уйлагандыр, күрәсең. Мине улына якынайта башлады. Ә ул вакытта шәһәр егетенә кияүгә чыгу бер мәртәбә иде. Ике арада мәхәббәт булды дип әйтә алмыйм. Булачак иремнең күңелендә гаилә кору, бала үстерү дигән уйлар юк иде. Гаепләп тә булмый. Аңа да шул 18 тирәсе иде. Безне кавыштырырга әнисе бик тырышты. Үзем дә аңлап бетермичә, 17 яшемдә кияүгә чыктым. Әти белән әнигә беренче тапкыр каршы килеп, сүземне сүз иттем. Мине туйлар ясап биреп җибәрделәр. Уртак тор-

мыш алып бару дигән уй башта да булмады. Уен дип кабул иткәнбездер. Тик бу уен минем өчен газапка әйләнде. Миңа гел кул күтәрде ул. Кыйналудан аңнарымны җуя идем. Бар кешедән, хәтта әтисеннән, үземнең кечкенә энемнән көнләде. Сәбәп бирәсең, шуңа көнләшә, диләр. Көнләшмәгән кеше беркайчан да көнләшми. Менә минем Закирның беркайчан да көнләшкәне юк! Интегеп яшәвемне әти-әниләрдән яшердем. Ана күңелен алдап булмый шул. Әни сизенде, чөнки бер кайтканда битемдә зәп-зәңгәр тап, икенче кайтканда – тәнемдә... Һаман саен егылып имгәнеп булмый бит! «Кызым, бер көн дә тормыйсың, кайтасың», – диде әни. Иң кирәкле документларымны гына алдым. Бөтен әйберем, хәтта туй күлмәгем дә шунда калды. Сумкамны тоттым да, «мин киттем» дип чыгып йөгердем. Вокзалга кадәр йөгергәнемне хәтерлим. Тагын тотып кыйнар дип курыктым. Улының сукканын белсә дә, кайнанам мине гаепләп калдырды. Безнең араларны да бутаучы ул булды. Мин беркатлы балалагым белән, якын итеп, бөтен серләремне кайнанама сөйләдем, ә ул, мәрхүм, урыны җәннәттә булсын, барысын да бутап, улына җиткереп барган.

Никадәр авыр яшәсәм дә, әтиләргә кайткач ике атналап көттем әле үзен. Әнигә дә: «Килсә, аның белән китәм», – дип әйтә идем. Ияләшү булды микән инде ул?! Бәхетемә, өч атнадан соң гына килде. Ә мин ул вакытка сүрелгән идем инде. Шуннан соң үземне бер дә кияүгә чыкмаган кыз шикелле тоеп яши башладым. Миңа төрттереп сүз әйтүче дә булмады. Киресенчә, өйләнмәгән егетләр тәкъдим ясадылар. Авызым бер пешкәнгәме, барысын да кире кактым. Күрәсең, Закир бәхетенә булганмын...

Казанга килдем. Балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башладым. «Точмаш» тулай торагына урнаштым. Күрше бүлмәдә җырчы Фирүзә Сибгатуллина яши иде. Дуслашып киттек. Телевизордан ул вакытта танылып килгән җырчы Закир Шаһбанны күргәч: «Тормышта нинди кеше микән? Эх, аралашып алырга иде», – дигән хыялым барлыкка килде. Җырларына гашыйк булдым дип әйтә алмыйм, күрмәве күбрәк җәлеп иттергәндер. Кимчелекле кешеләр күрсәм, бик жәллим. Фирүзә аны кунакка чакырды. Закирны «Заман» төркемендә бергә эшләгән гитарачы Әнәс Бакиров алып килде. Матур итеп өстәлләр әзерләдек, чәйләр эчтек, биедек тә әле. Икенче көнне ул мине үзенә кунакка чакырды. Өч хатын аерган кешенең уй-ниятләре, башкача, мин уйлаганча булмаган. Ул мине хатын-кыз итеп күргән. Кунакка бардым, ләкин үземә кагылдыртмадым. «Ул вакытта безнең арада нидер булган булса, сиңа өйләнмәгән дә булыр идем», – ди хәзер Закир. Танышып бер атна үткәч, әнигә шалтыраттым. Закир белән кайтам, дидем. Телевизордан күргәннәре булган. «Кайтыгыз», – диде. Тик без кайтып җиткәнче аның фикере үзгәргән. Закир минем кулны сорагач, әни риза диде дә, икенче бүлмәгә алып кереп мине тирги башлады: «Син бу адымга аңлап барасыңмы? Ничек яшәрсең? Бөтенесен үзеңә тартырга кирәк булачак!» Әнинең кичерешләрен хәзер генә аңлыйм. Балаңны бит бәхетле булсын дип үстерәсең. Аларга бик авыр булгандыр. Әлегә үз кызымны шундый кешегә кияүгә бирүне күз алдыма да китерә алмыйм. Гади колхозчы булсалар да, бик зирәк булганнар. Закирга бернәрсә сиздермәделәр, мәхәббәт дип, киләчәк тормышны уйламаган, ул вакытта җүләр булган кызларына да артык каршы килмәделәр. Әти бер генә әйтте: «Аерылып, елап, бусагама кайтып керәсе булма!» Аның шушы сүзләре тормыштагы авырлыкларны узарга ярдәм итте. Никах укытып та җибәрделәр. Хәзер алар Закирны миннән ныграк яраталар, бер сүз әйттермиләр. Закир беркайчан да ким-хур итмәде. Минем дә «ирем сукыр» дип кимсенгәнем булмады. Өйдә ул җайлашкан, урамга чыксак, култыклашып йөрибез. Алда баскыч булса, әкрен генә кулын кысып куям. Бу гадәтем шундый нык сеңгән. Башка кеше белән култыклашып барганда, баскыч күрсәм, үзем дә сизми юлдашымның кулын кысып куям.

Яши башлагач та бик күңелле иде. Әле театрга барабыз, әле концертка. Бөтен кеше Закирны таный. Бер елдан соң кызыбыз Алисә туды. Закирның күрмәве тумыштан, шуңа карамастан, йөклелек вакытында кимчелекле бала табармын дигән уй башыма да кермәде. Ә менә бала тапкач, җанга тиючеләр булды. Бервакыт гастрольләрдә йөргәндә «яраласы җан булгандыр, сукыр ир белән нәрсә дип таптың бу баланы?» – дип йөземә бәреп әйттеләр. Шулай да миңа ул сүзләрне ишетү бик авыр иде. Балам кечкенә вакытлар – иң бәхетле елларым. Кая теләсәк шунда бардык, ни теләсәк шуны алдык. Закирның беренче хатыныннан улы бар. Күп гаиләләрдә шул балалар көнләшүгә сәбәп була. Бездә андый хәл булмады. Алисә генә кечкенә чакта Закирның улы кунакка килгәч: «Ник ул сине «папа» ди, син бит минем генә әти», – дип әйтә торган иде. Үсә-үсә аңлады инде.

Бер ата-ана да, сау-сәламәт кызым сукыр кешегә кияүгә чыксын да, аны бәхетле итеп яшәтсен, дип теләми.

Закир күрмәсә дә, шуның хәтле тормышка җайлашкан. Аның өч тапкыр өйләнеп аерылуы да тәҗрибә бирми калмагандыр. Ул бик мөстәкыйль. Белемгә омтыла торган кеше. Телефоны тулы аудиокитаплар. Хәтере бик яхшы. Һәр сорауга җавабы бар. Үзе күрми, ата-анасы, туганнары юк, ике мең чакрым үтеп, Казанга килгән, үзен үзе «ясаган» көчле рухлы кеше ул. Чын татар ире! Аны берничек тә сындырып булмый. Идәнгә тәгәрәп еласаң елыйсың, ләкин барыбер үзенекен эшли. Күрмәве берни түгел, характеры үзәккә үтә кайчак. Савыт-саба да шалтырамый калмый. Әйтми дә калып булмый. Яши-яши җыела бит ул. Социаль челтәрләрдә ялган бәхетле тормыш ясасалар да, бөтен кешедә дә – шул. «Син минем ирем белән яшәмисеңдер бит?» – дип әйтәм кайчак иптәш кызларым белән сөйләшкәндә. Гел Закир хакында сөйлиләр кебек. Хәзер Газинур Га-

фиятуллин кебек, амбразурага капланып ята торган ирләр юк. Үзебез боза торганбыздыр инде ул. Хатын-кыз – хисле. Мәхәббәтен хискә сала да, аналык инстинктларын чыгарып, ирләрне бар яклап көйләргә керешә. Мин дә Закирны иркәләп, һаман аның артыннан карап-барлап яши торгач, үзем дә сизмичә, мөстәкыйльлегеннән читләштердем. «Сиңа авыр булыр, үзем эшлим әле» дигән сүзнең булганы да юк. «Син тимер шикелле бит минем!» – дип кенә тора. Мин чыннан да үземне нык дип әйтә алам. Үзебезнең автобус белән гастрольләргә чыгып китәбез, икешәр тәүлек йокламыйча, меңәр чакрым рульдә барам. Тәгәрмәч тишелсә, үзем алыштырам. Шул чакларда Закирның бер генә тапкыр әйткәне булды: «Күрми торган кешегә кияүгә чыгып иза чигәсең инде, башка кешегә чыксаң, бәхетле булыр идең», – дип. Ирләр күбрәк үз якларын кайгырта. Ә соңыннан үзләре үк гаепли башлый: ник син миннән читләшәсең? Гап-гади кайгырту булмаган ирдән ни көтәргә соң? Кирәксә-кирәкмәсә, бөтен эшне үз өстебезгә өйдек. Шуңа да хатын-кызлар ирләренә караганда олырак күренәләр. Ә алар ярату тулы күңелгә телеп-телеп яра салырга да күп сорамыйлар...

– Хыянәтме? – дип сорыйм. – Юк, физик хыянәт хакында сүз бармый. Уен булды ул. Ләкин уеннан уймак чыга язды...

Интернет дигән каһәр тормышыбызга иркенләп кереп утырды хәзер. Закирның да компьютер, гаджетлары күрмәүчеләр өчен махсус көйләнгән. Интернет аша бер хатын белән аралаша башлаган. Ул хатынны башсыз дип саныйм. Сәхнәдәге Шаһбанны күреп, интернет аша аның белән танышып, үзенә бер образ тудырган ул. Бай, уңышлы, тормышның артына тибеп яши торган ир итеп. Ә ир-атка нәрсә? Хисләнеп киткән, күрәсең. Социаль челтәргә минем телефон аша да кереп язган. Һәм үз битен ачык калдырган. Хатларын укыгач, башыма суккан кебек булды. «Җаным да бердәнберем... җырларым синең өчен генә... фатир алырбыз, бергә яшәрбез...» Мәхәббәткә тап төшерү генә түгел. Бу хатын-кызны мыскыллау! Ничек кенә кимсенәсең әле. Син аны карыйсың, тәрбиялисең, ә ул нindидер бер хатынга яхшы күренер өчен, сине начар итеп күрсәтә. Ирләр хатыннарын шуның кадәр җүләргә чыгарып калдыралар. Хатын-кыз – бик сабыр зат. Тик сабырлык та бер бетә. Без бит – уянмаган вулкан кебек. Бер бәрсә, синең гомереңә җитәрлек итеп бәрә. Миндә дә вулкан уянды! Ул хатынга яздым, аңлатырга тырыштым. «Ирем сумкаларын җыйды, сезнең белән яшәргә җыена. Аның шул сумкасыннан башка бернәрсәсе дә юк. Сез аны карый алачаксызмы? Юк икән, зинһар, котыртып ятмагыз», – дидем. Мине тыңламады, аралашу дәвам итте. Бер якта – Закир. Аның өчен борчылам. Сау ир булса, «чукынышып» китсеннәр дияр идең. Юк, әйтеп булмас иде. Борынгылар тикмәгә генә «ир бирмәк – җан бирмәк» димәгән. Чыгып китәм дигәч, Закирга катгый итеп әйттем: китәсең икән, монда башка кайтмыйсың, дидем. Ә ул 50 гә җитеп килә, яңа гаилә төзи алырмы, урамда калмасмы? Нинди горур, мөстәкыйль булырга тырышса да, ярдәмгә мохтаҗ кеше бит. 14 ел яшәгән ир, баламның атасы! Икенче якта – балам. Аңа тап төшә. Әтисез дигән исемне күтәреп йөрергә кирәк булачак бит. Баланы тормыш юлында бер яктан әтисе, бер яктан әнисе җитәкләп бару ягында мин. Тулы гаиләдә үсәргә тиеш! Шул уйларны уйлап ныклы карарга килдем. Интернет аша ул хатынның туган ягын, карт әнисен эзләп табып, аңа шалтыраттым. Әнисе елый-елый кызының интернет белән җенләнүен, берничек тә тыя алмауларын, үзен дә ире генә каравын сөйләде. «Туктамыйсыз икән, сезне оятка калдырам, исем-фамилияләрегезне әйтеп, дөньяга чәчәм», – дип шалтыраткач, әллә курыкты, әллә әнисе тыя алды, югалды ул. Ир-ат, бигрәк тә иҗатта кайнаганы, матур сүзләргә алдана ул. Баш ияргә, гафу үтенергә яратмаган Закир моны «уен» дип атады. Тик бу уен түгел, бу – хыянәт! Кем беләндер түшәктә аунап кайтуга караганда, рухи хыянәт ачырак! Бала, Закирның киләчәге хакына, синең белән аерылышам дигән иремне дә, язмышны да, хыянәтне дә җиңә алдым: 14 ел язылышмый яшәгән идек, ЗАГСка барып рәсми рәвештә ир белән хатын булып кайттык. Бу – теге хатынга җавабым булды! Акыллы булып кала белергә кирәк! Хатын-кыз тели икән, ирен дә бирми, гаиләсен дә саклап кала ала!

Ул вакыйгаларга ике ел үтеп китте. Яралар да төзәлде кебек. Сүнгән учакта да ут кабызып була. Мәхәббәт дип, кочышып-сөешеп яшибез дип әйтә алмыйм. «Яратам» сүзен ишетергә мохтаҗ да түгелмен. 18-19 яшьтә кирәк ул сүзләр, ә безнең яшьтә кеше яратуны гамәле аша күрсәтергә тиеш. Минем өчен борчылуы, гаилә дип тырышуы, машинада рульдә чакта чәчемнән сыйпап баруын да аның яратуы итеп кабул итәм. Ул миңа бик якын кеше. Мин, бәлки, Закирсыз югалмам да, яши дә алырмын. Тик ансыз тормышымны күз алдыма да китерә алмыйм. Мәхәббәт төнне сагынып көтә торган нәрсә түгел, ул – ияләшү. Аннан башка утырып чәй дә эчә алмыйм. Без бер-беребезнең кирәклеген тоеп яшибез. Мин Закир янында үземне патшабикә кебек хис итәм. Тормышны икәү тартсак та, үземне иркә хатын дип саныйм. Ул яшәү өчен бөтен шартларны тудырды. «Кызым, зарланырлыгың юк, эшләп азапланмадың, кесәң тулы акча булды, янында – кызың, ирең, кочакла да ят!» – ди әнием. Закирга рәхмәтем – шигырьләремдә. Китабымдагы бар шигырьләрем аңа багышланган... Дөрес, ир-ат кебек үк, хатын кыз да гашыйк булмый тормый. Ләкин ул акыл белән эш итә. Хатын-кыз күңеле – карурман. Ә ул урманга кереп бер кешенең дә адашмыйча чыкканы юк әле. Монысы инде бөтенләй икенче тарих...



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

ӘТИ КЫЗЫ

Баскетбол буенча Татарстан чемпионы, «Икенче Урман сылуы», «Татар кызы-2018» республика бәйгесе җиңүчесе. Бөтенроссия авыл яшьләре уеннарында иң оста... трактор йөртүче?! Чибәр татар кызлары күзгә каршында гына утырмый ул.

Аңа карыйсың да аңлыйсың: менә шушындый булырга тиеш ул чын татар кызлары. Ихлас, тәрбияле, көләч йөзле, өстәвенә, әйтеп бетергесез чибәр: зифа буй-сын, сызылып киткән кап-кара кашлар, янып торган шомырт күзләр, алсулык йөгергән бит алмалары, елмайган иреннәр һәм озын чәч. Җитмәсә, бар яклап уңган. Балтач районы Сосна авылы кызы Гүзәл Габдрахманова быел «Татар кызы-2018» республика бәйгесе җиңүчесе булды. Бу – аның чираттагы җиңүе. Аңа кадәр дә күп бәйгеләрдә беренчеләр сафында була. «Мондый уңышларның сере нәрсәдә?» – дип сорыйм. Гүзәл тыйнак кына елмаеп: «Мин тормышта бик актив кеше», – ди. Мәктәптә укыганда спорт белән шөгыльләнә. Башкача мөмкин дә түгел. Әтисе Фәнил абый – физкультура укытучысы. Кызын кечкенәдән сынатмаска өйрәтә ул. Барлык спорт ярышларында катнаша, хәтта баскетбол буенча Татарстан чемпионы исемен яулый. «Син булдыра аласың», – дип аны үсендерә. Трактор руле артына да утырта кызын. Кызык өчен түгел, билгеле, ярдәмгә. Өйләрен салганда, зурлар белән берррәттән трактор белән су буеннан таш ташый Гүзәл.

Әшли-әшли үсеп, Казан дәүләт авыл хуҗалыгы университетына укырга барып кергәнен сизми дә кала. Анда театр дөньясына чума. Университетның Роберт Галиев җитәкләгән «Тургай» студентлар театрына кереп китә. Уку, театр, гастрольләр... «Галиябану» спектаклендә төп рольне башкара. Димәк, үзәкләргә үтәрлек итеп җырлый да! Шул арада Архангельскида узган «Урман патшабикәсе» бөтенроссия бәйгесенә барып, өченче урын алып кайтырга да өлгерә. «Элек спорттан адреналин алган булсам, хәзер сәхнәдән рәхәтлек алам. Гастрольләр вакытында спектакль тәмамлангач, әбиләр сәхнә артына кереп, кочаклап елаганда, күңелдә нинди ләззәт булганын белсәгез иде», – ди ул. Сәхнә белән дуслыгы төрле бәйгеләргә әзерләнергә ярдәм итә. «Татар кызы» бәйгесе дә авыр булмый аңа. Әнисе Гөлсу ханымдагы иҗади уйнау аңа да күчкән. Сәхнәдә Ай кызы образы тудырган Гүзәл теләген җиткерә: «Татар халкы айга ашеренгән Зөһрә кыз кебек калмасын, күңелләребез салкын айда гына бәргәләнмәсен иде. Күңелләрдәге татарлыкны җиргә чыгарыр, илгә күтәрер чак җитте».

Хыялларның чынга ашканын белә ул. Кечкенә чагында телевизордан әтисе белән Олимпиада караганда спортчыларның аклы-кызыллы киемнәренә мөкиббән китеп: «Эх, мин дә шундый костюмнар киеп ярышсам иде!» – дип хыяллана. Узган ел Зәйдә механизаторлар ярышында катнашып, хатын-кызлар арасында беренче урынны ала. Һәм менә ул быел Курскида узган XII бөтенроссия авыл яшьләре уенына аклы-кызыллы костюмнан Татарстан данын якларга бара. Команда беренче урынны алып кайта. Үзе исә монда да егетләрнең борынына чиертә. 120 катнашучы арасында трактор йөртү буенча гомуми зачетта бишенче урынны ала. Ир-егетләр арасында бит ул! Социаль челтәрләргә тракторда башкарган осталыкларын куйгач, дус егетләреннән хатлар килә: «Зинһар, безне оятка калдырып куйма». Егет дигәннән... Гүзәл дә гаилә кору теләге белән яши. «Булачак иремнең трактор йөртә белүе мөһим түгел, терәгем булсын да, башымны салырга киң күкрәге булсын», – ди. Әлегә магистратурада укый, хисапчы булып эшли. Эш арасында бәйгеләргә әзерләнә. «Татар кызы»ның 6 октябрьдә узачак халыкара этабында катнашасы бар. Кышын Төмәнгә барып, трактор йөртү осталыкларын күрсәтергә кирәк... «Укытучы баласы булгач, барысын да яхшы үтәргә тиешмен дип үстем. Тырышлыгым шуннан да киләдер, мөгаен. Әти-әнием кеше баласының уңышларына чын күңелдән сөенеп, «менә булдыра» дип мактаганда, минем бер генә теләк булды: «Әтиемнәр минем белән дә горурлансын иде!» – дип сөйли Гүзәл. Әни, бигрәк тә әти тәрбиясе җимеше шул бу! Кирәк урында мактап, кирәк урында үзең үрнәк булып, эшләтеп үстергән кызлар гына токмачын да җәяр, тракторын да иярләр, матур гаилә дә корыр, татарның данын да еракларга таратыр.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА











PRESSA




Фото: www.pixabay.com

АЗГЫННАР

ҖАН ӨШЕТКЕЧ БУ ХӘЛЛӘР ТУРЫНДА КҮПТӘННӘН БЕЛӘ ИДЕМ. ТИК ЯЗАРГА ГЫНА КЫЙМЫЙ ЙӨРДЕМ.



Мәдинә АВЗАЛОВА

Иң куркыныч әкият тә моның кебек авыр тәэсир калдыра алмый. Иң куркыныч җинаять тә тора-бара бер тоныклана. Ә моны онытып булмый. Хәзер инде ишеткәнемә үкенә дә башладым. Ник сөйләттем, нәрсә дип ачтым аның йөз кат йозактагы җәрәхәтле күңелен? Нигә елаттым? Бөтен тормышын астын-өскә китергән, алай гына да түгел, сызып ташлаган ул вакыйгаларны искә төшерү, көлдән торгызу – үлеп, яңадан терелү белән бер бит ул. Нигәяздың, диючеләр булыр. Тормыш кагыйдәләренә, дин кануннарына якын да килмәгән, җир йөзендә, гомумән дә, булмый торган мондый гайре табигый хәлләрне кисәтү, сабак алу берәүгә дә артык булмас, минемчә.

«Кем икәнен белеп бардым»

Бик читтә, әбинең үзе әйтмешли, «шайтан почмагы»нда булып чыкты ул авыл (исемнәр билгеле бер сәбәпләр белән үзгәртеп бирелә). Зур да түгел үзе, кечкенә дә түгел... Хәер, бусы миңа барыбер. Йөзләгән чакрым араны үтеп, ул яшәгән йортны, аны эзләп килдем. Әнә ул, үзе сыман көч-хәл белән терәлеп торган иске капка төбенә чыгып баскан да, кулын маңгай өстенә куеп, кемнедер күзли. «Килеп җитәм», – дип хәбәр иткән идем. Түзмәгән, каршы алырга чыккан. Мине күргәч, бәләкәй гәүдәсе тагын да куырыла төште. Алда безне авыр сөйләшү көтә. Барын да әйтеп бетерә алырмы, көче җитәрме?! Кочаклап алуга, бөтен икеләнүләрем уч төбендәге кар шикелле эреп юкка чыга. «Әйдә, кызым, – ди ул шундый якын итеп, яратып, – самоварым кайнады, синең әле самовардан чәй эчкәнең юктыр... Ул шулай үзалдына сөйләнә-сөйләнә капканы ачып җибәрә. Күргәнемнән баш әйләнеп, ис китеп торам: ишегалды тулы чәчәкләр, нindиләре генә юк! Җәннәт почмагы ич бу! Бетеп барган бер авылда, төртсәң аварга торган бәләкәй генә өйнең койма артында шундый тамаша! Һич уйламассың, билләһи! Ә авылның табигатен әллә ни димәс идем. Урамнары да тар, күрше-күләннең капка төпләрендә чәчәк түгел, әрем дә үсми әнә. Ә бираедә... «Мин чәчәкләр яратам, төшемә дә гел чәчәкләр керә... Төшеңдә чәчәк күрүне әйбәткә юрамыйлар. Мин инде күрәсен күргән кеше. Хәзер берни куркытмый, үлсәм дә сүзем юк. Тик менә җирләргә якын кешем генә юк...»

– Яратасызмы? – дим, ишегалды тулы ак ромашкаларга ишарәләп.

– Яратам... – Әби бераз дәшми тора да, – әле кичә бабайның каберенә дә утыртып кайттым, – дип дәвам итә сүзен. – Рәнҗеде дип, әллә ниләр уйлап ятмасын. Кызы гына башына җитте, кызы гына... Әйдә, шушы чәчәкләр арасында утырабыз, сөйләшүе дә җиңелрәк булыр.

Мәрьям апа, сүзне икенчегә борып, җәһәт кенә өенә кереп китә дә самоварын күтәреп чыга, аны ямь-яшел чирәм өстенә китереп утырта. Ул арада ак җәймә, чынаяклар, тәм-том пәйда була. Аның кунак көткәнлеге сизелә. Ә бәлкем, янына кереп йөрүче дә юктыр аның.

– Миннән кеше өзелми, – ди ул, уйларымны җилгә очырып. – Хәлемне белеп торалар анысы, рәхмәт.

– Ничек түзгәнсездер инде... – Сүземне нидән башларга белми торуымны Мәрьям апа шундук аңлап ала.

– Кешегә сөйли торган сүз түгел болар, – ди ул, әллә чакырганына үкенеп, әллә ургылып ташырга торган уй-хисләрен бүлешергә кеше тапканга сөенеп. Булсын, чит кеше булсын. Бер белмәгән, күз күрмәгән кешегә эч-сереңне бушату җиңелрәк тә, дөресрәк тә.

– Мин кияүгә соң чыктым, – дип сөйли башлый ул, тормышының берсеннән-берсе катлаулы юлларына тукталыш ясап ала-ала. – Шуңадырмы, кияүгә дә беренче сораган кешегә чыктым. Үзебезнең авылныкы түгел. Кем икәнен, каян килгәнен, безнең авылга ничек килеп эләккәнен соңыннан әйттеләр. Хәбәр килеп ирешкәндә, соң иде инде. Минем авырга узган чагым. Авылда чыбыксыз телефон әйбәт эшли бит. Өйдән өйгә йөртеп, китереп җиткерделәр: имеш, ул миңа кадәр дә ике тапкыр өйләнгән. Имеш, аның беренче хатыннан бер кыз баласы бар. Имеш, аның икенче хатыны бик бай булган. Ул аңа шул байлыгы өчен генә өйләнгән дә. Күпмедер яшәгәннән соң, имеш, хатынын үтергән өчен төрмәгә эләккән. «Сине ни көтәдер инде, Мәрьям?» Халык гөж килде. Гайбәт бит ул йөри-йөри дә, суга төшеп югала. Сөйләделәр-сөйләделәр дә, берзаман оныттылар. Хәсәнем дә бу сүзләргә «әйе» дә, «юк» та димәде. Кайда эш кушалар, шунда эшләп йөрде. Ә мине бу сүзләр аяктан екты. Сөйләшми иде ул бу хакта минем белән. Кырт итеп кисә дә куя. Моның ахыры начар тәмамланды. Дүрт айлык авырымны югалттым. Бик авыр кичердем бу югалтуны. Ә аның исе дә китмәде. Шул чагында куып кына чыгарасы иде дә бит. Һаман да шул ялгызлык куркыта. Нишләрмен, дидем. Алда ни көткәнен белгән булсаммы? Болары әле ачы фаҗиганең башы гына булган икән.

> *«Бабай түгел мин аңа... әти, – дип әйткәнен үзем ишеттем», – ди картаймыш көнендә шундый мәсхәраләр күргән Мәрьям апа.*

«Бармыйча түзә алмыйм»

Үткәненнән сабак алып, тәүбәгә киләсе дә бит... Ләкин юк. Ир көннәрдән бер көнне юкка чыга. «Ял көне җитә башладымы, берни әйтми чыга да китә. Аннан, берни булмагандай, яхшы кәеф белән кайтып керә», – дип искә ала еракта калган җан әрнеткеч ул минутларны 80 яшенә җитеп килүче Мәрьям апа. Кайда һәм ни эшләп йөргәнен янә чыбыксыз телефон ирештерә. Район үзәгендә яшәүче кызы янына йөри икән. Кызы бит, йөрсен, балаңнан да кадерле кем бар бу дөньяда! Барулары ешаеп, инде гадәткә әверелеп киткәч, хатын иренә әйтә: «Мине дә алып бар әле. Кызың белән таныштыр, күрәсем килә», – ди. «Күрәсең киләме? Әйдә алайса...»

– Килеп кердек җитәкләшеп, – ди Мәрьям апа, әйтерсең, кичә генә булган вакыйгаларны күз алдыннан үткәрә. – Ишекне ачып җибәрүгә кызы иремнең өстенә ташланмасынмы... И-и үбешәләр, и-и кочаклашалар. Әйтерсең, мин юк та... Бераздан гына исләренә килделәр. «Нишләвегез бу?» – дим, һушым китеп. Шулай дигәч, уңайсызлана калдылар. Хәсән генә: «Күрмисеңме, сагынышканбыз», – дип куйды. Тегесе иремнең кочагыннан чыгуга, чак кына аумадым. Авырлы лабаса кыз! Әллә нишләп киттем. Нindидер бер чиркану-җирәнү хисе биләп алды димме. Әтиле-кызлы торып яталар түгелме соң болар, җирбитләр... Берни әйтмичә, ишектән дә узмыйча, борылдым да чыгып

киттем. Аңладым мин, барын да аңладым. Кызы янына барыр алдыннан ашыга-ашыга күлмәк алыштыруын да, хатын-кыз шикелле киенү-чистарынуын да... Тик бер нәрсәне генә аңлый алмадым: ничек итеп, нинди намус, ни йөзең белән газиз балаң белән ятасың? Моңа җәза да уйлап табылмаган хәтта. Чөнки мондый җинаятьне адәм баласы күз алдына да китереп карамый. Ә иң хәтәре: кызы үзе асылына, үзе шуны тели. Җирәндем, күрәсем килмәде. Икенче көнне өйгә кайткач, чыгып китәргә куштым. Ә ул, берни булмагандай: «Кызым ич ул минем, ә син – минем хатын. Ачуланма, әллә нишләдем, янына бармыйча түзә алмаска әйләндем», – димәсенме. «Азгыннар сез, – дидем, – мондый хәлне күргәнем дә, ишеткәнем дә юк минем. Кеше белсә, нишләрсез. Авырлы да икән әле. Үз балаңның баласына әти буласың ич, хайван», – дим. Ярый әле хатыны күрмичә үлгән мондый оятсызлыкны... Җир тишегенә керерсең, билләһи. Мин кудым, ул китмәде. Кешегә әйтергә кушмады. «Сине дә яратам, аны да...» – диде. Баласы үсеп җиткәнчегә тиклем йөрде шулай ике арада.

Үз-үземә һаман бер сорауны бирәм: мөмкинме бу?

– Ә кызы кияүгә чыкмадымы?

– Улына 8 яшьләр тирәсе идеме икән, чыкты ул бер иргә. Ире әйбәт кеше иде. Кулыннан килмәгәне юк. Эштән кайта да кем чакыра, шунда китә. Әзрәк акчасы булыр, шабашка, дигән була. Гомер буе эшләде, хатынына ярарга тырышты. Ә кызы – Альбинасы, ире чыгып киттеме, әтисен чакыртып ала. Тегесе: «Малайны күрәсе килә» дигән сылтау белән тагын чыгып йөгерә. Соң гына кайта аннары. Хатын бик бозык, инде күрше-күлән дә шикләнә башлаган. Озак яшәмәделәр алар, – ди карчык тирән көрсенеп. – Икенче баласы тугач, бераз тынычланган иде. Баласы үсә төшкәч, тагын барырга тотынды бу карт җүләре. «Ярдәм кирәк аңа», – дигән була. Ә ире, бичара, әз генә дә шикләнмәде. Кемнең башына килсен инде шундый бозык уй?

Әбинең әйтүенә караганда, бер көн авыртып ятмаган, бер генә мәртәбә дә хастаханәгә йөрмәгән таптаза ирнең кинәт аяктан егылуын, вафат булу сәбәбен табибларның таба алмауларын халык хатынга сылтый. «Бер туктамый чуашларга йөри, гел шунда ул. Нәрсәдер эшләтә, сихерли ул аларны», – ди аны белгән кешеләр.

– Иреннән туган кызы кыяфәте белән әнисенә охшаса да, үз-үзен тотышы, холкы башкача: тәртипле бала, – ди Мәрьям апа. – Әтисе ягына тарткандыр. Күршемнең апасы шунда – үзәктә яши. Альбинаны яхшы белә. Бергә эшләгәннәр диме шунда. Үзара сөйләшкәндә, әллә чынлап, әллә уйнап, ычкындыргалап куя ди. Имеш, аның икенче баласы да – Хәсәннән... Әтисен «әти» дип әйтми, «Хәсән» дип кенә җибәрә. Ул гомер буе кыланмышларын кеше белми дип йөрде. Йөзенә бәреп әйтүче булмагач, шулай уйлагандыр инде. Аннары... ничек әйтәсең? Дөньяда булмаган хәл бит. Оят, билләһи.

«Дөньяда булмаган хәл»ләр, сирәк булса да, очрап торгалый шул. Һәм аның ахыры һәрвакыт аянычтәмамлана. Язганым да бар: Козловкадагы хатын-кызлар колониясендә 19 яшьлек кыз баланың тимер рәшәткә артына килеп эләгү сәбәбен ишеткәч, озак урын таба алмый йөргән идем үземә. Бәлкем, ул бала инде күптән иреккә чыккандыр. Тик ул гел күз алдымда, томырылып торган зур кара күзләрен тутырып миңа карый. «Коткарыгыз мине бу читлектән», – дип әйтергә теләве иде микән. Җинаятькә аны имансыз әтисе этәргән. «Көчләргә дип өстемә килә башлагач, пычак алдым да кададым. Үтерәм дип кадамадым. Хурлыктан сакланыр өчен», – дигән иде ул. Һич тә аны аклап әйтүем түгел. Беркемнең дә кеше гомеренә кагылырга хакы юк. Шуңа җәзасын алган да инде. Ә шулай да кыз җәл, сынган язмыш, билгесез киләчәк...

Хәсән бабайның вафатына әле ел чамасы гына икән. «Соңгы арада бик биреште, – ди Мәрьям карчык. – Озак кына урын өстендә ятты. «Кызыңны чакыртыйммы, бәлкем, әйтәсе сүзең бардыр?» – дим. «Юк, чакырма, күрәсем килми», – диде. Миннән гафу үтенде. Ходай ярлыкасын, дидем.

– Олы малай беләме соң аның бабасы түгел, әтисе икәнен?

– Юк-юк, белми... Белә күрмәсен, оят бит, балага оят, – ди карчык. – Ул инде хәзер бала түгел, үзе ике бала атасы. Алай дисәң... – Мәрьям апа бераз уйланып тора да: – Кеше теле тик тормый, күптән җиткергәннәрдер инде. Таш та куйдырып киткән әнә, бабам дип куйганмы, атам дип куйганмы, кем белә... Кызы гына гаепле, кызы гына, – ди әби, бөтен нәфрәтен шул сүзгә салып. – Дөрес яшәмәде, Ходай кичерсен. Мин дә дөрес яшәмәдем. Зур гөнаһның шаһиты булдым, түздем, сабыр иттем. Әни миңа: «Син битлек белән тудың. Бәхетле булырсың», – дип әйтә торган иде. Битлек белән туганмын шул. Югыйсә болай эшләмәгән, күрмәмешкә салынып йөрмәгән булыр идем. Чаң сугарга, аны бу гамәленнән туктатырга кирәк иде. Шул инде... «Бозык белән шөгыльләнә», – диделәр. Әтисен дә бозгандыр ул каһәр. Үлгәндә соңгы сүзе: «Каберемә якын килмәсен» булды. Аңлагандыр дим мин аны.

...Үземне, тәнемә пычрак су койгандай хис итеп, кайтыр юлга чыгам. Артыма борылып, әбигә кул болгыйм. Чәчәкләр арасында ул тагын да кечерәеп, бетәшеп калган сыман. Ак күлмәкле, ак яулыклы... ак күбәләк. Ул инде яшәми дә кебек. Җаны гына шул аллы-гөлле чәчәкләр арасында очып йөридер сыман. Очрашуны көтә микән?! «Кылмышларыгызга күрә, мәңгелек җәзага дучарсыз» (Сәҗдә сүрәсе, 32-14) диелгән Коръәндә. Юк, очрашмас аларның юллары... Тормыштагыча инде... аеры булыр.

КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Исегезгә төшерәбез: сентябрьдән 2019 ел өчен матбугатка язылу кампаниясе башланды





**«СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫНА — 105 ЕЛ!
ЖУРНАЛГА БЕР ЕЛГА БЕРЕНЧЕЛӘРДӘН БУЛЫП ЯЗЫЛГАН 105 УКУЧЫГА БҮЛӘККӘ — «СӨЕМБИКӘ» АЛЪЯПКЫЧЫ!***

Сез күптән көткән яңалык: хәзер «Сөембикә» журналына ЕЛЛЫК язылу мөмкинлеге бар!
Бер елга язылу бәясе — 1146 сум.
Ярты елга язылу бәясе — 573 сум.


ИНДЕКСЛАР: П8299 (алты айга язылу)
П2204 (бер елга язылу)



Казанда яшәүчеләр журналга ташламалы бәядән генә редакциядә языла һәм килеп ала алалар.
Бу очракта алты айга язылу бәясе — 330 сум,
бер елга — 660 сум.

Россия Федерациясендә, БДБ илләрендә һәм ерак чит илләрдә яшәүче укучыларыбыз өчен язылу бәясе элеккечә кала. Безне Роспечать каталогының журналлар бүлегендә табарга мөмкин.

ИНДЕКСЛАР: 73002 (алты айга язылу),
25227 (бер елга язылу).



Реклама

**ЖУРНАЛНЫҢ ЭЛЕКТРОН ВЕРСИЯСЕНӘ ЯЗЫЛЫП ТА УКЫЙ АЛАСЫЗ.
ЯЗЫЛУ ШАРТЛАРЫ — САЙТЫБЫЗДА.**

* Акция 2018 елның 1 сентябреннән 31 декабренә кадәр гамәлдә.
Тулырак мәгълүмат syuyumbike.ru сайтында.

16+



ЗАНЗИБАР



Раушания
ПОЛОСИНА-СӨЛӘЙМАНОВА

Африка дигәч, күз алдыгызганиләр килә? Чүл, тәбәнәк куаклар, кыргый җанварлар, заманча шартларда яшәүнең ни икәнен дә белмәгән кешеләр... Без дә шулайрак дип уйлаган идек. Әмма Африка бик зур һәм төрле ул. Яз көне бу кыйтганың төньягында – Мароккода булган идек. Дөресен әйтәм, Африка икәне сизелмәде дә. Гадәти шәрык илләренең берсе... Шуңа күрә бу юлы: «Бәлки Занзибарны сайларсыз?» – дигәч, шунда ук ризалаштык. Беренчедән, экваторны узып, каядыр барган юк иде әле. Икенчедән, ап-ак комлы пляжлары өчен Занзибарны «Африканың Мальдивасы» дип атыйлар. Өченчедән, бу әле яңа юнәлеш, димәк, анда үз көенә аккан тормышны күреп калу мөмкинлеге бар.

Отельне ничек сайладык

Занзибарга баручыларны суның чигенү-кайту күренешләре куркытырга мөмкин. Төп утрауда пляжлар берничә: көнчыгыштагылары – сөзәк, аларда су берәр чакрымга чигенә, ә көнбатыш яктагылары – текә ярлы, су алай ук эчкә китми, гомумән, аның чигенү-кайтуы артык сизелми. Без урта бер җирдән сайладык. Отельне балыкчылар авылы янында урнашкан дип язганнар иде, димәк, барып, карап-күреп йөрергә, андагы халыкның тормышы белән якыннанрак танышырга мөмкин булачак. Пляждагы комы да башкалардан аграк күренде.

Аз гына өстәп түләдек тә, тәрәзәләре океанга карап торган бүлмәгә урнаштык. Андагы манзара! Андагы таңның ничек матур атуы!

Ничек барырга?

Белүебезчә, Занзибарга турларны Россиядән Пегас туроператоры гына тәкъдим итә. NordWind авиакомпаниясе очкычлары Мәскәүдән оча. Билетны арзанракка алып, үз көеңә бару мөмкинлеге бөтенләй юк дип әйтмәкче булам. Алай дисәң, китәргә берничә көн кала, «арзанлы билетлар сайты» миңа Занзибарга кадәр нибары 13 меңгә билетлар тәкъдим итте. Әмма мондый очракка тагын тап буласыңмы, юкмы, кем белә?! Юл авыр булды дия алмыйм. Барганда да, кайтканда да төнлә очтык – тугыз сәгать тирәсе.

Виза һәм документлар

Визаны Занзибарның очкыч аланына барып төшкәч сатып аласың. Ул 50 доллар тора. Карта белән дә түләргә мөмкин, әмма кесәңдә акча булса әйбәтрәк. Отельгә барып җитүгә, һәр кешегә көнгә 1 доллар исәбеннән «туристик сбор» да түләргә кирәк булачак әле.

Акча

Танзаниянең (ул – Занзибар иленең бер өлеше) үз валютасы бар – Танзания шиллингы дип атала. 1 сум якынча 35–40 шиллинг тора. 1 долларга исә 2000–2400 шиллинг бирәләр. Җирле шәхесләр яки җанвар рәсемнәре төшерелгән тимер һәм кәгазь акчаларны истәлеккә алып кайтырга җыенмасагыз, долларларны шиллингка әйләндереп тормасагыз да ярый. Эре акчаңны ваклап бирергә яраталар, нишләптер аларда вак акчаның бәясе юк. Алдан барысы өчен дә түләнгән булса, үзегез белән күп акча алмасагыз да ярый.

Экскурсияләр

Аларны Пегасның үзеннән дә алырга була. Бу очракта гидлар экскурсияне рус телендә алып барачак. Инглиз телен белмәсәгез, шушысын сайлыйсыз. Әмма ул шактый кыйммәт (60–100 доллар тирәсе). Отель тәкъдим иткән экскурсияләр уртача 40–80 доллар тора һәм, әлбәттә инде, инглизчә генә. Иң арзан бәя – 20–45 доллар – бич-бойларда (пляж егетләре). Ләкин аларда сыйфат ягы түбәнрәк инде. Без үзебез шушы вариантны сайладык. Арзан булганга түгел. Кәрим исемле гид егет шушында туып-үскән, рус телен өйрәнә башлавына да әле дүрт ай гына. Мондагы тормыш турында Пегасның бер генә гиды да аның кадәр белми!



Экскурсияләрне шартлыча өчкә бүләргә була: пляж, урман, шәһәр буенча. Урман безгә алай кызык тоелмады. Әмма без белгән һәм белмәгән тәмләткечләрнең ничек үскәнен күрергә, маймыллар карарга теләсәгез – бара аласыз. (Тик ул маймыллар – коломбуслар гид әйткәнчә үк тыныч, зыянсыз булмаска да бик мөмкин!)

Ирем белән танышкан көнебезне билгеләп узарга бардык Занзибарга.

Без сайлаган экскурсияләрнең беренчесе – Сафари Блю иде. Фумба дигән авыл яныннан көймәдә утрауга кереп китәсең. Су чигенгәндә бу утрау күренә, су кайтканда – югала. Әгәр ярты көн безнең кебек шул тирәдә булсагыз, әлеге утрауның әкрен генә Һинд океаны суына күмелүен күзәтерсез. Су коендык, кызындык, шунда гына үсә торган бик тәмле җиләк-җимешләрне авыз иттек. Әйтергә онытканмын: сез бу утрауны картадан тапмассыз – ул анда юк.

Култыкта урнашкан күрше утрауларның берсенә йөзеп тә бардык. Суның төбе шулкадәр тигез! Култык кырыйларында мангра агачлары үсә: аны төзелештә күп кулланалар икән.

Шул ук утрауның икенче ягына йөзеп чыгабыз, анда – пляж, сувенирлар сата торган алачык-кибетләр урнашкан (безнең отель янындагы бәяләр мондагыдан арзанрак кебек тоелды). Безгә төшке аш әзерләнгән арада, баобаб агачын карарга киттек. Аңа инде 500 яшь! Моннан өч йөз ел элек ул бер ягына ауган һәм... үсүен дәвам иткән. (Безгә баобабның җимешеннән тәм-томнар алырга тәкъдим иттеләр. Кызыкмасаң да ярый, чөнки ул

Фото: автор



■ Бу ишекләрнең һәрберсе янында туктыйсы, кулың белән кагыласы, янына басып, фотога төшәсе килә. Кайберсенә хәтта бер гасыр гына да (!) түгел бит!

■ Көймә белән утраудан аз гына читкә киткән идек – андагы балык! Кызыл диңгездә йөзгән кешеләрне моның белән шаккаттырып булмас, билгеле. Әмма барыбер матур! Маска киеп, шул балыклар арасында йөзәргә дә була. Көймәдә утырган килеш кенә җиләк-җимеш ашатсаң да, сине төрле төстәге балыклар өере чорнап алачак.





баллы орлыкларны барыбер ашап булмый.) Бу гаҗәеп агачның өстеннән аркылыга-буйга йөреп кинәнгәч, төшке ашка киттек. Менә безгә бер-бер артлы диңгез нигъмәтләре ташый башладылар: балык, кальмар, креветка, лангуст, лобстер... Телеңне йотарсың!

Лагунага кергән җирдә менә-менә каршыңа диңгез юлбасарлары корабле килеп чыгар төсле тоела...

Ә кире кайтканда җил чыкты да, көймәнең җилкәннәрен күтәрделәр! Күз алдына китерәсезме?! Онытылмаслык сәяхәт булды ул!

Икенче экскурсиябез Prison Island утрау-төрмәсе иде. Ул илнең башкаласы Занзибар шәһәреннән ерак түгел урнашкан. Утрауда башта чыннан да төрмә төзиләр, әмма кайбер сәбәпләр аркасында ул төрмә булып ук чыкмый – йогышлы чирләр белән авыручы кешеләрне шунда озата башлыйлар. Бу инде бик күптән булган хәлләр. Бүген монда отель, ресторан урнашкан: кешеләр бирегә бөтенләй башка максатлар белән киләләр. Утрауда сейшель ташбакалары яши. Кайчандыр кешеләр аларны юк итеп бетерә язганнар: ташбаканы тотарга, аннан ашарга бик җиңел бит. Ә панцireннән нидер ясарга да була. Монда ничә генә яшьтәге, нинди генә зурлыктагы ташбакалар юк! «Балалар бакчасы» да бар, ике йөз яшьлек әби-бабайлар да... Ташбакаларны ашатырга да, теләсәң, сыйпап карарга да була (ничек дөрес сыйпарга икәнен алдан белешергә генә онытмагыз), бергә фотосурәткә төшәргә дә... Әмма мультфильмдагы кебек, өсләренә утырып йөрергә менә һич ярамый.

Занзибар шәһәре ике өлешкә бүленгән: Иске шәһәр (Стоун Таун) һәм Яңа шәһәр. Бөтен җирдәге кебек үк каланың иске өлеше аларда да шактый дәрәҗәле һәм кыйммәт санала. Занзибар шәһәренең генә түгел, гомумән, утрауларның иң матур бизәге булып агачтан уеп ясалган ишекләр санала. (Бу яктан татарлар белән дә беркадәр охшаш бугай алар: бездә дә зур, матур капкалар йорт хуҗасының дәрәҗәсе, байлыгы турында сөйли бит.)

Борынгы урамнар буйлап бик озак йөрдек. Рәхәтләнеп, иркенләп карап йөрергә урамдагы сатучылар гына тынгы бирми: «хәтерләре» дә юк – яңа гына борылып китәләр һәм кабат, шул ук товарны тәкъдим итеп, яныңа әйләнеп киләләр. Сувенирлар сатучы кибетләрдән генә торган тар урамга барып җиткәч, җиңел сулап куйдык. Базар да шуннан ерак түгел икән.Ниләр белән сәүдә итәләр икән дип йөреп әйләндек. Үзем белгән тунец балыгыннан кала бернәрсәне дә хәтерләп калмадым.

Ашау-эчү

Җирле халык дөгене бик яратып ашый. Алар бәрәңге белән баклажан да үстерәләр. Җиләк-җимеш исә монда ел әйләнәсе өзелми: бездәге кебек «шушы җиләк сезоны» дигән нәрсәне бөтенләй белмиләр. Үзләре ананас белән мангоны ярата төшә. Безгә маракуйя, карбыз, банан, ананас, папайя, манго ашаттылар. Монда килгәч кенә ананасның сатып алуга ук ашый торганга һәм өч көннән генә ашый торганга бүленгәнен белдек. Җирле халык өч көннән генә ашый торган ананасны алмый, алар фикеренчә, анысы – начар. Безгә, Россиягә кадәр, андые да килеп җитмәгәнен күз алдына да китерми инде болар...

Диңгез нигъмәтләрен бик тәмле әзерлиләр. Йомшак булсын өчен, пешерер алдыннан осьминогларны таяк



■ Утрауда башлыча занзибарлар һәм масаилар яши. Беренчеләре бик тыныч халык, тормышка фәлсәфи караулары белән аерылып торалар. Ашыкмый-кабаланмыйлар, үзләрен бик дустанә тоталар. Телләрендә гел өч сүз: «джамбо» – сәлам, «акуна матата» – проблема юк, «поле-поле» – әкрен, ашыкма. Шулай яшиләр дә! «Материк-ка – Танзаниянең башкаласы Дар-эс-Салас шәһәренә барырга яратмыйбыз, анда ыгы-зыгы күп», – ди алар.

белән тапыйлар. «Коле-коле» дигән бик тәмле балыкны хәтерләп калдык – аны маракуйядан ясалган әчкелтем соуста әзерлиләр. Ә «реди снаппа» дигән балыклары деликатес санала. Аның тәмлелеге!..

Чәкчәк музееен оештыручылар буларак, кая гына барсак та: «Безнең чәкчәккә охшаган тәм-том сездә дә юкмы?» – дип сорыйбыз. «Бар!» – диләр. Әмма камырлары йомшаграк, сироплары сыеграк булып чыкты. Барыбер кызык инде!

Җирле халык

Безнең Татарстандагы кебек үк, Занзибарның да ярты халкы – мөселманнар, яртысы – христианнар. Хатын-кызлар океанда суүсемнәр үстерү белән шөгыльләнә, ирләр күбрәк балык тоту белән мәшгуль.

Масаилар исә сугышчылар кабиләсеннән. Алар кызыл киемгә төренгән, кулларында – озын таяк, билләрендә – кынга тыгылган кылыч. Утрауда алар күбрәк сак хезмәтендә эшли (дөрес, безнең отельдә алардан тыш, тагын коралланган хәрби сакчылар да бар иде әле), чакырылмаган кунакларны – нидер сатып йөрүчеләрне, бала-чаганы, маймылларны, әрсез чыпчыкларны куалар.

Сирәк булса да, занзибарлыларда күп хатынлылык очрый (исламда бу рөхсәт ителә, әмма бөтен кеше моны эшли генә алмый). Ә масаиларда... күп ир белән тору күренеше бар икән. Хатын, гадәттә, өйдә генә тора, ә ирләре эшкә йөри, акча эшли. Әгәр ишек төбенә озын таяк сөяп куелган икән, димәк, ирләрнең берсе өйдә, хатын янында дигән сүз: калган ирләр бу вакытта бусаганы атлап узмый. Масаи ирләренең күбесенә мондый тормыш ошамый, алар шуңа күрә гаиләдән китә икән. Күпләре бөтенләй өйләнми, буйдак булып яшәүне өстенрәк күрә.

Тел

Занзибарда суахили телендә сөйләшәләр. Аңлавыбызча, әлеге телдә гарәп сүзләре байтак, димәк, гарәпчә белүчеләргә аралашу авыр булмаячак.

Ә бу сүзләрне белү ялыгызны күпкә җиңеләйтәчәк. Җирле халык сөенәчәк! Исегездә калдырыгыз: абари – хәлләр ничек, асанте – рәхмәт, асанте навеве – үзегезгә рәхмәт, таму – тәмле, ситаки – юк, кирәкми, самаки – балык, натака чакула – ашыйсым килә.

Флора һәм фауна

Күпләр Африкага кыргый җанварлар очратудан куркып бармый. Бөҗәкләр тешләп, төрле авырулар ияртүдән дә шүрлиләр. Занзибар материктан шуның белән аерыла да – анда куркыныч кыргый хайваннар юк. Черкиләрне якын китерми торган спрейлар да кулланырга туры килмәде.

Барысын да алдан белеп барсаң, кәеф төшмәскә әйбәтрәк була...

Занзибар яшеллеккә күмелгән: кая карасаң да кокос пальмалары үсә. Манго һәм мангро агачлары очрый. Мангодан көймәләр ясыйлар икән, ә мангро нык агачлардан санала. Нәрсә төртсәң, шул үсеп чыкса да, җирле халык өй тирәләрендә чәчәк ата торган куаклар, агачлар утыртып мәшәкатьләнми. Аның каравы, банан бакчаларын, дөге һәм кукуруз кырларын күп күрдек.

Зур-зур әкәм-төкәмнәр, кыслалар күрергә була. Су киткәндә, кыслалар комны казып оя ясый, якыная башласаң, бик тиз шунда кереп качалар.

Отелебездә маймыллар бар иде. Бездән киңәш: тыныч кына ял итәргә теләсәгез, аларны ашатмагыз. Беренче мәлдә бу, әлбәттә, кызык тоелачак, әмма бераздан ялкытачак – берәр җиләк-җимеш чыгарып биргәнче, балконнан китмичә, кычкырып утырачаклар.

Һава торышы

Занзибарга җыенсаң, шуны онытмаска кирәк: ул җирнең икенче ягында – бездә җәй булганда, аларда – кыш. Дөрес, аларның кышы бөтенләй башка: бездә кайбер җәйләр дә алай җылы булмый – температура 22 градустан түбән төшми. Ә җәен анда бик эссе. Кызу яратмыйсыз икән, Занзибар кышын күрергә дип барыгыз.

Нәрсә алып кайтырга?

Иң күп сораулар, әлбәттә, кабырчыклар турында. Ярамый дигән сүз бар барын, әмма бөтен кеше дә алып кайта бугай. Бакшиш түләсәң (әллә штраф, әллә «взятка» бу – аңламадым), хәтта иң зурларын да алып чыгарга мөмкин, диләр. Һәрхәлдә, безнең группадан берәүне дә туктатмадылар.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA

АВЫЗЫҢНЫ АЧЫП ЙОКЛАСАҢ...



Нәкыйп КАШТАНОВНЫ республикада белмәгән кеше юктыр да. Ул – танылган доктор-пульмонолог. Хезмәттәшләре аны галим-доктор дип йөртә. Һәм бу юкка гына түгел. Аның фәнни хезмәтләренә зур бәя бирелде. Ул утыздан артык җыр авторы. Табибның бүгенге көндә 29 китабы дөнья күрде! Кешенең чирен генә түгел, җанын дәвалаучы уникаль табиб безгә йогышлы чирләр арасында үлем-китү ягыннан афәтле төс ала барган күренешнең берсе – пневмониянең килеп чыгу сәбәпләре турында сөйли. Кисәтү, дәвалау юлларын өйрәтә.

Пневмония турында безнең эрага кадәр 460 нчы елларда яшәгән Гиппократ заманнарыннан ук белгәннәр. Гиппократ үпкә ялкынсынуын бөтен организмның авыруы дип санаган. Ләкин аның үпкә сүрүе – эмпиемасы турындагы фикерләре тора-бара онытылган. Галимнәр бу чирне дәвалау өчен хәтта кан алдыру ысулларын да кулланып караган. Тик үлем-китемнәр һаман арта гына барган.

Шулай да үпкә ялкынсынуын ничек булдырмый калырга соң? Без бит һәрчак, чирне дәвалаганчы, аны кисәтү җиңелрәк, дибез. Фәнни мәгълүматларга караганда, хәзерге вакытта иң нәтиҗәле чара – пневмококк һәм гриппка каршы вакциналар. Экспертлар фикеренчә, бу чир куркынычы янаган төркемгә керүчеләрнең барысына да (бигрәк тә 65 яшьтән соң) шул вакцинаны ясату мәҗбүри.

Пневмонияне кисәтү өчен башта аның килеп чыгу сәбәпләрен ачыкларга кирәк.

СӘБӘПЛӘРЕ: ГЫРЛАУ ҺӘМ АВЫЗЫҢНЫ АЧЫП ЙОКЛАУ

Пневмония – ул барыбызны бертигез борчый торган җитди проблемаларның берсе. Аның килеп чыгышы, сәбәпләре ахыргача өйрәнелмәгән. Димәк, без әле аны дәвалауда бөтен мөмкинлекләрдән дә файдалана алмыйбыз. Мин бу мәсьәлә белән күптәннән шөгыльләнәм. Авырулар белән алып барылган шәхси күзәтүләр, тикшеренүләр нәтиҗәсендә бу чирнең, нигездә, салкын тиюдән түгел, бәлки, авызыңны ачып, гырлап йоклаудан килеп чыгуы ихтимал дигән фикергә килдем. Дөрес, салкын тию үпкәнең сулыш юлларына азык калдыкларын «ташу» өчен әйбәт шартлар тудыра тудыруын. Әмма төп сәбәбе – әйткәнемчә, азык калдыкларының (бигрәк тә ит һәм колбаса) йогышлы микроб колониясе рәвешендә үпкәнең сулыш юлларына килеп эләгүенә бәйле. Әйтик, кеше уңайсыз ятып, гырлап йоклап китә. Авыз ачык, теш чистартылмаган (кайберәүләр иртән генә чистарта)...

Әйе, салкын тию, йә булмаса йогышлы вирус та пневмониягә илтеп җиткерергә мөмкин. Ә сәбәбе бер үк: хаста кеше, борыны тыгылу аркасында, авызын ачып йоклый. Әгәр дә борын сулаunion, теш аралары чиста булса, авызыңны ачып йоклау куркыныч түгел. Бу очракта пневмония булмый! Мәгълүм ки, «уңышлы» мохиттә микроблар тиз таралучан. Азыкны әзерләгәндә чисталык саклау мәҗбүри: чиста савыт-саба, чиста кашык... Пневмонияне кисәтү өчен әллә ни күп тә кирәк түгел үзе. Мөһим булган тагын бер нәрсәне әйтәсе килә: йоклаганда гырламас өчен ашамаска кирәк, йокы бүлмәгездә температура 24–25 градус чамасы булырга тиеш! Һәм, әлбәттә инде, уңайлы урын-җир. Ләкин гырлау һәм авызны ачып йоклау үзеннән-үзе пневмониягә китерми. Югыйсә бөтен дөнья «үлеп» беткән

Киңәш

- 6:180 күләмендә алтей тамыры төнәтмәсен 2 сәгать саен 1 аш кашыгы эчәргә;
- 40 грамм алтей тамыры, 15 грамм татлы тамыр (солодка), 10 грамм фенхель җимеше. Кайнатып, катнашманы җылы килеш 2-3 сәгать саен 2 аш кашыгы эчәргә (йөткерүне йомшарта);
- девясил тамырында эфир майлары һәм Е витамины бар. Шуны 20:200 нисбәтендә кайнатып, көненә 3-5 аш кашыгы эчәргә;
- 25 грамм чабыр (чабрец) үләне, 20 грамм өч төсле миләүшә үләне, 20 грамм нарат бөресе, 15 грамм бака яфрагы (подорожник), 10 грамм сазлыкта үсүче киптерелгән үлән. Стаканга төнәтмәнең дүрттән бер өлешен салып, ашар алдыннан җылы килеш 4-5 мәртәбә эчәргә кирәк.

булыр иде инде. Кабатлап әйтәм: авыз куышлыгындагы теш арасына кысылып калган ит, колбаса кисәкчекләре «бактерия колонияләрен»ә юл ача. Алар бронхны томалап, бер төн эчендә пневмония, абсцесс, алга таба гангрена китереп чыгарырга да мөмкин. Ә инде чирнең азу-азмавы күп очракта йогышлы чирләргә каршы тора алучанлык дәрәҗәсенә, организмның торышына (ару, тиешенчә тукланмау), төрле авыруларга (шикәр диабеты, иммунитет кытлыгы); бактерияләрнең нинди һәм ни күләмдә булуына, авыруның үз организмына мөнәсәбәтенә; табиб киңәшләрен төгәл үтәвенә; режим һәм диета саклауга бәйле. Дәвалау комплекслы алып барылырга тиеш. Биредә антибиотиклар куллану гына аз, организмны ныгыта торган витаминнар эчү дә зур әһәмияткә ия.

БЕРЕНЧЕ БИЛГЕЛӘРЕ: БИЗГӘК ТОТУ, ЙӨТКЕРҮ, ТЕМПЕРАТУРА ҺӘМ ТЫН КЫСЫЛУ

Еш кына ул әнә шулай башланып китә. Йөткергәндә күкрәктә авырту сизелеп куя. Пациент шулай дип әйтсә, шундук пневмониягә шик туа. Тикшеренүләр шуны раслый гына. Мондый кеше үзендә хәлсезлек сизә, тиз арый. Өлкәннәр исә кинәт ябыга, ашыйсы килмәүгә зарлана. Бүген дөрес диагноз кую өчен бөтен шартлар тудырылган. Аның иң үтемлесе – нурланыш диагностикасы. Рентген тикшеренүләр нәтиҗәсендә әлеге чирдән җәфаланучыларның 90 процентын күзәтү астына алып дәваларга була. Хәзер компьютер технологиясе дә ярдәмгә килә. Аннары канга җентекле анализ үткәрү дә яхшы нәтиҗә бирә. Монысы инде авыруның тәмам терелеп җитүенә ышану өчен мөһим.

Шулай да чиргә тамыр җәеп җибәрергә ирек бирмәскә кирәк. Үзгәрешләрне вакытында сизеп алсаң яхшырак. Чир тизрәк чигенәчәк. Үзегезгә игътибарлы булыгыз! Температура 39 һәм аннан да югары булса, алда әйтелгән билгеләр күренә башласа, кичекмәстән табибка күренергә киңәш итәм.

КЕМНӘР АВЫРЫЙ

Бу чир урта һәм өлкән яшьтәгеләр арасында була. Тәмәке тартучылар, сулыш органнары, бөер белән проблемалары булучылар, шикәр диабетыннан, алкоголизмнан җәфаланучылар, организмда теләсә нинди бер йогышлы чир йөртүчеләр, урын өстендә озаклап ятулар, күкрәккә һәм эч куышлыгына операцияләр, баланы яткан килеш ашатулар һәм башкалар (бала, урынга салуга, ашаганын косып чыгарырга һәм шул чагында азык калдыклары тын юлына эләгергә мөмкин) – болар барысы да әлеге чиргә сәбәпче. Пневмонияне дәвалауга бик җитди карарга киңәш итәм. Күп кенә даруларның кирәкмәгән өстәмә реакция бирүен беләбез. Шуның өчен даруларны табиб киңәше белән генә файдаланырга кирәк. Әгәр дә аның кире тәэсирен тойсагыз, бу хакта шундук табибка хәбәр итегез. Аларның кайберсе йөткертә, үпкәдә ялкынсыну китереп чыгара. Гырлау һәм авызны ачып йоклаудан кисәтү чаралары вакытында күрелә һәм ул үпкә авыруларын киметүгә китерә икән, бу бары күзәтү-тикшеренүләремнең дөреслегенә, тырышлыгымның юкка китмәвенә тагын бер мәртәбә дәлил генә булачак.

...Нәкыйп Каштановның «Новый взгляд на пневмонию и частные вопросы пульмонологии» дип аталган фәнни басмасында бу хакта бик җентекләп язылган. Автор пневмониягә кагылышлы мәсьәләләрдә медицинада моңарчы булмаган ачыш ясый: гырлаганда һәм авызны ачып йоклаганда, гигиена сакламаганда пневмониягә китереп җиткерергә мөмкин!

Пневмонияне кисәтү чаралары

- салкын тиеп, борын тыгылганда, авыз аша сулаганда, кичекмәстән дәвалау чарасына керешергә;
- алдагы тешләрнең булмавы, тешләрнең бозылуы шулай ук җитди сәбәп. Авыз куышлыгын, теш араларын җеп яисә теш щеткасы белән чистартып торыгыз;
- исегездә тотыгыз: ашаганда сөйләшергә ярамый, азык тын юлларына үтеп керергә мөмкин;
- әни кешенең имезер алдыннан күкрәген юмавы, бәләкәчен уңайсыз яткырып ашатуы, баланың сөтне косып чыгаруы нәтиҗәсендә дә пневмония булуы ихтимал. Баланың сәламәтлеге аның ничек ятуына нык бәйле. Күкрәк баласын утырган килеш имезергә кирәк, ашатканнан соң шундук урынга салырга ярамый;
- зуррак яшьтәге балаларда ул әлеге дә баягы авызны ачып йоклаудан яисә салкын тиюдән була;
- пневмония белән авырганда, табиблар антибиотикны бары бактерияле инфекция булганда гына билгелиләр;
- диагностиканың төрле алымнарыннан файдаланырга кирәк;
- терапия, иң элек, микробларны киметүгә юнәлтелгән булырга тиеш;
- бактериягә каршы терапия үткәргәндә чирнең килеп чыгышына игътибар итү зарур.

Мәдинә АВЗАЛОВА әзерләде.

PRESSA

КҮЗЕҢНЕ ЯШЬТӘН САКЛА



Кеше мәгълүматның 80–90 процентын күзләре аша ала, диләр. Күзләр – дөньяга ачылган күңел тәрәзәләребез. Аларда көн дә кояш нуры чагылсын, бәхет балкысын өчен, балачактан ук сакларга кирәк. Бүгенге телевизор, компьютер, телефон заманында моны ничек башкарырга? Казан шәһәре 3 нче поликлиникасының консультатив-диагностика бүлеге мөдире, табиб-офтальмолог Диләрә ШӘЙДУЛАТОВА белән балаларның күзләрен саклау, иң еш очрый торган күз авырулары хакында сөйләшербез.

Бүгенге балалардагы күз авыруларын замана чире дисәң дә була. Техника алга киткән заманда күзләргә көчәнеш арта гына бара. Балалар кече яшьтән техника белән «син» дип кенә сөйләшә, аларны смартфон, телефоннардан аерып алуы да кыен. Бер яктан, смартфоннар балаларга өстәмә белем чыганагы да. Икенче яктан, кечкенә экранга озаклап текәлеп карау күзләргә көч китерә.

Ә тулаем алганда, табибка күбесенчә рефракция, ягъни күзнең оптик системасы бозылу аркасында начар күрү сәбәпле мөрәҗәгать итәләр. Мәктәп укучыларында бу, гадәттә, күрә карау – якыннан яхшы күреп тә, ерактагысын күрмәү. Кече яшьтәге балаларда киресенчә – югары гиперметропия (якыннан начар күрү) күзәтелә. Югары гиперметропия үз чиратында амблиопиягә, кылый күзлеккә, тумыштан килгән күрә карауга китерергә мөмкин.

Соңгы елларда мәктәп укучыларында миопия бер афәткә әверелде дисәң дә була. Башлангыч сыйныфларда ул балаларның 30 процентында ачыкланса, 9–11 нче сыйныфларда инде 70–80 процент укучыда күзәтелә. Күзләргә авырлык елдан-ел арта бара.

Укучылар арасында якыннан начар күрүчеләр дә бар, ләкин ул аның кадәр массачыл төстә түгел. Балаларның бик күбесе ерактан күрми. Әлеге аномалиянең сәбәбе – күз алмасының озынаюы. Шуның аркасында күзнең челтәр катлавында сурәтләр юньләп фокусланмый, бала ерактагы предметларны тонык итеп күрә башлый.

Дәвалау әлеге патологиянең ничек тиз үсүенә бәйле. Елына бер диоптриядән күбрәк артучы миопия кичекмәстән дәвалауны сорый. Югыйсә күз төбендә җитди үзгәрешләр башланып, кеше өлешчә сукыраерга да мөмкин. Ерактан начар күрүче балаларга дәваны мөмкин кадәр тизрәк башларга кирәк.

Баласының күзләрендә үзгәреш булуын әти-әниләр үзләре дә сизә ала. Беренчедән, еракка караганда ул күзләрен кыса. Класста арттагы парталарда утыра икән, начаррак укый башлый, язганда өстәлгә иелә, телевизорның каршысына ук утырып карый... Кайчагында балага туры караганда бер күз алмасы борынына яки чигәсенә таба авыш күренә. Болар барысы да тизрәк күз белгеченә күренү өчен сәбәп булып тора.

Баланы болай да елына бер тапкыр күз табибына күрсәтү мөһим. Яңа туган баланы бер айдан ук офтальмологка алып килергә кирәк: тумыштан килгән кимчелекләр юклыгын ачыклар өчен бу. 1 яшендә күзнең рефракциясен ачыклыйлар, кирәк булса, күзлек билгеләнә. 3 яшендә күзнең үткенлеген тикшерәләр. Начаррак күрсә, күзлек белән бергә, махсус аппарат белән дәва курсы билгеләләр. Мәктәпкә керер алдыннан баланы кабат табибка күрсәтү мәҗбүри.

Хәзер күзләрне дәвалау ысуллары да, мөмкинлекләр дә күп. Заманча магнитотерапия аппаратлары, лазер белән дәвалау, аккомодация күнегүләре – болар баланың күрү сәләте алга таба начарланмасын өчен кулланыла.

Әти-әниләргә әйтәсе килгән сүзем – гаджетлар белән сак булырга. Беренчедән, гаджетлар белән эшләүнең вакытын чикләргә. Икенчедән, экранның зурлыгына игътибар итәргә. Экран никадәр кечерәк булса, баланың күзләренә дә шуның кадәр күбрәк көч килә. Иң зыянлысы – телефон, ул сөйләшер өчен генә кулланылсын, уеннар уйнар өчен түгел. Уку өчен компьютер яки ноутбук кулай.

Балагызның тактада язганнарның барысын да укый алу-алмавы, ерактагы әйберләрне ничек күрүе, телевизорны кая утырып каравы белән кызыксыныгыз. Теләсә нинди тайпылыш сездә шик уятырга һәм кичекмәстән табибка барырга этәргеч булырга тиеш. Күз авыруларын башлангыч стадиядә кисәтү – балага яхшы күрү бүләк итү дигән сүз.

Киңәш

- А витамины күзнең челтәр катламындагы таякчыклар һәм көпшәчекләр эшен яхшырта.
- Күз өчен бик тә кирәкле бета-каротин кишердә генә түгел, яшел төсле яшелчәләрдә дә күп. Мәсәлән, шпинатта, кузгалакта, аш тәмләткеч үләннәрдә.
- Бета-каротин фәкать майлар белән бергә кулланганда гына үзләштерелә.
- Күзләргә составында кальций булган ризыклар һәм терлек итләре файдалы.
- Кызыл, сары төсле яшелчә һәм җиләк-җимештә күз күремен яхшыртучы лютеин бар.
- Кышкы-язгы вакытта балаларның рационын махсус витаминнар белән баетырга тырышыгыз.

ВАРИКОЗ – НӘСЕЛ ЧИРЕ



Варикоз – тире астындагы вак веналарның киңәюе – еш очрый торган чирләрнең берсе. Лифтка керсәң дә, транспортка утырсаң да, варикозны яңа ысуллар белән дәвалаучы үзәкләрнең рекламаларына юлыгасың. Нинди чир соң ул һәм рекламада күрсәтелүче ул ысуллар чынлап та ышанычлымы? Бу хакта медицина фәннәре кандидаты, Казан шәһәре 7 нче клиник хастаханәсенең кан тамырлары хирургиясе бүлеге мөдире Илдар ХӘЛИЛОВ белән сөйләшәбез.

«Миңа калса, кешеләрне варикоз белән чамадан тыш куркыталар. Әлеге чир турында сөйләгәннәрнең күбесе дөреслеккә туры килеп бетми. Безгә варикозлы пациентлар еш мөрәҗәгать итә. Күбесе рекламадагы дәвалау үзәкләрендә булып, андагы мәгълүматтан югалып калучылар. «Кичекмәстән операция ясатмасагыз, ахыры бик хәтәр, хәтта үлем белән дә тәгәлләнергә мөмкин», – диләр аларга. Варикоз үлемгә китерә торган чир түгел. Гомере буе варикоз белән яшәп, 90 яшенә җитүчеләр дә бар.

Алай да иң беренче сорауга җавап бирик әле – каян килеп чыга ул? Күпләр уйлаганча, авыр күтәрүдән генә барлыкка киләме?

Иң төп сәбәп – нәселдәнлек. Веналар кан тамырларының каркасы зәгыйфь булудан киңәя. Ә моның өчен геннар гаепле. Әгәр дә каркас нык булса, авыр күтәргәннән дә, аяк өстендә озак басып торганнан яки биек үкчә белән йөргәннән генә варикоз барлыкка килми.

Веналарның каркасы тумыштан ук зәгыйфь булып, кеше гомере буе аяк өсте эшли, авыр күтәрә икән, билгеле, кан тамырлары киңәя.

Күп очракта хатын-кызларда варикозның беренче билгеләре йөклелек чорында беленә башлый. Сәбәбе – карындагы яралгы оча сөягендә урнашкан кан тамырларын кыса, веналардагы кан тулысынча куылып бетми – тамырларга көч килә. Бу чорда гормоннар үзгәреше күзәтелә, шуңа да кан тамырларының тотрыклылыгы кими.

Кан тамырларының эчендә кечкенә генә клапаннар бар. Аяк веналарында кан астан өскә таба йөри. Әлеге процесста әнә шушы клапаннар да катнаша – канны өскә куып, алар ябылалар һәм кирегә агарга ирек бирмиләр. Ә кан тамырлары киңәйгәч, клапаннар тулысынча ябылып бетми, веналарда кан тоткарлыгы күзәтелә. Шуның нәтиҗәсендә тромблар барлыкка килергә мөмкин. Тромбларның кайчак эчке веналарга үтеп керү ихтималы бар, ә менә бу, чынлап та, куркыныч диагноз. Варикоз белән мөрәҗәгать итүчеләрнең 30-40 процентында канны кирәгеннән тыш куертучы ген булуы ачыклана.

Варикоз үзе алты стадиядә уза.

Башта әле бернинди дә уңайсызлык сизелми. Нәселендә кан тамырлары киңәюдән интегүчеләр булуы гына кешене сагаерга мәҗбүр итә.

Аннары аяк балтырларында, тез астында вак веналар күренә башлый.

Соңрак аякларда авырлык, шешенү, кычыту сизелә.

Алга таба төнлә балтырларны көзән җыеру башлана. Көзән җыерганда җылымса ванна ясау булыша.

Варикоздан иң яхшы профилактика – йөзү. Йөзгәндә аякларга вертикаль басым юк, шул ук вакытта балтыр мускуллары эшли. Яткан килеш әйләндерелүче велосипед тренажеры да әйбәт.

Мускулларның һәм веналарның тонусын күтәрүгә дә игътибар итәргә кирәк. Аның ике юлы бар. Беренчесе дарулар – флеботониклар куллану. Икенчесе – механик юл – махсус трикотаждан бәйләнгән оеклар кию.

Тромб барлыкка килмәсен өчен, күп су эчүне гадәткә кертү мөһим.

Варикозны, гадәттә, операция юлы белән дәвалыйлар. Ул да берничә төрле. Иң ышанычлысы – классик операция. Бу очракта киңәйгән венаны алып ташлыйлар.

Веналарга операция лазер яки радиоешлык ярдәмендә дә ясала. Зәгыйфьләнгән кан тамырына электрод үткәреп, эчке венага тоташкан урында аның стеналары эретеп ябыштырыла. Бу тиз, җәрәхәтсез ысул, ләкин рецидив булырга мөмкин.

Радиоешлык белән ясаганда лазер урынына радиодулкыннар кулланыла.

Химик ысулы да бар: веналарны махсус препарат белән эретеп ябыштыралар. Кемгә нинди ысул кулайрак буласын, әлбәттә, табиб – кан тамырлары хирургы билгели.

Миф һәм чынбарлык

■ **Җәяү йөрергә ярамый.** Чынлыкта, җәяү йөрергә кирәк. Ләкин кемдер өчен ул – берничә йөз метр, кемдер өчен – берничә чакрым. Аяк сызлый, көзән җыера икән, димәк, артыгы йөрелгән. Ә менә бер хәрәкәтсез, озак вакыт аяк өстендә басып торырга ярамый – кан тамырларына көч килә.

■ **Авыр күтәрү тыела.** Җиңел генә кул йөгеннән зыян булмас.

■ **Кояшта кызыну зарарлы.** Сәгатьләр буе эссе кояш астында ятмыйча, чамасын гына белеп кызынырга була.

■ **Кайнар мунчага кермәскә!** Ләкин кайнар ванна куркынычрак. Кан тамырлары киңәйгәндә аякларны җылы суга озак тыгып тору зыянлы.

■ **Үкчәле туфли кияргә ярамый.** Көне буе биек үкчәдән йөрү беркемгә дә ярамый. Үкчә 4 сантиметрдан артык булса, балтыр мускуллары эшләми, веналарда тоткарлык барлыкка килә. Көнгә 2-3 сәгатьтән арттырмыйча, үкчәле аяк киеме кию зыян итмәс.

PRESSA



Бу ризыкка шушы исемне бирүебез юкка түгел. Яшәртүче аш дип тә карарга була аны – яшелчәләр организмны яшәртә, билгеле, яшьләр ярата торган дип тә... Ләкин безнең очракта ул яшьлек хатирәләренә бәйле. «1983–1984 еллар иде. Беренче курста укыган чак, – дип, шушы ризыкка бәйле хатирәсе белән уртаклашты мастер-классыбызның бүгенге хуҗабикәсе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты, «Татаркино» комитеты директоры, «Мөселман киносы» халыкара фестиваленең башкаручы директоры Миләүшә АЙТУГАНОВА. – Без Севастопольгә бардык. Баклажан белән дә беренче тапкыр шунда таныштым. Аннан ни генә әзерләмиләр икән! Миңа иң ошаганы – тәгәрмәчләп кыздырып, өстенә сарымсак сипкәне булды. Әнә шул елдан бирле бу яшелчә белән дуслыгым нык». «Яшьлек» ашы... матур яңгырый бит! Һәм бик тәмле! Әзерлибезме!



Кирәк

- 600-700 г сөяксез ит;
- 3 баклажан;
- 2 кишер;
- 2 суган;
- 2 помидор;
- 250 г каты сыр;
- 3 тырнак сарымсак;
- 4-5 караҗимеш;
- бер уч әстерхан чикләвеге (30-50 г);
- үсемлек мае;
- аш тәмләткеч үләннәр (базилик, тмин)

тәменчә тоз һәм кара борыч.

МИЛӘҮШӘ АЙТУГАНОВАДАН «ЯШЬЛЕК» АШЫ


Фото: Ксения Богданова

Эш барышы

■ итне вак шакмаклап турап, табада яки сотейникта болгаткалап кыздырабыз. Шунда ук кара борыч, аш тәмләткеч үләннәрне сибәбез. Бераз кыздыргач, утны киметеп, 10-15 минут томалап пешерәбез.

■ шакмаклап туралган баклажанны үсемлек мае салынган тирән табада (моның өчен вок-таба кулай) кыздырабыз. Ул әзер диярлек булырга, ләкин изелмәскә тиеш.

■ Аерым табада вак итеп туралган суган белән эре угычтан уылган кишерне кыздырабыз. (Май салмыйча, аз гына су салып, йомшартып кына алсаң да ярый.)

■ Помидорларның өске ягын пычак очы белән ярып җибәреп, 3-4 минутка кайнар суга салып торабыз (кабыгы юка булса, 2 минут та җитә). Кабыгын кубарып, шакмаклап турыйбыз.

■ Сарымсакны исә пычак йөзе белән изеп, кабыгын чистартабыз, шулай ук ваклап турыйбыз.

■ Баклажан янына итне, помидор белән сарымсакны, кыздырылган суган белән кишерне салып, сак кына бутыйбыз. Тәменчә тоз һәм аш тәмләткеч үләннәр кушабыз.

■ Чиста табага итле баклажаннарны тигезләп салабыз. 4-5 урынга юылган караҗимеш батырабыз, ваклап туралган әстерхан чикләвеге сибәбез. Иң өскә мул итеп уылган сыр түшибез.

■ Сыр эреп, алтынсу төскә кергәнче, табаны кайнар мичкә куеп алабыз.

■ Табынга биргәндә өстен ваклап туралган петрушка белән бизибез.

Мастер-класс «Беседка» иҗат студиясендә уздырылды.



РЕКЛАМА

Ситора Захаровадан



Кирәк

- 1 кг уртача зурлыктагы баклажаннар;
- 3-4 кишер;
- 1-2 баш сарымсак;
- 1 уч яшел укроп;
- тәменчә тоз, борыч.

Эш барышы

■ баклажаннарны юып, кабыгыннан чистартып, урталай кисәбез.

■ Кәстрүлдә кайнап торган тозлы суга салып, 2-3 минут пешереп алабыз. Алар «тере» булырга, артык пешеп йомшармаска тиеш.

■ Юылган кишерне уртача тишекле кыргычта уабыз, укропны, сарымсакны вак кына итеп турыйбыз.

■ Аннары барысын бергә кушып, тоз сибәбез, бераз кара борыч өстибез.

■ Баклажанның бер яртысына әлеге катнашманы мулдан салып, икенче яртысы белән каплыйбыз, тыгыз булсын өчен җеп белән бәйлибез.

■ Кәстрүлгә тутырып, авыр әйбер белән бастырып куябыз да 10-14 көнгә суыткычка тыгабыз.

■ Баклажаннар тозлы гөмбә кебек бик тәмле була.



ҮСЕМЛЕК СӨТЕ

Дөрес тукланучылар терлекчелек тармагында җитештерелгән азык-төлектән баш тартып, үсемлекләрдән алынган аксымнарга өстенлек бирә. Хәтта сөтнең дә үсемлекләрдән генә ясалганын сайлыйлар. Ул бик шифалы, аны даими куллану организмны сәламәтләндерә, кирәкле микроэлементлар, витаминнар белән баета. Бүген андый сөтне инде кибетләрдән дә табып була. Ләкин мин аның үзем ясаганын кулайрак күрәм.

Солы сөте

- кан тамырларын артык холестериннан чистарта, йөрәк авыруларын кисәтү өчен менә дигән чара булып тора;
- ашказаны һәм эчәклекнең эчке катлавын зарарлы микроорганизмнардан саклый;
- матдәләр алмашын җайга сала, уткудыргыч үзлеккә ия. Ябыгырга теләүчеләр өчен ул – табыш, чөнки калориясе аз;
- файдалы матдәләргә бай: составында В төркеме витаминнары, тимер, кальций, фосфор һәм кремний күп. Ул менә дигән антиоксидант;
- солы сөте белән юыну бит тиресенең күзәнәкләрен тарайта, тирене яшәртә.

Солы сөте ясау

50 грамм солы лавачына (25–30 минут пешә торганын сайлау отышлы, анда файдалы матдәләр күбрәк саклана) 500 мл су алына. Солыны блендер касәсендә җебетсәң дә була. Аны 10 сәгать бүлмә температурасында тотабыз. Тиешле вакыт чыккач, барысын бергә блендер белән яхшылап туглыйбыз (югары тизлек режимында). Барлыкка килгән сыеклыкны вак иләк аша сөзәбез. Солы сөте менә шушы була инде. Теләсәгез, аңа бал куша аласыз. Файдалы да, тәмле дә эчемлек әзер.

Кокос сөте

- матдәләр алмашын яхшырта, организмны шлаклардан, токсиннардан арындыра; тулысынча эшкәртелүе һәм үзләштерелүе белән кыйммәт;
- составында лаурин кислотасы булганлыктан, антибактериаль үзлеккә ия, иммунитетны ныгыта; кан басымын көйләү сәләте исә калийга бай булуы белән аңлатыла;
- А, В, С, У витаминнары чыганагы; андагы магний нервыларны тынычландырырга, мускулларның киеренкелеген киметергә, йокысызлыкны җиңәргә булыша;
- сөякләрне ныгытучы фосфатка бай; кокос сөтен даими куллану кандагы шикәрне нормальләштерә, ашказаны-эчәклекнең эшчәнлеген көйли;
- кокос сөте белән битне чистартсаң, үлекле бетчәләрне бетерә.

Кокос сөте ясау

Бер кокос чикләвеген ачып, эчендәге йомшагын кырып алабыз һәм кисәкләргә ваклап, төнгә су белән чылатып калдырабыз. Иртән суын түгеп, кокос йомшагын чиста суда яхшылап юабыз. Блендер касәсенә кокос һәм аннан ике тапкырга күбрәк күләмдә су салып (1х2 нисбәтендә), туглыйбыз. Барлыкка килгән сыеклыкны вак иләктән сөзәбез. Кокос сөте үзе генә дә бик тәмле, теләгән кеше бер чәй кашыгы бал да куша ала. Аның майлы булуын да истән чыгарырга ярамый. Кокос сөте нигезендә банан һәм грушадан баллы смузилар ясамау хәерлерәк. Май белән шикәрне бергә катнаштырырга ярамый, ул ашкайнату системасында проблемалар китереп чыгарырга мөмкин.
Кичтән суыткычта калдырылган сөт өстенә кокос мае утыра. Аны җыеп алып, ризыклар әзерләгәндә кулланып була.
Кокос мае бит тиресе (күз тирәләреннән тыш) һәм чәчләр өчен дә файдалы.

Игътибар! Үсемлек сөтенең суыткычта саклану вакыты өч тәүлек кенә.

Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА әзерләде.

КАРТЛЫК, БЕЗДӘН ЕРАК ТОР!

Шиацу – биткә көндәлек ясый торган массажны японнар шулай дип атый. Кагыйдәләре шәрык хатын-кызларына күптәннән билгеле, бәлки шуңа да гел яшь күренәдер әле алар. Иң беренче һәм иң мөһим кагыйдә – даимилек. Шиацуга иртән яки кичен, битне чистартканнан соң керешәләр. Икенче кагыйдә – тирене тартмаска, җиңелчә генә баскаларга!



■ Тонус өчен: чигәдә бармак белән баскач авырта торган ноктаны табабыз. Бармак битләре белән түгәрәк хәрәкәтләр ясап, борын канатларыннан шушы ноктага таба менәбез.



■ Караш балкып торсынга: күзләрнең эчке почмагына өч секунд дәвамында баскалыйбыз. Шушы күнегүне өч тапкыр кабатлыйбыз.



■ Муен асылынмасын өчен: кул аркасы белән муенның уртасыннан ике якка таба җиңелчә генә ышкыйбыз.



■ Маңгайдагы җыерчыклардан арынабыз: ике кулның бармаклары белән маңгайның уртасына ярты минут баскалыйбыз. Аннары кулларны чәч төпләре буйлатып чигәләргә таба йөртәбез.



■ Авыз-борын тирәсендәге тирән җыерчыкларны киметү өчен: урта бармак бите белән борын канатыннан ирен читенә кадәр җиңелчә генә баскалап төшәбез.



■ Нервыларны тынычландыру өчен: кулларны муен артына куеп, башны артка таба этәбез, ләкин куллар белән нык итеп тотып торабыз.


Немец косметологы Клаудиа Фрейлих күнегүләре



■ Күз кабаклары асылынмасынга: бармак бите белән каш өстендәге тирегә нык кына итеп басабыз, үзебез шул ук вакытта кашны күтәрергә тырышабыз.



■ Авыз мускулларын ныгытабыз: алты секунд дәвамында хыялыбыздагы тузганакны өреп очырабыз. Соңыннан елмаябыз.



■ Муен шома булсын дисәк: башны артка ташлап, аскы иренне өскесе өстенә меңгерәбез. Алты секунд шулай торабыз. Күнегүне берничә тапкыр кабатлыйбыз, башны, чиратлаштырып, уңга һәм сулга борабыз.




■ Аскы күз кабаклары асылынмасынга: бармак битләре белән яңак сөягенә нык кына басып, күзләрне башта йомшак кына, аннары чытырдатып йомабыз.



■ Өске күз кабаклары өчен: бармаклар белән каш сөягенә нык кына басып, кашларны өскә күтәрәбез, ә күзләрне чытырдатып йомабыз. Алты секундтан җибәрәбез.



■ Яңаклар шәлперәймәсен дисәк: яңак мускулын катырып, авыз читен башта өскә күтәрәбез, аннары аска төшерәбез. Берничә тапкыр кабатлыйбыз.



■ Биттәге җыерчыклардан: ике кулның бармаклары белән битнең тиресен җиңелчә генә тарттырып, «О» һәм «У» авазын сузабыз. Күнегүне берничә тапкыр кабатларга кирәк.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.
Рәсем: Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА.



ӘЧЕМЕ, СЕЛТЕЛЕМЕ?

Артык зур көч куймый гына яхшы уңыш алу өчен туфракның ашланган булуы гына җитми әле, аның әчелеген дә нормага китерергә кирәк. Туфракның әчелеген берничә дәрәҗәдә билгелиләр: бик әче, әчелеге аз, нейтраль, селтеле туфрак. Ул pH күрсәткече белән билгеләнә, pH 7 булса – нейтраль; 5-6 – әчелеге аз; 3-4 – бик әче туфрак, pH 8-9 туфракның нык селтеле булуын аңлата.

■ Бакчадагы җирнең әчеме-юкмы икәнен ачыклауның иң дөрес юлы – лабораториядә тикшертү. Андый мөмкинлек булмаса, өй шартларында да билгеләргә мөмкин. Әйтик, лакмус кәгазе ярдәмендә.

■ Аш серкәсе белән дә тикшереп карый аласыз. Бер уч туфракны яңгыр суы белән юешләп, бер аш кашыгы аш серкәсе салалар. Әгәр дә күбекләнсә, туфрак селтеле. Аз гына күбекләнсә, нейтраль. Берниндидә реакция булмаса, димәк, әче.

■ Акбур оны белән дә сынап карап була. Пыяла шешәгә 2 аш кашыгы туфрак алына, шуңа 5 аш кашыгы җылымса су һәм 1 чәй кашыгы акбур оны салына. Шешә авызына эчендәге һавасы чыгарылган бармакча кидерелә. Шешәне яхшылап селкеткәннән соң бармакча «торып басса» – туфрак әче, яртылаш кына турайса – әчелеге аз, ничек бар шулай калса – нейтраль.

■ Бакчада үскән чүп үләннәре дә туфракның составын «әйтеп бирә». Мәсәлән, ат кузгалагы, ала миләүшә, наратбаш, бака яфрагы, ак клевер, бөтнек әче туфракны ярата.

■ Әчелеге аз яки нейтраль булган туфракта эт әчәгесе, кычыткан, каты билчән, үги ана яфрагы, иссез ромашка, гади сарут, көтүче сумкасы яхшы үсә. Анда-санда үскән бер-ике үсемлек кенә берни дә сөйләми, билгеле, алар төркем булып үссәләр генә ниндидер нәтиҗә ясап була.

■ Без яратып үстерә торган күп яшелчәләр әчелеге аз яки нейтраль туфракны үз итә. Әче туфрактан алар үзләренә кирәкле микроэлементларны үзләштерә алмый. Әчелеге аз булган җирдә кыяр, кәбестә, бәрәңге, помидор баклажан, кабак, карлыган, крыжовник, розалар, яран, пион, нәркис, лаләләр үстерергә мөмкин.

■ Селтеле туфрак та күпчелек үсемлекләр өчен кулай түгел. Алай да кизил, барбарис, боярышник, сирень, айва, абрикос агачлары селтеле туфракта да үсә ала.

Бакчадагы җирнең әчелеген билгеләгәннән соң, аны нейтральләштерү чараларын күрергә кирәк.

■ Иң киң таралганы – көз көне казыганда бакчага сүндерелгән известь кертү. Бик әче туфракка ул 1 сутыйга 50–75 кг исәбеннән кертелә. Әчелеге аз булса – 25–35 кг.

■ Известь урынына доломит оны да кулланырга була. Ул ваграк булган саен, реакциягә тизрәк керә. 1 квадрат метр җиргә 500–600 г доломит оны кирәк. Әчелеге аз туфракка 350 грамм кертсәң дә ярый.

■ Утын көле дә бик нәтиҗәле. Өстәвенә, ул калийлы ашлама да булып тора. Утын көле 1 квадрат метр җиргә 100–200 грамм алына.

■ Гап-гади акбур да туфракны нейтральләштерә ала. Аны исә 1 квадрат метрга 300 г нисбәтендә кулланалар.

■ Кайчак туфрак, киресенчә, селтеле була. Аның әчелеген арттыру өчен көздән үк чи тирес, яфрак компосты, торф, мүк, пычкы чүбе, ылыс кертеп казыйлар. Боларның тәэсире шунда ук сизелми, ләкин нәтиҗәсе озакка җитә.

■ Көз көне казыганда җиргә катлаулы ашламаларны да кертеп калдыру мөһим. Мәсәлән, фосфорлы ашламалар туфракта начар эри. Аны көздән үк куллансаң отышлырак. Тиресне дә көздән үк кертеп калдырсаң, язын җир көпшәгрәк, йомшаграк була – микроорганизмнар тиресне таркатып, андагы микроэлементларны үсемлекләр кабул итәр хәлгә китереп өлгертә.

■ Җир тыгыз, авыр балчыклы булса, көз көне казыганда ком кушалар.

■ Кайбер яшелчәләрне көздән үк утыртып калдырырга кирәк була. Авыр туфраклы бакчаларда көздән әзерләп калдырылган түтәлләр язга тыгызлана, туфрак өсте ката. Бу очракта мүлчәләү ярдәм итә. Түтәл өстен коелган яфрак, үлән белән мүлчәләп калдырсаң, язга туфрак алай ук тыгызланмый.

■ Кар эрү белән, мүлчәне тырмалап алырга кирәк, ул җирнең җылынуына комачаулый.

Фото: www.pixabay.com


Кучкар. Әллә ниләр вәгъдә итә бу ай. Суынган мөнәсәбәтләрне җайлап җибәрү мөмкинлеге тора. Планеталарның тезелеше тәвәккәллеккә этәрә. Эшләрне ахырына җиткерү өчен кулай чор.


Үгезбозау. Финанс ягын җайлар өчен яңа мөмкинлекләр барлыкка килер. Тормышыгызда яңалыклар күп булыр. Ләкин уйламыйча гамәл кылудан сак булыгыз. Импульсивлык сезгә зыянлы.


Игезәкләр. Һөнәри үсеш чоры. Тормышка актив карашыгыз мөмкинлекләрегезне барларга булышачак. Алдыгызда яңа офыклар ачылачак, файдаланып калыгыз.


Кысла. Айның беренче яртысы – идеяләрне һәм яңа проектларны тормышка ашыру өчен менә дигән вакыт. Яңа эшкә керешәсез икән, уңышлы тәмамланачак. Сизгерлегегез искиткеч: чынны ялганнан шундук аерырсыз.


Арыслан. Илһамлы вакыт. Сез иҗади дулкында. Эшегездән, аралашулардан, мөнәсәбәтләрдән тәм табарсыз. Кайдадыр тәвәккәллек кирәк булыр, курыкмагыз, уңыш сезнең якта.


Сөмбелә. Моңарчы бозылган араларны җайлау, мөнәсәбәтләрне яңарту өчен яхшы чор. Төп коралыгыз – башкаларны ышандыру сәләтегез. Төгәллеккә омтылыгыз, уңышка ирешү өчен шушы сыйфат мөһим.


Бизмән. Яңача уйлау, яңача эшләү сәләтегез ачылачак. Ай башында ук эшегезнең нәтиҗәләрен тоярсыз. Алдыгызда яңа мөмкинлекләр тора. Сезгә чынлыкта ни теләвегезне генә ачыкларга кирәк.


Чаян. Тормышыгызда күңелле вакыйгалар көтелә. Җаныгыз тынычлап калыр. Сездән бөркелгән уңай энергияне башкалар да сизми калмас. Бу исә күп кенә киртәләрне бер мәшәкатьсез җиңәргә булышачак.


Укчы. Бу айда иң зур куанычыгыз – гаиләгезнең уңышлары. Камиллеккә омтылу сезгә элек тә ят түгел иде, хәзер ул аеруча көчле күренә. Теләгегезне чынга ашыру өчен каяндыр бер көч алырсыз.


Кәҗәмөгез. Яңа идея белән янарсыз. Кызыгы шунда: аны тиз арада тормышка ашыру юллары күренер. Тормышыгызда куанычлы яңалык көтелә. Бу ай моңарчы күрелмәгән уңыш вәгъдә итә.


Сукояр. Тормышның бар өлкәсендә үсеш көтелә: эштә дә, гаиләдә дә, керемнәрдә дә... Аралашучанлыгыгыз, кешеләргә дустанә мөнәсәбәтегез – иң зур ярдәмчегез. Моңарчы чишелеше юк сыман тоелган мәсьәләләр дә уңай хәл ителәр.


Балык. Тыныч чорга керәсез. Алай да ул күбрәк эш белән узар. Айның икенче яртысы планнар кору, аларны тормышка ашыру өчен яхшы вакыт. Бердәнбер кыенлык – яңа планнарның юклыгы гына булырга мөмкин.

Чит илләр *Россия* *Татарстан*

сентябрь дә кабынган йолдызлар



Вера Минкина (9.09.1918–20.09.2011) – **Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, 60 елдан артык гомерен Камал театрына багышлаган шәхес.**

Чистай районы Бахта авылында туа. Казан Театр техникумын тәмамлап, иҗат юлын Республика күчмә театрында башлый. 1952 елдан – Камал театрында. Башкарган рольләренең кайберләре: «Зәңгәр шәл»дә – малай (К. Тинчурин), «Җырланмаган җыр»да – Гөлбикә (М. Кәрим), «Һиҗрәт»тә – Сания (Н. Исәнбәт), «Чаткылар»да – Гыйльмениса (Т. Гыйззәт), «Кыю кызлар»да – Зөлкагыйдә (Т. Гыйззәт), «Гөргери кияүләре»ндә Палый (Т. Миңнуллин) – барлыгы 200 дән артык.

Ике кинофильмда: М. Горький исемендәге киностудиядә төшерелгән «Ришад – внук Зифы» (1981) һәм Свердловск киностудиясенең «Клад» (1975) фильмнарында уйный. 1991 елдан 2004 елгача – «Инсаният» труппасында.



Лидия Федосеева-Шукшина (25.09.1938) – **РСФСРның халык артисты**.

Ленинград шәһәрендә туа. Башлангыч сыйныфлардан ук Кино йортындагы драма түгәрәгенә йөри. Режиссер Анатолий Граник аны нәә шул вакытта күреп алып, «Максим Перепелица» фильмында уйнарга чакыра. Кечкенә генә роль аның киләчәген хәл итә – 1957 елда ВГИКка укырга керә (Тамара Макарова һәм Сергей Герасимовларда укый). Беренче уңышы – «Сверстницы» фильмындагы студент кыз роле. Ире – язучы, режиссер, актер Василий Шукшин белән алар «Какое оно, море» фильмын төшергәндә таныша. Ире белән бергә уйнаган «Печки-лавочки», «Странные люди», «Даурия», «Калина красная» фильмнары аңа уңыш һәм танылу алып килә.

Лидия Федосеева-Шукшина безгә актриса Мария Шукшинаның әнисе буларак та таныш.



Дженнифер Тилли (16.09.1958) – актриса, сценарист.

Американың Лос-Анджелес шәһәрендә туа. Тамашачыга «Головы», «Пули над Бродвеем», «Связь», «Лжец, лжец», «Страна приливов», «Невеста Чаки», «Пули над Бродвеем» фильмнары аша таныш. Соңгысы өчен «Оскар»га да тәкъдим ителә.

Карьерасын телесериаллардагы кечкенә рольләрдән башлый. 1989 елда аны «Скачи во весь опор» комедиясендә уйнарга чакыралар. Шул ук елны аның катнашында «Знаменитые братья Бейкер» фильмы дөнья күрә. Фильмдагы җырны Стив Колинсон махсус аның өчен яза. 1994 елда Ким Бейсингер һәм Алек Болдуин белән «Побег» фильмында уйный.

Фото: www.aeslib.ru; www.vokrug.tv

PRESSA



ИЛАҺИ РӘХӘТЛЕК

Бәйрәм халәтен башкача да тасвирлап була икән – тамашачыга картиналардан үтә күренмәле тынлык, үзенә бер маза, илаһи рәхәтлек күчә. Мәскәү рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илдар Мостафин картиналарында әнә шундый стиль чагыла.

Тәһрандагы әкияти сәяхәте вакытында Илдарга фарсы миниатюраларының үзенчәлекле сәнгате ачыла. 2005 елда ул Иранда «Изге Коръән» күргәзмә-бәйгесендә катнаша. Төрле илләрнең рәссамнары арасыннан жюри Мостафин картиналарын иң яхшылары дип билгели.

Шәрык аңа бик нечкә җепләр аша – электән үк классик фарсы шигъриятен укып баруы, үз тамырлары турында уйланулары аркылы – җай гына килеп керә. Әкренләп картиналарына татар милли бизәкләре, символлары үтеп керә башлый. Мәсәлән, кулдан тукылган кызыл башлы татар сөлгеләре. Соңрак алар Илдарның натюрмортларын бизи. «Орнамент үзе дә халык күңеле аша узган бизәк бит ул. Аны һәркайда – агач ботакларында, болытларда, тау сызыкларында күреп була», – ди оста үзе. Идел Болгариясе, Урта гасыр Казаны, татар риваятьләре, халык әкиятләре, Колшәриф мәчете силуэтлары, Уфа турындагы истәлекләре иҗатына нигез булып ята. Шул дулкында Дәрдмәндкә, Тукайга, суфичылык шигъриятенә, Коръән аятьләренә, Урта Азиянең мәһабәт мәчетләренә багышланган картиналар циклы языла.

Татар сюжетлары исә аңа балачактан, 60 нчы еллар Уфасыннан ук таныш. Нестеров музееның бай коллекциясе, Башкортстан рәссамнарының иң яхшы картиналары Илдарны шулай ук сәнгать дөньясына әзерләгән. Мәскәүгә күчкәнче, Уфа сәнгать училищесының рәссамнар әзерли торган бүлеген тәмамлаган. Аннары башкаланың Косыгин исемендәге Текстиль институтына барып кергән. Гамәли сәнгать факультетында келәм туку осталыгын үзләштергән (гобелен техникасы), тукымага сурәтләр төшерү серләренә өйрәнгән (батик). Соңгы курста укыганда күн галантереясе белән кызыксынып киткән. Аспирантураны тәмамлаганнан соң, Илдар Мостафинга Венгриядә гамәли сәнгать академиясендә уку бәхете елмая. Шул елларда Венгриянең Россиядәге илчесе, атаклы дипломат Дьерд Нановски (ул сынлы сәнгать белән мавыга) белән дуслаша. Венгрия дипломаты чит илдә Мостафинның беренче шәхси күргәзмәсен оештырырга булыша. Аннары инде Голландия, Германия, Австрия, Швейцария, Испания һәм, әлбәттә, Россиядәге күргәзмәләр... Бу елларда карикатура жанры белән дә мавыгып ала. Болгариянең юмор башкаласы Габровода, Токиода, Гаванада карикатура конкурсларында җиңә. «Советский Союз» журналының баш рәссамы булып эшли.

Берничә ел элек Мәскәүнең Чертанов районында узган «Язгы Кырым» күргәзмәсе әле дә күз алдымда. Шәкертләре – яшь рәссамнар эшләре арасында Мостафинның җылы Кырым пейзажлары үзенә бер якты бизәк булып балкый. Текстиль институты аның өчен туган йорт кебек: Илдар Харис улы анда декоратив сәнгать һәм графика кафедрасы мөдире вазыйфаларын башкара.

...Илдарның сугышта һәлак булган бабасы шәмаилләр язу остасы булган. Татар шәмаиле кайтавазын Илдар Мостафин картиналарында да тоеп була. Бернәрсә дә очраклы гына түгел.

Аның эшләре безгә илаһи рәхәтлек бәйрәме ясый.

Марат СӘФӘРОВ













ИЛДАР МОСТАФИН

PRESSA



сеть ювелирных салонов
ЭКСКЛЮЗИВ

РЕКЛАМА

РОСКОШЬ ПО ДОСТУПНЫМ ЦЕНАМ

СКИДКИ ДО 50%* | ПОДАРОЧНЫЕ СЕРТИФИКАТЫ

*Акция действует с 1 июля по 31 октября 2018 года. Подробности на www.exclusive-jewelry.ru

ул. Восстания, 62, (843) 564-77-67, ул. Зорге, 67 (843) 268-94-95,
ул. Бутлерова, 29, (843) 238-42-50, ул. Чистопольская, 16/15, (843) 223-00-08.
www.exclusive-jewelry.ru, instagram: @exclusive.kazan

